КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни җомга

№4 (131)
23 гыйнвар
1998 ел

елның июленнән
башлап чыга

Атналык гәзит

بسم الله الرحمن الرحيم

Бүгенге санда:

2 *Ләбибә ИХСАНОВА.* Бүгенге үзгәрешләрне без — олы кешеләр әзерлексез каршыладык, күбебез югалып калды.

6 *Диас ВӘЛИЕВ.* Җиңе-
үнең тын-аулак мохитендә без
бертуктаусыз эшләргә, бу эштә
кыланчык-мактанчык хаким-
нәрдән дә, мәрткә киткән
халыктан да тану-танылу көтеп
торырга тиешле түгел.

8 *Тәминә БИКТИМЕРОВА.* Мәрҗанинең оныгы Суфия апа әнисе Гайшә аша шан-шәрәфле Апанайлар нәселенә барып тоташа...

12 *Әзһәр ХӨСӘЕНОВ.* Гөлшат Зәйнашева кебек каләм ияләре булуына горурланып яшим һәм, һич тә икеләнмичә, аны җырлар алиһәсе дип атыйм.



Әлмисактан килә йолабыз —
Изге Сузгә дога кылабыз...

Мөхәррир мөнбәре

Кешелек ашау-эчүдән тыелып торуда яшәү өчен кирәкле тирән мәгънә күргән, дини өйрәтүләрдә исә ул изге гамәл итеп саналган. Гомумән, Рамазан шәрифтә ураза тотуны әһле ислам бәхет-сәгадәткә ирешүгә тиңли. Әмма Аллаһының шушы мөбарәк аенда ирексездән „ач торучылар"ны да күрәбез. Юк, алар, хата-гөнаһлардан арынып, оҗмахка керергә ашкынмыйлар; алар нибары үз хокуклары хакына ашаудан тыелырга мәҗбүр. Әйе, бу тәртипсез чорда хәләл хезмәт хакыны да ачлык игълан итмичә алып булмый. Халкыбызның бәхетсезлеге өчен дә күпме милләтпәрвәр атналар буена тәгам-ризыктан ваз кичеп торды. Ярабби, бу изге айда фарыз ураза тотучыларның да, ихтыярсыз ачлык игълан итүчеләрнең дә гамәлләре күпмедер әҗер-савап китерсен иде...

Зиннур **МАНСУРОВ**

Мин әйттем

Безнең ишек алдын бер яктан зур гына камышлы күл чикләп тора. Җәен анда кыр үрдәкләре йөзә, малай-шалай кармак салып утыра. Кышын күл өсте боз белән каплангач, калын кар катлавы да яткач, аркылы-торкылы сукмаклар салып, кешеләр үтеп-сүтеп йөри.

Нинди зур мәйдан буш һәм файдасыз ята дип, эче пошкан кешеләр дә бар икән әле. Быел менә шушы күл өстен кардан әрчеп, су сибеп, менә дигән шугалак ясадылар. Кар явып киткән саен боз өстен чистартып торалар. Ләкин, ни хикмәттер, көндезен дә, кичен дә ник бер бала, ник бер яшь җилкенчәк күренсен шунда. Чырчу, бала-чага тавышы яңгырап торырлык кына урын, югыйсә. Кыш уртасы килеп җитте, мәктәп укучылары кышкы каникулларда кар өстендә тәгәри-тәгәри уйнап, чаңгыда, конькида җилдереп, тәннәрен язып, каннарын кыздырып алудан тәм тапмыйлар. Ул гынамы, хәтта физкультура дәресенә дә бик ук теләп йөрмиләр. Яшүсмерләребезнең күбесенә битарафлык, инициативасызлык, әйткәнне көтеп тору кебек чирләр кайдан килде соң әле? Романтика, матур хыяллар белән тилереп яшәү нигә онытылды? Элегрәк елларда яшүсмерләр космонавт булам, сәяхәтләргә чыгам, табигатьнең яңа законнарын ачам дип, бөек идеаллар белән яшиләр иде. Аларның хәзерге яшьтәшләре, күп булса, эшмәкәр булам, ди. Ул дәрәҗәгә үрелүгә өмете юклар милиционер, йә шофер булырга җыена. Ә күбесе киләчәк язмышы турында бөтенләй дә уйланмый. Кыймылдарга иренгән уйларга да иренүчән була. Минем тугызынчы, унберенче сыйшунда аяк басмавы юклыктан да килә. Юк дисәк тә, бар алар үзләре, спорт кирәк-яраклары кибетләрдә тулып ята. Тик бәяләре генә якын килерлек түгел. Элекке елларда дүртбиш сум торган алюмин чаналар хәзер йөз егерме сум, әйбәтрәк итеп бер сыксаң сынарга торган кәшәкә таягы – 40 сум, ботинкалы тимераякларның бәясе егылып китмәле – 35-37 үлчәүлесе 500 сум (болар барысы да яңа бәя белән) тора икән.

Спорт кирәк-яракларының бәяләрен төшерү хакында уйларга да мөмкин түгел, базар мөнәсәбәтләре аңар юл куймас. Шулай да кайбер чараларны куллану мөмкин булыр иде. Менә, мәсәлән, адресы яклау дигән кагыйдә гамәлдә йөри. Ярлы кешеләрнең балачагаларына өстәмә туклану талоннары бирәләр. Елына күрә җылы шулпа, дигәндәй, ярап тора үзе. Сабыйларга саф һава һәм хәрәкәтле уеннар икмәк һәм сөт кебек үк зарури икәнен уйласак, фәкыйрь гаиләләрнең балаларына мәктәпләр аша чана, чаңгы, тимераяк кебек әйберләрне арзанрак бәягә сатуны хөкүмәтебез оештыра алыр иде. Заманында мәктәпләрнең үз карамагында да спорт кирәк-яраклары була иде. Юк җирдә шуны булдыру, барын тулыландыру өчен дә төрле чаралар күрергә мөмкин. Шуларның иң популяры – телемарафон. Бу максат өчен хәйрия концертлары, спектакльләр кую да изге эш булыр кебек. Ил төкерсә күл була, ди бит халык. Балаларыбызның сәламәтлеге өчен нидәр генә эшләмәссең. Моның өчен үткәннәрдән гыйбрәт алу да зыян итми. Борынгы Грециядә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүне мәҗбүри эш дип санаганнар. Моның өчен бөтен шартлар тудырылган. Яшьләрнең сәламәтлеге хакына 22 яшькә җиткәнче аракы эчү, тәмәке тарту закон белән тыелган. Шуңа күрә борынгы эллиннар сәламәтлекнең, матурлыкның эталоны булып саналган. Сәламәт тәндә – сәламәт акыл, дигән сүзне дә онытмыйк. Бала-чаганың уенына уен эш дип карамыйк. Уен ул аның табигый халәте, хәрәкәтчән, җитез, елгыр балалар тормышта да актив, хезмәттә уңган, хөрмәтле кеше булып үсәләр. Әйдә, уйнасыннар рәхәтләнеп. Уйнарга өйрәтик без аларны. Шугалаклар, чаңгы юллары, бозлы таулар буш ятмасын, бала-чага тавышыннан тынып тормасын.

Ләбибә **ИХСАНОВА**

Уен – уен эш түгел

булды, ә шугалак һаман буш һәм тын тора. Алар өчен тырышып йөргән кешеләрнең хезмәте әрәм.

Гомер ул аккан су кебек, узып киткәч кире кайтарып булмый дип әйтәләр. Шулай да һич онытылмый торган, ераткагы йолдыз кебек ымсындырып яшәткән якты истәлекләр кала күңелдә. Минем дә беренче тапкыр Казанга килүем нәкъ менә шул шугалак һәм тимераяк белән бәйле булырак истә калды. Фатир төшкән танышларыбызның тәрәзәләре "Динамо" стадионының шугалагына карап тора иде. Кичләрен аллы-гөлле утлар кабына, күңел җилкендергеч музыка уйный, зәңгәр боз өстендә ялгыз да, кулга-кул тотынып та тимераякта шуалар. Мин аларга кызыгып, шул матурлыктан сихерләнеп, сәгатьләр буе тәрәзә төбендә утырам.

Иртәгесен, әтигә ялына-ялына, "Снегурочка" дигән тимераяк алдырдым. Авылда бер вакыйга булды ул. Заводта ясалган чын тимераяк беренче тапкыр авылга кайтты бит. Колхозга беренче трактор кайтканнан да ким булмагандыр, билләһи. Үзебез ясаган тимераяк белән генә шуа идек бит без. Агач кисәгенә тимер чыбык, йә калай кагабыз да шуны боргычлап киез итеккә беркетеп куябыз һәм күзләр бәйләнгәнче, караңгылар төшкәнче инеш өстендәге бозда шуабыз. Минем дә бер малайдан дәфтәргә алыштырып алган шундый тимераягым бар иде. Инде менә чып-чын тимераяк, шәһәрчә әйтсәң, коньки ем булды. Моны ничек онытырсың?!

Кызык, бүгенгеләр бала чакларын нәрсә белән исләренә төшерерләр икән? Аптырыйм мин аларга. Саф һавада, ак ныф балаларыннан, мәктәпне тәмамлагач ни эшләргә уйлыйсыз, дип сораганым булды. Бик күп мәртәбәләр, белмим әле, дигән җавапны ишеттем. Ә бит аларның дөньяны кочардай булып йөрер чаклары әле.

Яшүсмерләрнең мондый төшенкелеккә бирелүе тормышның тотрыксызлыгыннан, ышанып йөргән нәрсәләргә карашның кинәт үзгәрүеннән, алдагы көннең билгесезлегеннән килә торгандыр. Барысы да кинәт булды бит, бу үзгәрешләрне без – олы кешеләр – әзерлексез каршыладык, күбебез югалып калды. Буыны сыек яшүсмерләр аны тагын да авыррак кичерде.

Яңа шартларда яшәү физик чыныгу алмаган, аз хәрәкәтләнгән балаларның психикасына да, сәламәтлегенә дә нык тәэсир итте. Мәгълүматларга караганда, мәктәп балаларының сиксән проценты сколиоздан (умыртка сөяге кәкрерәю) җәфа чигә, бик күбесе кан азлыктан интегә, күрү сәләте начар булганнар да елдан-ел күбәя икән. Бу авыруларның сәбәбе – һавада аз булу, хәрәкәт җитмәү, начар туклану, көннәр буе телевизорга төбәлеп утыру икәне мәгълүм.

Балаларны сау-сәламәт үстерү хәзерге заманда әти-әни кулыннан гына килә торган эш түгел. Бу зур проблеманы хөкүмәт үз карамагына алып, комплексы чаралар белән генә хәл итәргә мөмкин. Татарстан парламентында балалар һәм яшүсмерләрнең бүгенге хәле турында әзерлекле зур сөйләшүнең булганы юк әле. Бу исә җитлеккән мәсьәлә генә түгел, аңар игътибар итәргә соңга да калып барабыз бугай инде. Үзебез атлаган саен, балалар – тормышның киләчәге, дип әйтергә яратабыз. Саулыкка туймаган, хылсыз, дөртсез балалар, үсеп җиткәч, нинди тормыш корырлар дип уйлаганыбыз гына юк.

Һәртөрле уен – бала-чаганың стихиясе ул. Уйнаганда ул үзен зур кеше дип хис итә, зурларча фикер йөртергә өйрәнә, характеры формалаша, табигый сәләте камилләшә. Юк, без аларны сабый чакның кадерен белмәүдә гаепләргә ашыкмыйк әле. Бала ул һәрвакыт бала булып кала. Әнә бит, әле бая мин әйткән күлнең текәрәк ярыннан шуып, бозландырып бетергәннәр. Асларында фанермы, картон кисәгеме шунда. Пальто итәгенә утырып шуарга да күп алмыйлар. Кая киткән соң әле безнең зәңгәр, яшел, кызыл пластмассалардан ясалган, култык астына кыстырып кына йөрерлек, җиңел "ледянка"ларыбыз? Бармак белән төртсәң дә шуып китәргә торган алюмин чаналарыбыз кая киткән? Әллә заводлар аларны да ясаудан туктаганнармы? Бала-чага өчен бик кирәк булган шундый вактөякне дә чит илләрдән кайтара башладыкмыни? Үзебезнең кара чәчле, алсу йөзле, әнҗе калфаклы "Айсылу" дигән курчакгыбызны диңгез артыннан килгән "Барби"лар кысрыклап чыгарды бит әнә. "КамАЗ", "Жигули" дигән уенчык машиналарны электрон уенчыклар алыштырды. Бәяләре көч җитәрлек булса хупларга гына иде дә бит, катлаулы уенчыклар белән эш итәргә өйрәнерләр иде. Кая ул?! Әти-әниләре айлар буе хезмәт хакы алмаган бер вакытта уенчык сорап сүз кузгатырга мөмкинме соң? Ләкин уйныйсы килә баланың, кызыга уенчыкка. Бервакыт киоск тәрәзәсендәге матур-матур уенчыкларга мөлдерәп карап торган малайны кызгандым. Әнисе җилтерәтеп алып киткәч тә әле, борылып карый-карый, сөртенеп егыла язып, бахыр.

Ишек алдында гына менә дигән шугалак булганда бала-чаганың

ВАКЫЙГАЛАР
ХӘБӘРЛӘР
ЯҢАЛЫКЛАР

Мөнәсәбәт

Әхлагың ташка үлчим булса...

Рамазан тәмамланып килә. Ул байтак кына милләттәшләребез өчен чынлап та изге ай булды. Җан таләбе буенча ураза тоттылар, сәҗдәгә киттеләр, хәер-сәдака бирделәр. Изге гамәлләр Аллаһыга барып ирешер шәт, иншалла. Әмма шушы рухи чистарыну аенда башка төрлерәк хәлләр дә күзәтелмәде түгел. Мәсәлән, Бауман урамында Татар ашлары йорты кафесыннан сәүдә итүче татар хатыны иртәдән кичкә кадәр: "Горячий өчпочмак, горячий өчпочмак", – дип берөзлексез кычкырып торды. Урамда аяк өсте ашап йөрүчеләр дә өзелмәде. Эчеп, бәйрәм итеп, күңел ачып йөрүчеләр дә җитәрлек иде.

Шуның өстенә ураза тотучыны сусызлык белән дә сынау үткәрелде. Нигездә уразаны өлкән буын кешеләре тота. Аларның күбесе ялгызаклар һәм сәхәрдән алып авыз ачканчыга кадәр намазлык өстендә сәҗдәгә китеп һәм урынга ятып ял итеп кенә торучылар. Гыйнвар уртасында җитмешне узган Гамилә апаның, чиләк күтәреп, җиргә бөгелә башлаган гәүдәсен турайта төшеп, бер колонкадан икенчесенә сугылып, су эзләп йөргәнен күрдем. Сугышларны, ачлыкларны, тормыш авырлыкларын кичергән һәм сынаулар алдында бирешмәгән әлеге апаның кайдан булса да су табып, авыз ачар вакытка бер чынаяклык булса да чәй кайнатасына шикләнмим. Әмма ураза тоткан апаның биш мәртәбә намазга басасы һәм аның өчен тәһарәтләнәсе дә бар бит әле. Ә моның өчен су кирәк.

Татарстанда бик күп мәчет салынды, дип мактанырга яратабыз. Әмма кеше саен бер мәчет салып куйсак та, әгәр әхлагыбыз ташка үлчим икән, аннан адәм баласының үзенә дә, җәмгыятькә дә файда булмаячак.

Гарәп илләре Рамазан аенда гына түгел, ә ел әйләнәсе Коръән кануннары буенча яши. Һәм бу кануннарны җирле халык та, читтән килүче туристлар да үтәргә тиешләр.

Без дә үз Татарстаныбызда, Ислам кануннары өстенлек итәргә тиешле дәүләттә яшибез кебек. Кызганыч, бездә шәрран ярып, урысчалатып: "Горячий өчпочмак", – дип бакыручыны да, ураза тотучы халыкны сусыз калдыручыны да, хәтта дин әһелләре арасында бара торган ызгыш-талашны да хөкем итүче юк. Чөнки дин дәүләттән аерылган. Ә динсез, имансыз дәүләттә яшәүчеләрнең кылган гамәлләре дә кяферләрчә килеп чыга инде ул...

Сәрмәдия **СӨЛӘЙМАН.**

Әйткән сүз – аткан ук

Геннадий СЕЛЕЗНЕВ, Русия Дәүләт Думасы Рәисе (законсыз төстә гамәлдә йөри торган империя гербындагы ике башлы бөркет турында):

"Әгәр бүген илдә референдум үткәрелсә, халыкның күпчелеге әлеге аңлаешсыз кош белән беркайчан да килешмәс иде".
("КП").

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Русия Федерациясе Президенты Указы нигезендә В.Качалов исемендәге Урыс зур академия драма театры директоры **ПЕРВИН Григорий Мееровичка "Русия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре"** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Президенты Указы нигезендә Чаллы шәһәре хакимиятенең мәдәният һәм сәнгать идарәсе каршында эшләп килүче "Эврика" мәдәният үзәге артисты **ХӘЙРУЛЛИНА Гөлдания Мөбәрәкҗан кызына "Татарстанның атказанган артисты"** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Президенты Указы нигезендә Тукай районында чыга торган "Якты юл" газете мөхәррире **ГОМӘРОВА Халидә Бари кызына "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре"** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Президенты Указы нигезендә Казан дәүләт университетының философия кафедрасы доценты **КОРОЛЕВ Валерий Васильевичка "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре"** дигән мактаулы исем бирелде.

Изге Рамазан ае уңаеннан котлау

Галиҗәнап, Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев әфәндегә

Хөрмәтле Президент!
Кадерле Кардәш!

Изге Рамазан ае уңаеннан әчкерсез тәбрикләвегез өчен Сезгә рәхмәт әйтәм һәм изгегезне дә чын күңелдән котлыйм.

Шушы уңайдан шәхсән Сезгә, Галиҗәнап, сәламәтлек һәм уңышлар, ә тугандаш татар халкына бәхет һәм иминлек телим.

Сөләйман ДӘМИРАЛ,
Төркия Республикасы Президенты.
16 гыйнвар, 1998 ел.

Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге комитеты белдерә

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге комитеты 1998 елда шушы бүләкне дәгъваларга эшләр кабул итү турында белдерә. Тикшерүгә аеруча оста башкарылган, иҗтимагый танылу алган әдәбият, сәнгать әсәрләре, шулай ук сәнгать белеме, әдәбият белеме өлкәсендәге хезмәтләр, аеруча эстетик кыйммәтле архитектура корылмалары кабул ителә.

Бүләккә дәгъва кылучы хезмәтләрне дәүләт, иҗтимагый һәм иҗат оешмалары 1998 елның 16 февраленә хәтле күрсәтә алалар.

Күрсәтү шартларына бәйле мәсьәләләр белән Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге комитетына түбәндәге адрес белән мөрәҗәгать итәргә кирәк: **420060, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты. Телефоннар: 36-69-26, 36-25-08.**

Татарстан – Русиянең милли бүләге иясе

Мәгълүм булганча, Русия Федерациясенең Сәүдә-промышленность палатасы, Журналистлар берлеге, Русия җәмәгатьчелеге белән элемтәләр ассоциациясе тарафыннан җәмәгатьчелек белән элемтәләрне үстерү өлкәсендә "Көмеш укчы" дигән милли бүләк булдырылган иде. Бу бүләк Русия Федерациясенең матбугат һәм җәмәгатьчелек белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итүче дәүләт органнары, субъектлары җитәкчелегенә бирелә.

Милли бүләк жюрие карары белән Татарстан Республикасы шушы бүләк лауреаты дип табылды. Президент М.Шәймиев Русия Федерациясенең массакүләм мәгълүмат чаралары һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр аеруча нәтиҗәле үсә торган субъект җитәкчесе буларак билгеләп үтелде.

Килешүгә кул куелды

Татарстан Хөкүмәте һәм Түбән Новгород өлкәсе хакимияте арасында сәүдә-икътисади хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды. Бу документ ТР Президенты М.Шәймиев һәм ул чакта Түбән Новгород өлкәсе губернаторы булган Б.Немцов 1994 елның 6 маенда кул куйган килешүне тагын да үстерә, ике якка да файдалы хезмәттәшлекне, оешма, предприятиеләр белән сәүдә-икътисади бәйләнешләрне күздә тота.

Килешүгә Татарстан Премьер-министры Ф.Мөхәммәтшин һәм Түбән Новгород өлкәсе губернаторы И.Скляров кул куйды. Кул кую тантанасында Президент М.Шәймиев катнашты.

Актерның күңел бәйрәме

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның һәм Русиянең халык артисты, СССР һәм Татарстанның Дәүләт бүләкләре иясе Ринат Таҗетдиновның 60 яшьлек юбилее тантаналы шартларда билгеләп үтелде. Артистны котларга Татарстан Президенты М.Шәймиев тә килде.

Җомгадан – җомгага

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЬЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Кремльдә М.Шәймиев дин әһелләре белән очрашты һәм республикада мөселман хәрәкәте мәсьәләләре турында фикер алышты.

Премьер-министр Ф.Мөхәммәтшин Чүпрәле районының Иске Ишле авылында яңа мәктәп бинасын ачу тантанасында катнашты һәм районның төзелеш эшләре бара торган башка авылларында да булды, Чаллыдан, Әлмәттән килеп эшләүче төзүчеләр белән очрашты.

16-17 гыйнварда Казанда "Татарстан Республикасында Түбән Новгород өлкәсенең икътисади көннәре" үткәрелде.

Лениногорскида спорт мәктәбе ачылды.

Татар иҗтимагый үзәгенең чираттагы утырышы булып узды һәм анда үзәкнең яңа рәис-координаторы итеп Ф.Сафиуллин сайланды.

Республика Парламенты Рәисе В.Лихачев җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе Чуашиядә Н.Федоровның Президент вазифаларын үтәүгә керешүе уңаеннан үткәрелгән тантанада катнашты.

"Татнефть" акционерлык җәмгыяте "Тирә-юнь мохитне эффектлы контрольдә тоткан өчен" халыкара алтын медальгә лаек булды.

Берләштерелгән дәүләт музеенда кабат оештырылган "Шәрекъ" клубының беренче утырышы узды.

Республика үзәк музеенда К.Тимирязев исемендәге Мәскәү дәүләт биология музееның "Диңгез төбендәге хәзинәләр" дигән күчмә күргәзмәсе ачылды.

Халыкара гроссмейстер А.Галләмованың әнисе туган төбәктә – Актанышта шахматчы катнашында шахмат бәйрәме уздырылды.

Кукмара районының Зур Сәрдек авылы мәктәп-лицее һәм Кукмараның 2 нче урта мәктәбе коллективлары Бөтенрусия конкурсында җиңеп лауреат булдылар, ә җитәкчеләре З.Сабитов белән М.Йосыфҗановка "1997 ел директоры" дигән мактаулы исем бирелде.

Күренекле композитор Н.Җиһановның туган көне уңаеннан Зур концерт залында аның әсәрләреннән торган концерт булып узды.

Сәхифәбездә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, "Татар-информ" һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

Беренче биттә – **Н.ТУГАНОВ** фотосы.

Шәриф Камал иҗатына багышлап

Шәриф Камалның Казандагы мемориаль музеенда "Шәриф Камал – журналист" дип исемләнгән әдәби-музыкаль программа күрсәтелде.

Монда күренекле каләм ияләре, мәктәп укучылары кунакка килде. Алар алдында Казан дәүләт университетының татар журналистикасы кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты Р.Нуруллина, композитор Р.Еникеев, артистлар А.Арсланов, Ә.Галимова, Т.Дубин һ.б. чыгыш ясады.

Маэстроны хөрмәтләү

Әлмәт һәм Бөгелмә шәһәрләрендә Татарстан Дәүләт симфоник оркестрының бәйрәм концертлары булды. Алар оркестрның сәнгать җитәкчесе һәм дирижеры, Татарстанның һәм Казакъстанның халык артисты, профессор Фуат Мансуровның 70 яшьлек юбилеена туры килде. Юбилярны Әлмәттә "Татнефть"нең генераль директоры һәм "Рухият" фонды советы рәисе Ринат Галиев, Бөгелмәдә шәһәр хакимияте башлыгы Наил Мәһдиев кайнар котладылар.

"Иске Казан"га яңача караш кирәк

"Казан" милли мәдәният үзәгендә тарихчылар, археологлар, галимнәр һәм журналистлар катнашында "Түгәрәк өстәл" уздырылды. Уртага салып сөйләшкән сүз "Иске Казан" тыюлыгы һәм шул исемдәге музей, әлеге юнәлештә алга куелган мәсьәләләр хакында булды. Татарстан мәдәният министры урынбасары Рафаэль Вәлиев, археолог Альберт Борһанов, музей директоры Хәлил Касыймов һәм "Казан" милли мәдәният үзәге директоры Ринат Закиров һ.б. җәмәгатьчелек игътибарын янә бер тапкыр "Иске Казан" проблемаларына юнәлтеп кенә калмадылар, кызыклы тәкъдимнәр белән дә чыктылар.

Олуг юбилей мөнәсәбәте илә

Тиздән киң җәмәгатьчелек татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакыйның туына 120 ел тулуны билгеләп үтәчәк. Шушы уңайдан татарлар яши торган күп кенә төбәкләрдә әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Г.Исхакыйның иҗаты, тормыш юлына багышланган кичәләр үткәрелә. Мондый чараларның берсе Самара өлкәсенең Камышлы районы, Иске Усман мәктәбендә дә уздырылды.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фидания Нуретдинова укучыларга, аларның әти-әниләренә олуг шәхеснең катлаулы тормыш юлы турында сөйләде, иҗаты белән таныштырды.

Әлеге кичә Гаяз Исхакый иҗатының зур калаларга гына түгел, ә кечкенә авылларга да кайтуы турында сөйләүче вакыйга буларак истә калды.

Әтнә Мәрҗани елында яши

Шиһабетдин Мәрҗанинең 180 еллык юбилеен мәшһүр галимнең якташлары – әтнәлеләр башлап җибәрде.

15 гыйнварда – Мәрҗанинең тууына 180 ел тулган көнне – Әтнә районы җитәкчеләре, укытучылар һәм укучылар Казанга килеп, Шиһабетдин хәзрәт каберен зиярәт иттеләр, аңа чәчәкләр куйдылар.

16 гыйнварда Мәрҗанинең туган төбәгендә – Әтнә районының Комыргуҗа урта мәктәбендә тарихчы-галим, философ, мәгърифәтче һәм дин эшлеклесе Ш.Мәрҗанинең юбилеена багышланган фәнни-педагогик конференция үткәрелде. Конференциягә Казаннан олуг галим нәселен дәвам иттерүче Мәрҗани варислары – дүртенче, бишенче һәм алтынчы буыннар (барлыгы 12 кеше), Мәрҗаниләр нәселенә кияү тиешле әдип Әмирхан ага Еники махсус чакыру буенча килгән иделәр.

Конференциядә төп докладны Татарстан Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Раиф Мәрданов сөйләде. Ул Татарстан Милли китапханәсендә тупланган Мәрҗани мирасы белән таныштырды, 1915 елда чыккан "Мәрҗани" исемле китап турында тәфсилле мәгълүмат бирде, олуг галимнең бай китапханәсенең тарихына тукталды. Р.Мәрданов Комыргуҗа мәктәбендәге Мәрҗани музеена китаплар бүләк итте. Төркиядә "Әхмәт Вәли Мәңгәр вакыфы" нәшер иткән "Мөстәфадел-әхбар..." китабының 2 томлык репринт басмасы Мәрҗани якташлары өчен аеруча кыйммәтле бүләк булды.

Әтнә районының хакимият башлыгы урынбасары Люция Әхмәтҗанова: "1998 ел – районыбыз өчен Мәрҗани елы", – дип белдерде һәм җирле идарәнең бу җәһәттән эшләнәчәк эшләре белән якыннан таныштырды. Мәрҗанинең дөньяга килгән авылы – Ябынчыда галимнең туган нигезенә истәлек ташы куелачагы һәм Әтнәдә Мәрҗани исемендәге тарихи һәм этнографик төбәк музее оештырылуы турында әйтте.

Мансур ТИМЕРБУЛАТОВ.
Әтнә районы.

"Майкрософт" татарча сөйләшергә җыена

Моңарчы Американың "Майкрософт уиндоуз" компаниясе чыгара торган кампитрларда Русия Федерациясе субъектлары халыклары телләрен "санлау" каралмаган иде. Моннан ары "WINDOWS NT" челтәрле популяр операция системасына татар теле буенча да махсус программа кертеләчәк. Әлеге яңалыкны кертүдә иң мөһим рольне татар диаспорасының киң тармаклы булуы хәлиткеч роль уйнады.

Татар телен дөньяның кампитр системасына кертү мәсьәләсе, мәгълүм ки, II Бөтендөнья татар конгрессында да күтәрелгән иде. Латин имлясына күчүебез монда бер вариант буларак каралды. "WINDOWS NT" операция системасына кириллица яки латин язуы кертелерме – бу кадәресе әлегә мәгълүм түгел.

Җавап-савап

Татарстанның үз алтын запасы булачак, дип ишеттем. Шул дөресме?
Ш.ЯХИН.

Дөрес. Декабрь башында Татарстан милке булган беренче алтын партиясе "Заречье" коммерция банкына саклауга тапшырылды. Алтын запасы әлегә 49 килограмм гына. Алга таба да республикага алтын керә торачак. Ул промышленность тауарлары җитештергән өчен алына. Үз чиратында, бу инвесторлар өчен гарантия булып та хезмәт итәчәк.

* * *

Җирле администрация башлыкларының кайсысы елына иң күп керем ала? Безнеке түгелме икән?
Р.САБИРОВ.
Әлмәт.

Сезнеке түгел әлегә. Президент каршындагы дәүләт хезмәткәрләре департаменты мәгълүматлары буенча, сезнең якташыгыз икенче урында. Әлмәт районы һәм Әлмәт шәһәре хакимияте башлыгының декларация буенча еллык кереме 102 млн. 552 мең 387 сум. Беренче урында Әтнә районы администрациясе башлыгы Габделәхәт Хәкимов тора. Аның еллык кереме 207 млн. 948 мең 730 сум тәшкил итә. Лидерларның өченчесе Түбән Кама районы һәм шәһәре администрациясе башлыгы Әгътәс Галиәхмәтов (68 млн. 99 мең сум).

("АиФ")

"Кызыл әтәч" Кизгелекне аңламый

12 гыйнварда Иске Аракчино бистәсендә көндезге 3 сәгать тирәсендә "Ханов йорты"нда янгын чыкты. Укучыларыбызга мәгълүм рәссам Илдар Ханов дөньядагы 5 төп динне кабатланмас бер архитектура ансамблендә сынландырмакчы. Автор уенча, әлеге корылмада һәр диннең үз гөмбәзе булырга тиеш. Нәкъ менә шул гөмбәзләрдән дүртесе, аңсамбльне бизәп, күтәрелгәч кенә, бәла-каза килеп чыга.

Янгын монтаж эшләрен алып барганда башлана. Эретеп ябыштыручы калай кисәндә чәчрәгән очкын пенопластка төшә. Яна башлаган пенопласт тамчылары, өй түбәсен тишеп, икенче катка – буяулар һәм төзү кирәк-яраклары саклана торган бүлмәгә тама. Канатларын 15 квадрат метр мәйданга җәйгән "кызыл әтәч"не 6 янгын сүндерү машинасы бер сәгатьтә авызлыклауга ирешә. Бәхеткә, йортның тышкы ягына зыян килмәде. Рәссам янгын сүндерүчеләргә рәхмәт әйтте, ә тегеләре рәссамга газ аппаратлары белән эшләгәндә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен төгәл үтәү кирәклеге турында кисәттеләр.

Яшен ташы булып яусәләр

Татарстан Республикасының Мәгариф, Сәламәтлек саклау министрлыклары һәм республиканың медицина профилактикасы үзәге мәктәпкәчә учреждениеләрдә балаларны физик тәрбияләү һәм гигиенага өйрәтү буенча үткәрелгән республика смотр-конкурсына йомгак ясады.

Шәһәр балалар учреждениеләре арасында беренчелек Казаннан 106 нчы ясле-бакчага бирелде. Авыллар арасында Түбән Кама районының Кама Аланы бистәсендәге "Айгөл" балалар бакчасына тиңнәр табылмады.

Мәгариф министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, соңгы җиде ел эчендә ясле-бакчаларда тәрбияләнгән нарасыйлар арасында авыручы балалар ике мәртәбәгә диярлек кимегән икән.

Салым полициясе күз-колак булырга чакыра

Федераль салым полициясе хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсендә гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләүчеләр өчен махсус телефон булдырылды. Хәзер республикада яшәүчеләр, Казандагы 75-43-45 номерын җыеп, салым полициясенең дежур хезмәткәренә "Федераль салым полициясе органнары турында"гы Закон нигезендә салым полициясе хәл кыла торган сораулар белән мөрәҗәгать итә алалар. Салым полициясенең бурычлары:

– салым буенча җинаятьләрне, хокук бозуларны ачу, кисәтү һәм булдырмау;

– дәүләт салым инспекцияләре эшчәнлегенең иминлеген тәэмин итү, аларда эшләүчеләрне хезмәт вазифаларын үтәгәндә һәртөрле каршы торулардан, кул сузулардан саклау;

– салым органнарында ришвәтчелекне кисәтү, ачу һәм булдырмау.

Телефон тәүлек буенча эшли.

Реплика

Көлке көлә килә, артыңнан куа килә...

"Шәһри Казан" гәзитенең 1998 ел, 14 гыйнвар санында басылып чыккан каһкаһәле юллар йөрәгемне үткен пычактай телеп алды.

Әйе, безнең барыбызга да уртак кайгы килде: Иске Аракчино бистәсендә рәссам Илдар Хановның манаралы-гөмбәзле әкияти йортының бер өлеше янды. Ут эчендә рәссамның күп еллык хезмәте – гомере буе иҗат иткән зур-зур рәсемнәре көлгә әйләнде. Гаҗәеп тирән фәлсәфәгә ия "Апокалипсис", "Ленин һәм революция", "Аппассионата", "Хиросима", "Кешелек учагы" һәм күп кенә башка әсәрләре эзсез вәйран булды! Бу сүзләрне язуы да шулкадәр авыр. Ә менә шул вакытта, кешенең кайгысына сөенгәндәй, читтә көлемсерәп торулар бигрәк тә күңелне сыкрата. Кемнән көләбез, нәрсәгә сөенәбез? Бу бит Ханов йорты түгел, безнең милли хәзинәбез, дөнья хәзинәсе янды.

Күрәчәге булгандыр инде, бик зур бәһаләр тәкъдим итеп карасалар да, рәссам әлеге әсәрләрен сатмаган, аларның туган илдә, туган җирдә саклануын теләгән. Шундый хәвеф буласын кем белгән бит, кем белгән?..

Илдар Ханов үз йортын Аракчинодагы рухи һәм мәдәни учакка әверелдермәкче. Хыялы өле кайчан тормышка ашар?

Уйлап кына карагыз, хәзер бик күп урыннарда, авыл, бистә, район үзәкләрендә, яңгырдан соң чыккан гөмбәләрдәй, сыраханәләр, рестораннар үрчи башлады. Ә бит музей, күргәзмә заллары, сәнгать мәктәпләре күзгә күренеп кими, яисә бөтенләй җан тәслим кыла. Нигә соң үзен зыялылар кавеменнән санаучы бу автор без – татарстанлыларның уртак кайгысыннан көлә. Әллә ул сыраханәләрне рухи көгъбәләргә караганда кирәклерәк, дип саныймы икән?!

Мария ИЛЬИНА,
сәнгать белгече.

Гүзәлнең гүзәл җиңүе

Казан укучысы Гүзәл Хәмидуллина, Санкт-Петербург каласында Русиянең яшь башкаручылары арасында үткәрелгән "Невская лира-98" эстрада җыры фестивалендә катнашып, Гран-при иясе булды. Әлеге бәйгедә 5тән алып 17 яшькәчә булган җырчылар көч сынаштылар. Фестивальнең оештыру комитетыннан алынган мәгълүматларга караганда, якташыбыз әлеге конкурсның йөзек кашы буларак кабул ителгән.

Гүзәлебез Юдино бистәсендәге тимерьюлчылар мәдәният сараеның музыка студиясендә шөгыльләнә, 152 нче мәктәпнең 11 нче сыйныфында укый.

Шүрәлеләр безгә баккан

Үзешчән рәссам-дизайнер Ренад Галимуллин дистә еллар дәвамында Г.Тукай шигырь-поэмалары геройларына багышлап агач тамырларыннан юнып эшләгән әсәрләрен Татарстан Берләштерелгән дәүләт музеена бүләк итте. Нигездә Шүрәле образын гәүдәләндерүче әлеге әсәрләр – үзешчән рәссамның озак еллар дәвамында эзләнү-табышлары нәтиҗәсе. Г.Тукайга булган мәхәббәтен ул Татарстан телевидениесе аша күрсәтелгән "Тукай минем йөрәгемдә", "Тукай әкиятләренә сәяхәт" дип исемләнгән телевизион спектакльләр аша да тамашачыларга җиткергән иде инде. Әлеге хезмәтләрендә рәссам агач тамырларыннан эшләнгән Шүрәле, Су анасы, Шомбай һәм башка образларны җанландыра алды. Бер караганда, гап-гади агач тамырлары, ботаклар кебек кенә күренгән әйберләр аша Тукай тудырган образларны сөйләтте, хәрәкәткә китерде. Г.Тукайның 110 еллыгы уңае белән рәссамның шагыйрь музеена (Казан) тапшырган әсәрләре кебек үк, Татарстан дәүләт музеена тапшырган композициясе дә тамашачылар күңеленә хуш килерлек.

• Р.Галимуллин Шүрәлеләре белән.

ВАКЫЙГАЛАР, ЯҢАЛЫКЛАР турында хәбәр итү өчен телефон: 32-60-11

– Башкортстан җитәкчелеген еш кына "башкортлаштыру"да гаеплиләр: хакимият органнарында башкортлар саны республикадагы халыклар арасындагы башкортлар проценты белән чагыштырганда күпкә артык...

– Хәзер шундый вакыт – гаепләү өчен сәбәп күп. Бездә авыл халкының күпчелеге – татарлар һәм башкортлар. Шуңа күрә андагы хакимият органнарында шул халык вәкилләре чынлап та күбрәк. Промышленность предприятиеләрендә урыслар күпчелекне тәшкил итә.

– Урысларның саны республика Министрлар кабинетында һәм парламентта да чагыштырмача аз бит...

– Парламент белән, беләсезме, ничегрәк килеп чыкты... Бездә субъекттан (республиканың административ районыннан) ике депутат сайлана. Республикада 54 авыл районы бар. Шуңа күрә, урыс булмаган депутатларның күбрәк сайлануы бик тә табигый. Ә ни өчен әле аларның барысы да урыс булырга тиеш ди?

– Уфада урыслар шәһәр халкының 57 процентын тәшкил итә, ә шәһәрнең җиде районындагы хакимият башлыкларының өчесе генә урыс. Шәһәр мэры – татар...

– Монда яшерен нәрсә юк. Бу – махсус эшләнгән нәрсә: максаты – Башкортстан һәм Татарстан союздаш республика була алмасын. Ләкин без хәзер мәсьәләне болай куймыйбыз. Әгәр исәпли башласак, Чиләбе өлкәсе территориясенең яртысын чиста башкорт авыллары алып тора. Ырынбур өлкәсендә дә шул ук нәрсә күзәтелә. Ләкин, минем уемча, бу мәсьәләне куертырга ярамый.

– Читтән күзәткәндә, Башкортстанда үзгәрешләр Русиянең башка регионнарына караганда акрынрак темплар белән баруы күзгә ташлана. Мәсәлән, промышленность предприятиеләренең 95 проценты дәүләт милке булып калды, колхозлар тулаем саклана, күп кенә авыл советлары өстендә элеккечә кызыл әләмнәр җилферди. Башкортстандагы тормыш итү рәвеше илнең башка регионнарыннан аерылып тора, дигән фикер белән килешәсезме?

Мортаза РӘХИМОВ,
Башкортстан Президенты:

БЕЗДӘ ТӨП ХАЛЫКНЫҢ БЕР ӨСТЕНЛЕГЕ ДӘ ЮК

– Без кешеләрне эшлеклелек сыйфаты буенча бәялибез. Монда процентлар турында нинди сүз булуы мөмкин. Бу – бик үк әдәпле сорау түгел. Без элек "Ник бөтен урыннарда урыслар утыра?" дип сорамый идек бит. Хәзер заманнар үзгәрде. Без, киресенчә, милли мәктәпләр ачабыз – кешеләрне ана телен өйрәнергә мәҗбүр итәбез. Бездәге мәктәпләрдә укыту 13 телдә алып барыла. Бу начармы әллә?

– Мондагы урысларның кайберләре әңгәмә вакытында аларның балаларына көчләп башкорт теле өйрәтәләр, дип сөйләделәр...

– Беркемне дә мәҗбүр итмибез. Юк сүз. Ә ник әле урыслар башкорт телен өйрәнмәскә тиеш? Элек Русиядә теләсә нинди инженер бөтен телләрдә дә сөйләшә белергә тиеш иде. Урыслар, киресенчә, үзләре яшәгән илнең телен балаларына өйрәтергә тиешләр. Шуңа күрә бездә "башкортлаштыру бара", дип сөйләү хакыйкатькә туры килеп бетми. Мин милли вәкилчелекне тигез пропорциядә гамәлгә кертергә тырышам. Кызганыч ки, бу без теләгәнчә барып чыкмый. Бездә башка заман бит инде... Элек партия обкомында татарларны башкорт дип яздыралар иде: чөнки квалификацияле милли кадрлар кирәк иде, андый кадрлар юк иде. Шуңа күрә хәзер, хакимият структурасында татарлар аз дигәндә, чынлыкта хәлнең ничек булуын аңларга була.

– Сез, Мортаза Гобәйдуллович, үзегезнең бер чыгышыгызда Башкортстан һәм Татарстан конфедерациясе төзү мөмкинлеге турында әйткән идегез...

– Бик мөмкин, тора-бара конфедерация дә төзербез. Безнең телебез дә, мәдәниятебез һәм традицияләребез дә уртак... Ниндидер аерымлыклар элек тә булгандыр. Без – күчмә халык, алар – игенчеләр, утрак тормышта яшәгәннәр. Гомумән алганда, безнең бар нәрсәбез дә уртак.

– Әгәр Татарстан һәм Башкортстан конфедерациягә берләшсә, ул чакта башка проблемалар килеп чыгуы да бар. Бер чыгышыгызда сез Казакъстан белән Башкортстанны нибары берничә дистә чакрым ара аерып торуы белән беркайчан да килешә алмавыгыз турында әйткән идегез...

– Гомумән алганда, Ырынбур өлкәсе чикләре (Башкортстанны Казакъстаннан шул аерып тора) ясалма сызылганнар. Бу киртәне ике төрки халык үзара турыдан-туры аралаша алмасын өчен корганнар,

– Безнең авыллар бөтенрәк. Бездә авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме ел саен арта бара. Шул ук вакытта без колхозларны үзгәртеп кору буенча актив эш алып барабыз. Авыл реформасы дигән нәрсәне акрынрак алып бару хәерле – оптималь вариант эзләү ягында без. Акыллы, уңган хуҗа башта яңа йорт өчен фундамент сала, аннары гына иске йортын сүтә башлый. Бездә тормыш шартлары нормаль. Авылларга газ кертәбез, яңа йортлар салабыз. Авылны үзгәртеп коруны без башкачарак үткәрәбез: башка регионнардагыча бер көн эчендә барысын да җимереп ташламыйбыз. Сез китергән саннарга килсәк, алар бөтенләй дөрес түгел. Бездә һәр җирдә предприятиеләрне акционерлаштыру үткәрелде. Алар безнең үз кануннарыбыз буенча үтте. Предприятиеләр элеккечә идарә ителә. Барлык предприятие җитәкчеләре Министрлар Кабинеты белән килешү төзеделәр.

– Димәк, предприятиеләр, өлешчә булса да, элеккечә дәүләт күзәтүе астында калды?

– Әлбәттә. Башкача ярамый да!

– Республикада оппозицион гәзитләр, партияләр юк. Алай гына да түгел, эш урынында кешеләр Рәхимовны мактап сөйли, өйдә – шуның киресе. Мин моңа үзем шаһит булдым. Алар, минемчә, ачыктан-ачык дөресен сөйләүдән курка...

– Миннән нигә куркырга? Моны хөрәсән ялкаулары гына сөйли. Бездә 250 иҗтимагый оешма теркәлгән, теләсә кайсысы үз гәзитен чыгара ала. Турыдан-туры мыскыллау – икенче нәрсә. Мәсәлән, әйтик, "Профиль" минем турыда язып чыккан иде – мин шундук судка бирдем. Суд минем яклы булды. Яки менә Аринин (Дәүләт Думасы депутаты) минем турыда язып чыкты. Мин аны да судка бирдем. Бездә оппозиция бармы икән соң? Әйе, бардыр... бәлки.

– Юк ул. Республикада сезне ачыктан-ачык тәнкыйтьләп чыгучы кешеләр булмавын ничек аңлатасыз?

– Бездә тотрыклылык хөкем сөрә. Театрлар, мәктәпләр эшли. Чиркәүләр, мәчетләр төзибез. Һәркайда – дисциплина, тәртип. Күрше регионнар белән чагыштырганда, җинаятьчелек 3-4 мәртәбә кимрәк. Мин мафиоз эшчәнлекне, икътисади җинаятьләрне кискен рәвештә тыям. Үзем гадәти генә фатирда яшим. Минем бернәрсәм дә юк: дачам да, машинам да, самолетым да. Ә болай... Сораулар булуы мөмкин, әлбәттә. Хәзер заманы шундый.

Игорь РОТАРЬ.
("НГ").

Җавап — сорау

Ике бүлмәле фатирда хосусыйлаштырылган бүлмәм бар. Биредә теркәлгән булсам да мин анда яшәмим. Шул бүлмәгә кемнедер фатирга кертә аламмы?

С.ӘМИНОВ.

Әйе, фатирга кертә аласыз. Торак бинаны вакытлыча наемга биреп тору РФ Гражданнар кодексындагы 671-688 нче маддәләр белән каралган. Бу килешү гади гариза язу юлы белән эшләнә.

Хәрби пенсионер гаиләсе фатирын хосусыйлаштырды. Бу очракта хәрби пенсионерга бирелгән фатирны тоту һәм коммуналь хезмәтләр өчен ташламалар үз көчендә каламы?

С.ГАРИФУЛЛИН.

Татарстан Республикасының "Татарстан тулай торак фондын хосусыйлаштыру турында"гы Законындагы 20 нче маддә нигезендә хосусыйлаштырылган торак биналарны тоту, ремонтлау һәм көнкүреш хезмәтләре (җылылык, электр энергиясе, газ, су һәм канализация) күрсәткән өчен тотыла торган чыгымнар ул бина (фатир) хуҗалары тарафыннан дәүләт һәм коммуналь торак фондларына куелган бәяләр күләмендә түләнә. Дәүләт тарафыннан бирелгән ташламалар саклана. Инвалидларга, сугыш ветераннарына һәм аларга тиңләштерелгән кешеләргә, хезмәт инвалидларына, сабый чактан ук инвалид булган һәм картлык буенча пенсия алучыларга, дәүләт бурычын үтәгәндә һәлак булганнар гаиләсенә, өч һәм аннан артык балалары булган гаиләләргә, милек формасының нинди булуына карамастан, йортны тоту, ремонтлау өчен тотылган ташламалар күләме Татарстан Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Мин үзем пенсиядә инде. Фатирымны кызым белән бергә хосусыйлаштырган идем. Бер ай үтүгә, кызым башка урында яши башлады. Ә миннән аның өчен салым таләп итәләр.

Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА.

Салым түләү теркәү (прописка) белән бәйләнмәгән. Салым билгеле бер милектәге өлеш өчен салына. Салымны кызыгыз өчен алулары дөрес.

Мин кызыма фатир сатып алдым. Үзем башка шәһәрдә яшим. Фатирны нотариус аркылы үз исемемә яздырдым. Кызым кайтып яши башлаганчы нинди салым һәм нинди коммуналь хезмәтләр өчен түләргә тиешмен икән?

Х.ДАЛОТКАЗИНА.

Фатир – сезнең милек. Инвентаризациядән соң билгеле булган сумманың 0,1 проценты күләмендә сез милек салымы түләргә тиешсез. Шулай ук фатирга техник хезмәт күрсәткән һәм җылылык өчен ЖЭУ белән төзелгән килешү буенча тиешле күләмдә акча түләргә тиеш буласыз.

Ике бүлмәле фатирда күрше белән яшим. Күптән түгел ул кияүгә чыкты. Ул күршем минем рөхсәтемнән башка ирен пропискага кертә аламы?

З.КӘРИМУЛЛИНА.

Соравыгыз буенча, сезнең күршегез белән икегезнең дә торакны наемга алу турында килешүләрегез аерым, ягъни һәр күршенең дә лицевой счетлары аерым төзелгән. РФ торак кодексының 54 нче маддәсе буенча, фатирда торучы үз торагына ирен, балаларын, әти-әнисен һәм туганнарын, үз гаиләсендәге балигъ булган кешеләр рөхсәте белән, закон тәртибендә пропискага кертә ала. Әти-әниләргә балигъ булмаган балаларын теркәү өчен беркемнән дә рөхсәт кирәкми. Шулай итеп, күршегез үз ирен сездән рөхсәт сорамыйча да пропискага кертә ала.

Тузган, искергән торак исәбенә кертелгән коммуналь фатирны хосусыйлаштырып буламы?

Г.САДРИЕВ.

Татарстан Республикасының "Торак фондны хосусыйлаштыру турында"гы Законының 5 нче маддәсе нигезендә тулай тораклардагы бүлмәне, махсус һәм ябык хәрби шәһәрчекләрдәге, шулай ук искергән һәм җимерелергә торган йортларны хосусыйлаштыру каралмаган. Иске йортта барлык яшәүчеләрнең рөхсәте белән йортны хосусыйлаштыруга рөхсәт алынса, бу йорт иске йортлар исәбеннән төшерелә. Фатирларны гражданнарның хосусый милкенә әйләндерү гомуми нигездә башкарыла.

("Око" агентлыгы).



Диас ВӘЛИЕВ

ҖИҢЕЛҮ

Газитләрнең бәйрәм саннарын яратмыйм. Андый саннарда уйдырма һәм ялагайлык, ялган оптимизм һәм мәгънәсез юмор тулып ята. Ә ул төче мәкаләләрнең теленә игътибар итсәңме?! Бал да май инде менә, бал да май! Менә шуңа күрә дә, Яңа ел алдыннан язган бу мәкаләмдә мин үземә әнә шул бал-май мичкәсенә бер кашык дегет тә салып кую хокукын калдырдым. Ә ул бер кашык дегетсез мөмкин дә түгелдер. Һәм, җитмәсә, юлбарыс әзрәк ырлап та куйгаларга тиеш бит әле!

Әйе, мин юлбарыс елында туганмын. Әйе, бу елда миңа 60 яшь тула. Уйландыра торган вакыт бу һәркем өчен. Кем әйтмешли, гомерләр узып бара, ә кайда соң әле аның җимешләре-бүләкләре? Юк алар, күренмиләр, гомер йомгагының нәтиҗәсе дә, кызганыч ки, шатлык-сөенечләрсез. Тагын шунысын аңлап-күреп торуы аяныч: үз гомереңнең азагы зур бер дәүләт гомере азагына туры килүе дә фаҗига икән бит әле!

Бу дәүләттә, бу илдә булган хәлләр миңа беркайчан да ошамый иде. Әмма 1991 елдан соң башланганнары исә бернинди акылга да сыймый, бернинди мәгънә калыбына туры килми. Үзеңнең ни дәрәҗәдә көчсез булуыңны әнә шул хәлләр аша тоясың, әнә шул көчсезлек җаныңны үрти, изә. Дөрес, мин Казан һәм Мәскәү матбугатында үз сүземне, фикеремне әйтеп илле-алтмыш мәкалә язып чыктым, публицистик китаплар бастырып чыгардым. Әмма аннан ни файда? Ялгыз бер бәндәнең бушлыкка кычкыруы нәрсә соң ул? Синең әрнүле тавышың комга сеңеп барган су кебек юкка чыга – үзе дә юк, эзе дә калмый. Халык, әйтерсең, мәрткә киткән, йоклый-йокымсырый. Һәм аның шушы халәттән чыгарга исәбе дә күренми, моңа әзерлеге дә сизелми.

Кайчак уйлап та куям: ни өчен генә заманында хәрби хезмәткә китмәдем икән? – дим. Кем белә, бәлки генерал булыр идем, кул астымда Ватанга чын күңелдән бирелгән офицерлар һәм солдатлар, көчле һәм нык бер дивизия булыр иде. Ә бит бүгенге көндә мәсьәләне, хәтта сүз генә дә түгел, нинди дер бер яңгыравыклы тавыш хәл итә түгелме соң? Кайчак вакыйгалар барышын көтелмәгән бер бәрелеш, һөҗүм үзгәртә дә куя. Әмма... язмыш хәтта монысына да мөмкинлек бирмәгән.

Каләм ияләре, язучыларның көче юк дәрәҗәсендә. Алар юл читенә чыгарып ташланган, юлның иң читенә.

Бүген мине шундый бер хис – җиңелү һәм оттыру хисе әзәрлекли. Иреннәрдә – бетмәс-төкәнмәс ачы сагыш-борчылу тәме. Ни гаҗәп, ертлач һәм ялагай әдипләр, нинди дер бер төркемдәге әдипләр һәрчак әйбәтрәк яшәделәр, алар бәхетлерәк тә, сәламәтлекләре дә ныграк. Аларның күңелендә мондый күңелсез уйлар, борчылулар туа алмый. Намусы кушканча яшәгән -язган әдипнең хәле шактый авыррак. Гадәттә, нәкъ менә алар җиңелүгә дучар. Мин үземне намус кушканча яшәдем дип уйлыйм. Менә, алтмыш яшемә килеп җиткән бер вакытта үземнең җиңелүләремне, җиңелүләремнең кайберләрен санап чыгам.

Әйтик, драматургиядә. Әйе, нәрсәдер эшләнгән-язылган: ун пьесам бар. Араларында шәпләре дә бар, дип уйлыйм. Шуннан нәрсә? Мине драматург буларак юк итү өчен әдәбият тирәсендә бөтерелүче гангстерлар унбиш ел буена көч түкте. Алар минем исемемне илнең, республиканың театр афишаларыннан сызып-йолкып ташладылар. Аяныч, әмма бу – факт. Әмма әлеге фактның иң аяныч ягы шунда: мин инде үзем үк бу хәлләргә күптән кул селтәдем. Инде килеп, проза жанрын алыйк. Әйе, бу өлкәдә дә язганнарым шактый. Дөрес, ике романым һәм тугыз хикәям әлегә басылып чыкмады. Шулай ук, шактый уңышлы әсәрләрем бар прозада. Йә, шуннан нәрсә? Кем белә, кем укыган ул әсәрләрне? Миллионлы шәһәрдә шул өч- дүрт кеше беләдер.

Фәлсәфәне дә мисалга китерик. Бу өлкәдә дә байтак нәрсәм басылып чыкты. Мәсәлән, шактый үзенчәлекле, шактый киң пландагы фәлсәфи система тудырдым, анда зур-зур фикерләр әйтелде, бу фикерләр әле моңарчы дөнья әдәбиятында күренмәгән иде. Нәтиҗәсе нәрсә? Әнә, китап эчләрендә күмелеп ята алар. Ун-унбиш кеше танышкандыр алар белән, күп дигәндә. Бер-ике кеше аңлагандыр аларны, әгәр төшенгән булса. Кайчанга тикле эзсез-күзсез ятар икән ул фикерләр? Йөз елмы? Әллә ике гасыр буенамы?

Биш ел элек – инде биш ел үтеп киткән – мин беренче булып яңа, бөтен дөньяга уртак бер дин тудыру идеясен игълан иттем, әлеге диннең төп нигезләрен язып чыктым. Яңа дини системаның төп кануннары турында ике китап чыгардым. Дөньяда һәр нәрсәнең тарихи яшәү вакыты чикләнгән. Бу канун дөньядагы диннәргә дә кагыла. Ул диннәр ничек кенә нык һәм көчле булып тоелмасын, алар барыбер сүнәргә-сүрелергә тиеш. Ул диннәрне инде бүгенге заман шартларына тулырак җавап биргән дини кыйммәтләр алыштырачак. Әмма безнең Татарстан ул – дөнья диннәрен тудырган Һиндстан да түгел, Палестина да, Гарәбстан да түгел. Ул илләрдә дини геннар һәр кешенең җанына беregeп үскән. Ә бездә дин өчен җирлек янып каткан балчыктан, салкын балчыктан гыйбарәт. Белмим, яңа бер дин гөле күккә үрләсен өчен тагын ниләр генә кирәктер? Әлеге яңа дини тәгълимат мәсьәләсендә дә мин җиңелүгә, аяктан еккыч җиңелүгә дучар.

Заман язучыларга тагын бер җитди сынау – хәерчелек белән сынау алып килде. Без бу хакта сөйләргә дә кыенсынабыз. Ә нәрсәсеннән кыенсынып торырга соң әле?! Хәерчелек – реаль күренеш.

1996 елның бер көне хәтеремә уелып калган. Җомга көн иде ул. Үлем түшәгендә яткан әнием янына участок табибы килде. Авыруны карагач, миңа әйтте: әни йә шимбә көнне, йә якшәмбе көнне җан бирәчәк икән. Табиб киткәч, мин язу өстәленең тартмасын ачтым, калган-булган акчамны санадым. Тартмада егерме сигез мең акча бар икән. Егерме сигез мең – туксан алтынчы ел акчасы! Балаларның да акчасы юклыгын белә идем. Нишләргә? Ничек җирләргә соң әнине? Ә бит акча иртәгә үк кирәк булачак. Язучылар берлеге идарәсенә шалтыраттым, хәлемне аңлаттым. Бераз гына булса да матди ярдәм күрсәтмәсләрме дигән өметем бар иде. Яшәр-ашар өчен түгел, әнине җирләү өчен кирәк бит. Рәисебез җавап бирми торды, аннан соң әйтте: "Соң; Диас Нәзихович, менә мин әтиемне җирләгәндә Язучылар берлегенә мөрәҗәгать итмәгән идем".

Хәзерге профессиональ-язучы тормышыннан алынган бу гап-гади мисал кем өчендер, бәлки, көлке бер хәл булып тоелыр, көлеп ләззәтләнү теләге уятыр. Алла хакы өчен – рәхим итсеннәр!

Бүгенге язучының тормышыннан барлык таяныч-юанычлар юкка чыгып бара. Әле элегрәк азмы-күпме булыша алган Язучылар берлегенең ярдәме юклыгын әйтеп тә тормыйк. Иң аянычы – илнең тере сулышын тою юк, чынлап та юк ул сулыш. Язучы таяна алырлык халык юк, ул инде шәхес булган халыктан ярым тере бер биологик матдәгә әйләнде. Әнә,"дөнья массоннары" аның хәзер милли төсмерен дә тартып алмакчы. Язучының хәзер үз укучысы да юкка чыкты, бушлыкка төшеп батты, кем әйтмешли, ай күрде дә кояш алды аны.

Бүгенге язучы, әгәр ул нинди дә булса төркемгә хезмәт итми икән, ялгызлыкка һәм мохтаҗлыкка хөкем ителә, мескен гомерен азмы-күпме сузу өчен генә көрәшә. Хат алышу хокукы юк – конверт алырга акчасы җитми, информациягә хокукы юк – гәзит-журналга язылырга акчасы булмый. Хәтта юл йөрергә дә акчасы юк бит аның. Монысы нәрсә, яшәгән урыныңнан рөхсәтсез чыкмау турындагы кисәтүгә кул куюмы?

XX гасыр – кешегә карата һәм, шул исәптән, иҗат кешесенә карата төрледән-төрле эзәрлекләүләр күрсәткән гасыр.

90 нчы елларда Русиядә репрессия эзәрлекләүләренең янә дә бер төре, бик тә хәйләкәр төре калкып чыкты. Монысы – кешенең шәхси тормышын хәерчелеккә салу. Кешене нигә әле, төрмәгә тыгып, аны ашату, сак астында тоту өчен акча әрәм итәргә ди?! Бүгенге режим кешене, язучыны болай да үз өендә үк тоткын рәвешенә китереп куя. Бик тә "кешелекле" ысул бу. Сталин заманнарындагы тупас эзәрлекләүләр белән чагыштырып булмый инде, ни генә әйтсәң дә! Кемдер әйтер, арттырыбрак җибәрәсең, дияр. Хәзер бит ирек заманы, дияр. Юк, ирек заманы мондый булмый. Минем, мәсәлән, бик кирәк чакларда редакцияләргә дә бара алмый калганым бар. Сәбәбе шул: трамвайга акчам юк иде.

Кесәсендә зур акчалар кыштырдаган агай-энегә, мөгаен, минем бу сүзләремне ишетү бик рәхәттер. Рәхим итегез! Сезнең күңелдәге ул ләззәтне тагын да арттыра алам. Менә шундый бер гап-гади, вак кына, еларлык та, көләрлек тә бер хәлне сөйлик: Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (ул уенчыкларны миннән кире алыгыз, аларның һичбер әһәмияте юк), инде шактый өлкән яшьтәге кеше, соңгы елларда гына Аллаһы ярдәме белән тугыз китап чыгарган автор (димәк, ул үзе ялкау да түгел икән бит әле) трамвайда "куян" булып бара, мескен булып, бәйләнчек контролерлар килеп тотмасын дип, оялып һәм дер калтырап йөри.

Бүгенге режимга, мөгаен, иҗат кешесенең нәкъ менә шундый хәлдә булуы әйбәтрәк. Без режимга, мөгаен, композиторны яки язучыны аяк астына салып таптау, аны рухи яктан кимсетү һәм имгәтү өчен кирәк. Элекке вакытларда трамвай билеты өч тиен тора иде. Өч тиен акчасы булмау хәленә китереп җиткерү кирәк бит язучыны, ә!

Ярар, кадерле хөкемдарлар-хакимнәр, таптагыз безне, иҗат кешеләренә карата алып барылган "бөек" репрессияләрне дәвам итегез. Бу традиция кичә генә башланган нәрсә түгел, әле иртәгә генә дә бетмәячәк. Сез хөкүмәткә кереп урнашкан чит ил разведкалары агентларына, димәк, үз-үзегезгә баш җитмәс күләмдә гонорарлар түлисез. Сатлыкҗаннарга, Ватанны җимерүчеләргә түлисез сез аны! Шулай булгач, илне-тормышны тергезергә тырышучылар өчен акчагыз юк.

Һәм без, язучылар, шушы шартларда "үлемсез" әсәрләр, "мәңгелек" әсәрләр тудырырга тиеш. Бары тик "мәңгелек" әсәрләрне генә. Бүтәннәреннән файда-өмет юк.

Шушы тулысынча һәм гомуми җиңелүнең, гомуми сатлыкҗанлык һәм өметсезлекнең гадәттән тыш шартларында, һәртөрле теләкләрдән ваз кичеп, беркемгә һәм бернәрсәгә дә ышанмаган хәлдә, иҗат мәгънәсен үз тормышыбыз-язмышыбыздан түгел, читтән эзләп, без инде алтыннан-алтын әсәрләр язарга тиеш, имеш. Һәм, мөгаен, без аны язарбыз да!

Зур һәм кечкенә сугышларны искә төшерик. Ахыр чиктә, ни гаҗәп, сугышта җиңгән халыклар түгел, ә бәлки җиңелгән халыклар отышта кала. Ул халыкларның йөрәгендә, әйтерсең лә, нинди дер серле көч тупланып кала, һәм аларны әнә шул көч дөньяда беренче урыннарга күтәрә дә.

Без бүген – җиңелгәннәр, мәсхәрәләнгәннәр, изелгән-кимсетелгәннәр – әлеге эчке көчне, серле көчне үз күкрәгебездә сакларга, каршылык күрсәтергә һәм шуның бәрабәренә китаплар язарга тиеш булабыздыр. Без бүген тудырган идеяләрдән, без тудырган образлардан башка өченче меңьеллыкта яшәгән халыкларга яшәү бик тә ямансу булыр. Кешелек цивилизациясе сулышсыз хәлдә. Җиңгән Көнбатышның бернинди мәгънәви фикере, идеясе юк. Көнбатыш рухи яктан ярлы һәм нәселсез.

Яшәүнең яңа идеяләре, яңа фикерләр бары тик бездә, җиңелүчеләр аңында гына туарга мөмкин. Безнең бурыч зур – үзебезне генә түгел, сазлыкка баткан кешелек цивилизациясен дә саклап калу. Яшәешнең төп вакыйгалары, хәлиткеч вакыйгалары әле алда. Һәм, шуңа күрә, җиңелүнең тын-аулак мохитендә без бертуктаусыз эшләргә тиеш. Бу эштә кыланчык-мактанчык хакимнәрдән дә, мәрткә киткән халыктан да тану-танылу көтеп торырга тиеш түгел без. Югалган яшәү асылын кабат таба барып, иҗатка тотыну кирәк.

Бу яңа елга кергәндә, юлбарыс елында туган кеше буларак, менә шундый уйлар иде минем күңелдә.

* * *

Бу дөньяда игелекне
Эзләмә дә, көтмә дә;
Изге, чиста, якты сөю
Керми хәтта төшкә дә.

Төшләрдә дә чүп-чар тулы
Чокыр-чакыр тыкрык...
Яман сүзләр, гайбәт белән
Дөньябызны тутырдык.

Гөнаһларның бу көндә үк
Күрә-күрә җәзасын,
Эчеп, череп, сүгенеп йөреп,
Татар кая бара соң?!

23 ноябрь, 1997.

* * *

И, Ходаем! Башта ярдәм күрсәт
Өен ташлап юлга чыкканга.
Ә аннан соң булыш ятимнәргә
Гарип-горабага, мохтаҗга.

Аннан килеп, ярлы-ябагайга
Ярдәмеңне күрсәт дөньяда.
Шулардан соң инде миһербанлык,
Игелегең күрсәт миңа да.

23 ноябрь, 1997.

Сабырлыкны саклау авырлашты,
И, Ходаем, үзең түзем бир.

Хәтта үзем үлчәү югалтканмын –
Явыз дисәгез дә баш тартмыйм.
Аш атканга өле таш атмыйм да,
Таш атканга инде аш атмыйм.

Тирә-юньнән ипле хәят качты
Нинди көчләр нәрсә иңдерер?
Сабырлыкны саклау авырлашты,
И, Ходаем, үзең түзем бир.

Кисәү өстәп яман ут-учакка,
Күңелләрне ыслап киптермә.
Олыларның каһәреннән сакла,
Сабыйларның яшен түктермә.

Түшне-башны борчу-сөрем басты,
Айный алмый шашып йөримдер.
Сабырлыкны саклау авырлашты,
И, Ходаем, берүк түзем бир!

22 апрель, 1997.

* * *

Ак җилкәннәр җырда җырланылды,
Ал җилкәннәр булды хыялда.
Киләчәктә күздә тотылганны
Күңел күрде зәңгәр буяуда.

Клара БУЛАТОВА

Үз җаена кайта барсы да...

* * *

Учлаплар түккән энҗеләр кебек,
Уйлар-фикерләр кала түгелеп.
Түгелмәс иде – мунчала түгел,
Кулыңа каләм алсаң иң элек.

Алар кәгазьгә теркәлер иде,
Орлык җирлеккә бер төшәр иде,
Әйтер фикереӊ югалмас иде,
Җанныкы җанга ирешер иде.

Үтә гомерең тибенне күреп,
Үз сәндерәңнән бик түбән йөреп;
Уйлар-фикерләр кала түгелеп,
Учлаплар сипкән энҗеләр кебек.

Чәчелеп кала, җыясы иде,
Кәгазьгә теркәп куясы иде...

11-13 гыйнвар, 1996.

* * *

Уразаның соңгы көне бүген,
Кичә тоттым, бүген кермәдем.
Каләм язган чәчмә әсәр өчен
Җавап тотып йөргән көннәрем.

Каһарманнар бигрәк тере чыккан -
Прототиплар үзен таныган.
Янау килә хәзер Кытмыр Гыйлаҗ
Балалары токым ягыннан.

Сүзнең көче, димәк, барып җиткән,
Адресатын тапкан.
Алай да,
Әдәбият кануннарын ничек
Аңлатасың һәрбер наданга!

8 ноябрь, 1997.

* * *

Үз вакыты белән бозы туңа,
Үз вакытында язгы шау тына -
Үз җаена ята барсы да.

Бу барышны үзгәртермен, диеп,
Алдар өмет белән ярсыма:
Үз җаена кайта барсы да...

26 февраль, 1997.

* * *

Әшәкелек хәзер баштан ашты -
Югалта бит йөзен безнең Җир!..

Көрәшләргә җаннар ашкынганда,
Кызыл җилкән керде төшләргә.
... Соңгы ярга кораб якыная –
Җилкәннәре кара төсләрдә.

1 март, 1997.

* * *

Тынгысыз җан тынлык эзли калса,
Туктый белмәс күңел туктаса,
Уяу затлар оеп йокыга талса -
Гөлбакчалар йөзен тут баса.

Ә тутыккан йөздән нур югала,
Җыр югала тынган күңелдән...
Кем, кайсыгыз чыгу юлын таба
Тутык басып килгән бу илдән?

10 март, 1997.

* * *

Дәгъваламыйм Ходай язмаганын,
Эзләп йөрмим чит-ят яклардан.
Ни бирелгән – бары шуны алдым,
Ни тиешле – шуны кайтарам.

Ходай язмаганын дәгъваламыйм,
Бирелгәнгә, шөкер, җитәрлек.
Тик Ходаем гомер бирсен иде
Бәхиллекләр җыеп китәрлек.



* * *

Төн дә утырып язам мин,
Таңнан да торып язам.
Шуның белән бер кирәкле
Эш кырыр булып янам.

Бүгенге яшәешенә
Илнең бер бәя бирәм.
Алдар хакимнәр эшен дә,
Имештер, дөрес күрәм.

Язганнарымны, янәсе
Кемнәрдер укып багар;
Укыр да, уйлап карагач,
Ниндидер мәгънә табар.

Бичара җанын шагыйрьнең
Шул өмет һаман алдый.
Тик аяныч: бик күбесе
Китапка күз дә салмый.

Ниһаять, инде сиңа да
Кирәктер төшенергә:
Шигырьгә бүген табына
Дивана кеше генә.

Комга су сибеп алданма,
Каләмең ташла, янма,
Төн дә утырып язма син,
Таңнан да торып язма...

5 гыйнвар, 1997.

* * *

Битарафлык... Ул үзеннән-үзе
Туа бугай безнең көннәрдә.
Кем ни белән яши? Ничек эшли?
Кайда йөри? Белми берәү дә.

Ялгыз карчык үлем түшәгендә –
Ишегенә килми берәү дә.
Битлек белән уңай вакыт сайлап,
Җинаятьче йөри тирәндә.

Вагоннарда кесә караклары
Куеныңа кадәр тыгыла.
Беркем күрми, яклар өчен килми,
Күргәне дә читкә борыла.

"Ни эшең бар?" "Сиңа ни калган?"нан
Гайре сүз юк кеше телендә.
"Бәласеннән башаяк", дип әнә,
Посып яши мәхлук өнендә.

Куркаклык та, мескенлек тә түгел,
Егетлек тә түгел, ирлек тә –
Битарафлык – шуннан бүтән нәрсә
Тумый бугай безнең җирлектә.

15 февраль, 1997.

Шигырь ячкәлек билгесе белән языла

МӘРҖАНИ ОНЫГЫ

Еллар бер-бер артлы үтә тора. Менә, тарихчы, олуг галимебез, фикер иясе һәм фәйләсуф ШИҺАБЕТДИН хәзрәт МӘРҖАНИнең дә туууына 180 ел тулды. Аллага шөкер, Мәрҗанинең исемен дә, хезмәтләрен дә халкыбыз онытмый, нәсел-нәсәбе дә сакланган. Мин дә бу язмамда, гомер юллары аша авыр язмышларны үтеп, әмма Мәрҗанинең затлы исеменә, данына һәм намусына һич тә тап төшермичә, нәсел чылбырын өзмичә дәвам иткән бер кеше – СУФИЯ апа МОСТАФИНА хакында сөйләргә телим

Суфия апа – Шиһабетдин хәзрәтнең оныгы Гайшә апа кызы. Гайшә апа аркылы Суфия апа тарихыбызда мактаулы, шан-шәрәфле урын тоткан Апанайлар нәселенә барып тоташа. Чөнки Гайшә апаның әнисе Хава олы хөрмәткә лаеклы, әлегә өйрәнелмәгән зур иҗат иясе Габдулла хәзрәт Апанаевның җәмәгате булган.

Тормыштагы затлы тәрбия, Ислам диненә, гореф-гадәтләребезгә тугрылык шушы ике нәселдән килсә, чишмә суларыдай саф күңеле, олы җанлы булу, авырлыкларны җиңә белү сәләте Суфия апага әтисе Абдулла Габделкәбир улы Мостафиннан күчкәндер, дип уйлыйм. Шуңа күрә дә, бу изге җан хакында берничә сүз язып китүне урынлы дип саныйм.

Абдулла Мостафин Башкортстанның кечкенә генә Сикәле Күл авылында туган. Унбер яшендә әтисе йортыннан бер ялгызы чыгып китеп, Казанга, Салихҗан хәзрәт Галиевнең мәдрәсәсенә укырга килгән. Өч ел буе мәдрәсәдә тырышып укып, үзен сәләтле, бик зиһенле, намуслы шәкерт итеп таныткан. Салихҗан хәзрәт тә аны бик яраткан, киләчәгенә зур өметләр баглаган. Өч ел үткәч, мәдрәсәгә атаклы Сембер бае Акчурин килеп төшә. Ул үзенең телсез угланына тәрбияче-мөгаллим эзли икән. Салихҗан хәзрәт, һич тә икеләнмичә, Абдулланы байга тәкъдим итә. "Синең балаңа ул яшьтәш. Абдулла аңа дус та, үрнәк тә була белер, белгәненә дә өйрәтер, алсаң, шушы шәкертне сайлап алып кит", – ди.

Хәзрәтнең ышанычын аклый яшь мөгаллим. Телсез баланы ул үзенең уч төбенә язып укырга-язарга, хисап чыгарырга өйрәтә. Алай гына да түгел, Абдулла рәсем ясарга, итек тегәргә һәм башка бик күп һөнәрләргә дә оста икән. Телсез бала өчен ул җанлы өлгегә, үрнәккә әверелә. Яшь остаздан бик тә канәгать калган байның бер дә Абдулладан аерыласы, аны читкә җибәрәсе килми. Ул егеткә сукно фабрикаларын күрсәтә, тукучылык, фетр басу серләренә өйрәтә. Ходай биргән сәләте өстенә искиткеч тырыш, һәрнәрсәне белергә омтылган Абдулла тиздән бу эшләргә дә өйрәнә. Озакламый аның уйлап табу сәләте дә ачыла. Моңарчы хатын-кызлар гына чиккән фетрларны машина белән чигү ысулын уйлап табып, ул Петербургтан патент алуга да ирешә.

Эшенә күрә хакын да түләгән бай, рәнҗетмәгән. Абдуллага өйләнер вакыт җиткәч, ул аны, аталарча киңәшләр биреп, Казанга озаткан. "Кәләшне үзеңә Казанда сайла", – дигән. Абдулла янә Салихҗан хәзрәткә килгән. Хәзрәт аңа үзенең дусты Габдулла Габделкәрим улы Апанаевның олы кызы Гайшәне димли.

Яшь гаиләне бик матур каршылый бай. Пароходтан төшүгә яхшы атлар җигелгән экипаж белән каршы алу дисеңме, яшьләргә махсус ниятләп, шәһәрчә җиһазландырылган йорт, тормыш итәргә кирәк-ярак дисеңме – барысы да әзерләп куелган була. Бу йортта Абдулла белән Гайшәнең дүрт баласы туа. Олысы – Мөхәммәт, аннан соң – Суфия, Әхмәт, Мәхмүт.

Ризыгың кайда, син шунда, ди халык мәкале. Шулай матур гына көн итеп ятканда дөньялар тынычсызланып китә. Байлар да төрлесе төрле якларга китү ягын карый. Баеп киткәч, Абдулла да 1916 елны,

гаиләсен алып, Бәләбәй шәһәренә китә, андагы күн заводына механик булып урнаша. Тик бу ыгы-зыгылы вакыт, кешеләргә тыныч кына яшәргә язмаган, дөньяның астыөскә килә.

7 яшьлек Суфиянең хәтеренә уелып калган бер хатирә – әтиәнисенең ерак басуларга алабута җыярга йөрүләре. Бервакыт шулай ата-ана алабута җыеп кайтсалар, ни күрсеннәр – балаларның берсе дә өйдә юк. Әйләнә-тирәдә инде күршеләр дә калмаган, беркемнән сорарга да юк. Ата-ананың башына тирән кайгы төшә.

Киңәшсез, рөхсәтсез генә үзләрен кем алып киткәнен Суфия хәтерләми, әмма күпме җирләр, илләр кичеп абхаз илендәге Новый Афон монастырена килеп урнашканнары бүгенгедәй исендә. Бу монастырьда ул чакта монахлар да булган.

Балаларның күбесе уку яшендә булсалар да, тәрбиячеләрнең берсе дә аларны укыту хакында кайгыртмаган. Җитмәсә, балалар арасында бизгәк, дифтерия кебек авырулар тарала. Суфиянең кече энесе дә шул авырулардан үлә.

Шулай 4-5 ел үткәч, хәсрәтнең мең дәрьясын кичеп, Абдулла белән Гайшә Новый Афонга килеп җитәләр. Очрашу шатлыгы да, улларын югалту кайгысы да – барысы да бергә була.

Балаларны алып кайтырга чыгалар. Әмма кайтып җитәрлек акча юк, Гудаут шәһәрендә туктарга мәҗбүр булалар. Гудаутта хәлле генә төрекләр, греклар да яшәп ята. Абдулланы да, Гайшәне дә алар бик ошатканнар, торыр өчен кибет складында урын да хәзерләп биргәннәр. Күп һөнәрле Абдулла монда югалып калмаган: модалы туфлиләр, читеккәвешләр теккән, төрле рәсемнәр ясаган, сәгать төзәткән.

Төрекләр үзләре белән аларны да Төркиягә китәргә кыстый башлаганнар. "Син югалмассың, Төркиядә һөнәрле кешегә яшәргә була", – дигәннәр. Әмма гомергә ата-ана хәер-фатихасын алып яшәргә өйрәнгән Гайшә апа әнисенең ризалыгын алмыйча китәргә кыенсына. Казандагы Хава апага хәлне аңлатып хат язалар. Тик совет власте органнары тарафыннан 1919 елның 15 сентябрендә үк атылган иреннән аерылган ана үзенең тормышында бердәнбер диярлек таянычы булып калган кияве белән кызына китәргә ризалык бирми.

Абдулла абый Кавказ аръягында бик билгеле партия җитәкчесе Нестор Лакобадан ярдәм сорый һәм Лакоба аларга Казанга кайтырга билетлар, ризыклар алырга җитәрлек акча биргән.

Кызганыч, Абдулла абзыйның гомере бик кыска калган була. Казанга кайтып ике генә көн торгач, эшкә урнашу нияте белән туганнары яшәгән Бирски шәһәренә китә һәм ике атнадан шунда үлеп кала.

Суфия Казанның 8 нче мәктәбендәге 3 нче сыйныфка укырга керә. Музыкага, җырга сәләте ачыла. Солтан Габәши җитәкләгән хорга йөри. Хор белән "Сания", "Эшче" опералларында катнаша. Җырлаган өчен азмы-күпме акча да бирәләр. 1930 елны Мәскәүдә үткәрелгән халык театрларының I Олимпиадасында да катнаша. Яшь кыз өчен бу искиткеч зур бәхет булып тоела. Әмма 1929 елны 6 нчы сыйныфны тәмамлаган Суфиягә гомуми белем мәктәбеннән китәргә туры килә. Берьюлы ике мәктәптә укырга рөхсәт ителми башлый. "Ә музыка мәктәбендә мин 13 сум 80 тиен стипендия ала идем. Безнең ярлы гаиләгә бу бик зур ярдәм кебек тоела иде", – ди ул. Әмма укырга, югары белем алырга да теләк бик зур бит әле. Ул, документларны күрсәтмичә генә, университетның хәзерлек курсларында укый башлый. Ике айлык курсларны тәмамлагач, керү имтиханнарын уңышлы тапшырып КДУга физика-математика факультетының астрономия бүлегенә укырга керә.

Беренче курсны тәмамлагач, академик Губкин җитәкчелегендә Татарстанның геологик картасын төзергә Әлки районына китәләр. Академик та сәләтле, тырыш кызның эшеннән бик тә канәгать калган, астрономиядән китмәскә киңәш биргән.

1930 нчы еллар романтик рухтагы яшьләрнең комсомол чакыруы буенча күпләп авиациягә килгән еллары. Суфиянең дә очасы, канатланасы килә. Авиация институты ачылуга, ашкынып шунда күчә. Диплом алды практикасын заводта үтәргә кирәк була. Практикага баручыларны махсус комиссия тикшерә. Менә шунда студент Суфия Мостафинаның әнисе Гайшә ханымның "Совет власте дошманы" Габдулла Апанаев кызы икәнлеге ачыла. Җитмәсә, "солтангалиевче" дип, абыйсы Мөхәммәт тә кулга алынган. Кызны, "фаш итеп", институттан чыгаралар. Үз язмышы да кыл өстендә булган ректор ничек курыкмагандыр, тырыш студентына ике айлык стипендия бирдертә. Суфия апа бу олы җанлы кешегә әле дә рәхмәт укый. Чөнки нәкъ шул вакытта энесе Әхмәт тә, аңа передача илткән җирдән Гайшә апа да кулга алыналар. Кайда яшәүләренә карамастан, барлык туган-тумачаларның бер-бер артлы кулга алынганнары ишетелеп тора. Тормыш куркыныч бер мәхшәргә әйләнә.

Суфияне иректә озак йөртмиләр. Барлык Апанаевлар өчен ташка тамган 58 нче статья биреп, төрмәгә утырталар. "Гомерем бетмәгәндер, бер елга якын утыргач чыгардылар тагын, – ди ул. – Мин кайтканда әни дә өйдә. Тик өй дип әйтерлек тә түгел. Зур бүлмәбезне ГПУда эшләгән бер чиновникка биргәннәр. Әни белән шулай бәләкәй генә бүлмәдә яши башладык".

Гайшә апага кем ярдәм иткәндер, ул "Азат хатын" артеленә "тегүче-надомница" булып эшкә урнаша алган. Ә Суфияне беркая да эшкә алмыйлар. Шулай тилмереп бераз йөргәч ул, кызлары Зәйнәп, Әминә, оныгы Оркыяне алып, Томски каласында яши башлаган дәү әнисе Хава янына китә.

Берәр институтны тәмамлап кулына диплом аласы килә аның. Индустрия институтына кереп, бераз укып та йөри. Тик матди хәл бик авыр, институттан чыгып, заводка эшкә керергә мәҗбүр була. Сугыш вакытында да ул шул электромеханика заводында эшли. Эш бик авыр. Ашау-эчү яклары бик исәпле. Суфиядән башкалар "рабочий паек" та алмыйлар. Гомергә туганнарын кайгыртып яшәргә өйрәнгән Суфиягә үз паегын гаилә әгъзалары белән бүлешергә туры килә. Ул ачыга, ачлыктан шешенә башлый.

Бер уйласаң, дөньяда бәхетеңә күрә кайвакыт юньле кешеләр дә очрап куя бит. 1943 елны заводта һәрбер җан иясенә кытлык зур булуга карамастан, ачлыктан шешенгән Суфиягә Казанга китәргә рөхсәт бирелә. Мең газап белән унбиш көн кайта ул Казанга. Кайтып керүгә, окоп казырга чакырып кәгазь килә. Көч-хәл белән райбашкарма комитетына килә Суфия. "Бер дә хәлем юк бит, бәлки бераз кичектереп торырсыз?" – дип үтенгәч, аңа кызыл битле бер түрә: "Бик әйбәт булыр. Шунда үлсәң окопка күмеп куярлар, безгә мәшәкатең ким булыр", – ди. Суфиягә бу юлы да исән калырга язган икән. Сталин районы торак идарәсенә грамоталы, эштән курыкмый торган хезмәткәр кирәк була. Шул окоп казырга китәргә килгән җиреннән Суфияне управдом итеп эшкә алалар. Соңыннан башка бүлеккә дә күчеп, ул 17 ел райбашкарма комитетында эшли.

1946 елны Суфия апа заманында үз акчасына 11 мәчет салдырган, мәдрәсә мөгаллимнәренә хезмәт хакы түләп, шәкертләр өчен торак йортлар җиткергән атаклы Ногман хаҗи улы Гомәр белән никахлашкан. Тату гына гомер иткәннәр. (Гомәр абый 1978 елны вафат була).

Суфия апа үзенең нәселенә табынып яши, андагы шәхесләргә искиткеч хөрмәт белән карый. Ерак бабаларының тормышын, иҗат мирасларын армый-талмый өйрәнә, барлый. Ничәмә-ничә музейлар, китапханәләр белән даими элемтәдә тора. Нәсел шәҗәрәләрен дә ул берничә нөсхәдә төзеп чыкты.

Әле менә Мәрҗанинең туган ягында – Әтнә районы Комырхуҗа авылында, Казанның 2 нче гимназиясендә оешып яткан Мәрҗани музейларына булышуны Суфия апа намус эше итеп карый, зур җаваплылык тоеп алар белән даими очраша, кирәкле материалларны эзли, таба. Һәр документны, һәр рәсемне дәлилләр өчен үзен дә, вакытын да кызганмый.

... Кечкенә генә фатирының тәрәз төбендә ул гөлләр үстерә. Нинди генә гөл утыртса да, гөлләре бик тиз үсеп китә. Шулай, матур гөлләрең кебек тагын да озак, матур яшәргә язсын сиңа, игелекле Суфия апа.

Тәминә БИКТИМЕРОВА,
тарих фәннәре кандидаты.

● Суфия апа Мостафина онықлары белән.
Мидхәт ШАКИРҖАНОВ фотосы.

М.Горький исемендәге әдәби-мемориаль музейда "Татар кулъязмалары һәм иске басма китаплар" дигән күргәзмә ачылды. Анда Татарстан Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегеннән алынган басмалар, сәнгать әсәрләре, шәмаилләр куелды.

Хөттатларның изге хитабы



Татар китабының мең елдан артык гыйбрәтле бай тарихы бар. Хәзерге китап рәвешендә укучы кулына килеп кергәнче ул берничә баскыч үтә: кулъязма һәм басма рәвештә ерак чорлар сулышын үзенә сеңдерә.

Татар китабының тарихын өйрәнүгә беренче буразналар салынды инде. Танылган галимебез, академик Әбрар Кәримуллин үзенең хезмәтләрендә басма китап, басмаханәләр тарихына тирән, етрафлы анализ бирде. Академик Миркасыйм Госманов, Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кулъязмалар бүлеге җитәкчесе Марсель Әхмәтҗанов кебек галимнәребезнең бу өлкәдәге эшчәнлеге дә татар китабының (аеруча кулъязмаларның) үткәндәге ролен билгеләү, нәтиҗәләрен халыкка җиткерү белән тыгыз бәйләнгән. Әлбәттә, милләтебезнең үткәненә кагылган һәрбер нәрсә бик авырлык белән тикшерелгәнгә, әлеге эш тә акрынлык белән бара.

Кулъязма китап – татар халкының бай рухи мирасы. Ул гыйлем, тәрбия бирү белән бергә, мөстәкыйль яшәп килүче тармак та булган. Чөнки нәкъ менә кулъязма китап битләрендә аны күчерүченең, бизәүченең, төпләүченең сәнгати осталыгы, күн эшкәртүчеләрнең, кәгазь-кара җитештерүчеләрнең тырыш хезмәте уелып калган. Ә инде заказчылар, сатучы-сатып алучылар арасындагы мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә бу төпләнмәләр безнең көннәргә үк килеп җиткән.

Татар кулъязма китабы дигәндә без серле, бизәксыман гарәп хәрефләре белән "чигелгән", саргайган кәгазь битләрен күз алдына китерәбез. Ләкин галимнәр раславынча, борынгы бабаларыбыз – болгарлардан Х гасырда Ислам динен кабул иткәнчегә кадәр үк, рун язулы кулъязма традицияләренә нигез салынган була.

Кызганычка, исәпсез күп хәзинәдән аз өлеше генә тарих гарасатларын кичеп, белгечләр кулына килеп кергән. Татар кулъязмаларының иң борынгылары да XIII-XV гасырлар белән чикләнә.

Китап күчерүчеләрне мөселман илләрендә "хәттатлар" дип йөрткәннәр. Каллиграфия – матур, нәфис, төгәл язу сәнгате. Матур язу осталыгы мөселманнарда, шул исәптән татарларда да, югары бәяләнгән; гыйлемлелек һәм иситкеч зур сәләтлелек үрнәге булып исәпләнгән. Шуңа да хәттатлар дәрәҗәле, мөхтәрәм кешеләрдән саналган. X-XI гасырларда барлыкка килгән "Язу – ярты гакыл" дигән хәдис тә әлеге һөнәрнең асылын чагылдыра, әһәмиятен күрсәтә.

Һөнәрмән хәттат булу өчен укый-яза белү генә җитми, тиз, ачык-төгәл, пөхтә, укучыга аңлаешлы итеп яза белү дә зарур. Шуңа күрә кулъязмалар иҗат итүченең исеме ихтирам белән телгә алынган, аның җәмгыятьтә тоткан урыны да Русия һәм Аурупа илләрендәге коллегаларыннан күпкә югары булган.

Профессиональ оста гадәттә ялгызы эшләгән (бу нисбәттән ул Аурупа илләрендәге "ирекле һөнәрче"ләрне хәтерләтә). Әмма сату өчен күпләп китап җитештергәндә берничә язу остасы, бизәүче-нәккаш, китап тышлаучы китепханәләр, гыйлем йортлары каршында яисә шәхси осталханәләрдә берләшеп эшли торган булганнар. Кайвакыт китап күчерүче бизәү һәм тышлау эшләрен дә үзе башкарган.

Татарларда китап язу-күчерү бик саваплы, изге эш саналган. Мондый мөнәсәбәтнең нигезе мөселманнарның "тормыш китабы" – изге Коръәнгә барып тоташа. Коръән – Алла тарафыннан иңдерелгән дип исәпләнгәнгә, кәгазьгә уелган сүз дә, язу процессы да тылсым көченә ия дип каралган.

Китап күчерүчеләрнең эшләү рәвеше бүгенге язучыларныкыннан нык аерыла. Хәттат, идәнгә җәелгән келәмгә утырып, тезләренә тигез такта куя һәм бу такта өстенә кәгазь салып эшкә керешә. Кайвакыт ул тәбәнәк сәкегә утырган, яисә уңайлырак булсын өчен аякларын шул сәкегә куйган. Соңрак китап куйгычлар да кулланышка керә.

Матур язу осталыгына өйрәтү кеше яшьтән башланган. Кайбер шәкертләр инде 10-11 яшьтә шул кадәр уңышларга ирешкәннәр ки, тулы бер кулъязманы күркәм итеп күчереп яза алганнар.

Мәдрәсәләрдә язу техникасын күп очракта хәлле, бай кешеләрнең, дин әһелләренең балалары үзләштергән. Алар барысы да профессиональ хәттат булып китмәгән, әлбәттә. Әмма алардан югарыкатлау әдәп кагыйдәләре буенча камил язу осталыгы таләп ителгән. Шәкертләр аерым хәрефләрнең язылышын, кушма лигатураларның формасын, төрле стильләрне, бер үк стиль кулланып язылган төрле почеркларны җентекләп өйрәнгәннәр, кул күнексен өчен йөзләрчә-меңнәрчә тапкыр кабатлаганнар. XVI гасырларда һәрбер өйрәнчек малай кимендә өч стильне (нәсх, солс, нәстәликъ) иркен кулланырга тиеш булган.

Язу сәнгатен өйрәнү ике төрле ысулга нигезләнгән. Беренчесе – "каләми" күнегүләр – сабырлык, басынкылык, игътибарлылык, җыйнаклык кебек мөһим сыйфатларны тәрбияләү һәм кул шомарсын өчен танылган хәттатларның үрнәкләрен күп тапкырлар кабатлаудан гыйбарәт. Мондый күнегүләрне башлап өйрәнүчеләр генә түгел, инде шомарган осталар да еш башкарганнар – барысы да оригиналдагы язуга охшатырга тырышканнар.

Икенче ысул – "назари" ысулы исә остазның күзәтүе астында бер стильне кулланган күптөрле осталарның үрнәкләрен чагыштыру, тикшерү, анализлау, нәтиҗә ясау рәвешендә барган. Һәм дә теге яки бу хәрефнең язуда гүзәл, камил кулланылышын ачыкларга ярдәм иткән.

Гаять матур күчермәләрне иҗат итү өчен (нәкъ менә шулай атарга нигез бар) бик күп көннәр, айлар, хәтта еллар киткән. Кайбер хәттатлар көненә берничә дистә юл, күп очракта ике-өч битне язу белән чикләнгәннәр. Шулай да алар арасында төгәл язу белән бергә тиз язу да асыл сыйфатлардан саналган.

Текст турыпочмаклы кысалар эченә алынган. Кысалар саны 1дән 2гә кадәр, төсләре – кара, зәңгәр, яшел, сирәк очракта кызыл яки алтынсу-саргылт булуы ихтимал.

Текстның исеме, бүлек башлары башка стильдә, калын, эре хәрефләр белән, төсле кара кулланып, астына сызып билгеләнергә мөмкин.

Күпчелек кулъязмаларның рамка кырларында да язмалар очрый. Мондый язмалар әсәргә төгәллек керткәндә, төшеп калган сүзләрне өстәгәндә хәттат яисә укучы тарафыннан ясалган. Еш кына юл кырындагы бу өстәмәләр тәфсир, аңлатмалардан тора. Тупланган татар кулъязмалары арасында каллиграфия осталары башкарганнары да, гади кешеләр, шәкертләр күчергәннәре дә бар. Гарәп язуында традицион "алтылык" (алты стиль) бар: мухаккакъ, райхан, нәсх, солс, тәүкигъ, рикагъ. Фарсы кулъязмалары аша безгә тәгълик (Төркиядә аны "дивани" дип йөртәләр), нәстәликъ һәм ишкәстә ысуллары үтеп керә.

Татарларда исә күбрәк нәсх, солс, нәстәликъ кулланылган.

Гарәп язуында баш хәрефләр, абзац бүленеше, тыныш билгеләре юк. Шуңа күрә алар урынына төрле геометрик фигуралар – бишпочмаклы йолдызчык, түгәрәк, йөрәк, өчпочмак кулланыла. Болар барысы да, төсле каралар белән эшләнеп, текстка бизәк рәвешен бирә.

Кулъязма китапларны күбесенчә күн тышлыклар белән тышлаганнар. Тышлыкның уртасына, почмакларына бизәкләр уеп төшерелгән.

Тышлыкның нинди булуы (күн, катыргы, юка кайрыдан) күчерүченең, заказ бирүченең, яисә әлеге нөсхәне саклаучының матди хәленә бәйле.

Мөселман күн тышлыкларының бер үзенчәлеге бар – аларда сул тышлыкка тоташып ясалган һәм уң як тышлык астына кереп торучы каплагыч эшләнелә. Тышлыкның эчке йөзе (форзацы) кәгазь белән ябыштырылган.

Иң төп язу коралы – тимер яки каурый каләм. Кош-корт каурыйларын куллланыр алдыннан яхшылап эшкәртәләр: көлдә яки комда тотып, эчендәге элпәсен, маен алалар да, махсус пычак ярдәмендә очлыйлар. Мондый каләм үткен була, язуы – ачык, сызыклары нәзек чыга.

Әсәрләрне кәгазьгә кара белән төшергәннәр. Караларны махсус рецепт буенча да, корымнан да ясаганнар.

XVI гасырда Казан ханлыгы буйсындырылгач, иҗтимагый тормышта әһәмиятле урын тоткан китапның функцияләре кысрыклана, китап язу-күчерү эше сүлпәнәя. Кулъязмаларны күбесенчә сату өчен түгел, бәлки, һәркем үзе өчен генә күчерә. Барча кешенең дә матур язу, бай итеп бизәү, яхшы итеп тышлау мөмкинлеге булмый. Шуңа күрә XVII-XVIII гасыр татар кулъязмаларының күбесе бик гади.

Татар милләтен теленнән, диненнән яздырырга күпме генә тырышмасыннар, урыс миссионерлары, патша хакимияте үз максатларына тулысынча ирешә алмыйлар. Татарлар арасында белемгә омтылу кимеми, гореф-гадәтләр югалмый, гарәп язуына нигезләнеп белем алу көчәя генә бара. Нәкъ менә шушы чорда китап ата-бабаларыбыз рухын саклаучы, аң-белем, тәрбия, дин мәсьәләләрен аңлатучы бердәнбер терәк була.

Татар кулъязма китабының эчтәлеге күптөрле: мөселманнарның изге китабы Коръәннән башлап, дини кануннар, тәфсирләр дә, мәдрәсәләр өчен дәреслекләр дә, татар халык авыз иҗаты әсәрләре, татар һәм Көнчыгыш шигъри ядкарьләре дә күчерелә, кулъязма сүзлекләр дә төзелә. Халыкта киң таралган бәетләр, фал ачу, күрәзәчелек итү серләре дә китап битенә теркәлеп барып, буыннан-буынга тапшырылган. Кулъязма китап традициясе XVIII гасырда басма китапка нигез салынгач та дәвам итә. Моның сәбәпләре бар: беренчедән, китап басу өчен матур, төгәл үрнәкләр кирәк була; икенчедән, реалистик характердагы әсәрләргә караганда дини китаплар күбрәк басыла; өченчедән, һәркемнең дә басма китап сатып алырга хәленнән килми (чөнки урыс самодержавиесе татар китабын бастыру өчен бәяне 25 тапкыр һәм аннан да артык күтәрә); дүртенчедән, шәкертләр, язу белгән гади кешеләр, кирәк әсәрләрне үзләре күчерәләр, һәр мәгълүмат, шигырь-бәетләрне теркәп баралар.

Шулай итеп, кулъязма традицияләре XX гасыр башына кадәр, хәтта гарәп графикасы латин язуы белән алышынгач та дәвам итә. Әле 80 нче еллар башында да, гарәп язуын белгән кешеләр хатларын, көндәлекләрен, шигырь-бәетләрен урыс-латин хәрефләре белән язуга караганда "иске татарча" язуны кулайрак күрәләр иде.

1917 елга кадәр сүнмичә сакланып калган милли рухыбызны динсез, кәгъбәсез большевиклар идеологиясе аша, югалтмыйча бүгенге көннәргә җиткерүдә әби-бабаларыбыз күңелендә уелып калган яктылык – динебезгә, гарәп язуына булган ихтирам, мәхәббәт аеруча зур роль уйнады. Алар һәрбер гарәп язулы кәгазь кисәген кадерләп сакларга тырыштылар. Бу исә буыннан-буынга күчеп, итагатьлелек, әдәплелек кагыйдәләре белән рәттән бабаларыбыз мирасына хөрмәт тә тәрбияләде.

Бүгенге көндә яшьләр, өлкәннәр рухи асылыбызга кайту максатыннан гарәп язуын, телен өйрәнәләр. Хәтта оста каллиграфларыбыз да бар. Тик күбесенең исеме халыкка барып җитми – аларга үз осталыкларын күрсәтү мөмкинлеге юк; гарәп язуы көнкүрешебездә аз кулланыла. Ә бит мондый осталарны халык белергә тиеш.

Милләтне саклап калу өчен аңарда үз тарихы, бай мирасы белән горурлык уяту зарур. Бу эш милли китапларыбыз аша да алып барылырга тиеш. Чөнки академик Әбрар Кәримуллин әйткәнчә, "милли аңны саклау, уяту, тәрбияләү өчен китап – иң көчле корал".

Давылларны үтеп тә җиңелмәгән, ерак бабаларыбыз калдырган төпле рухи нигезебез – татар кулъязма һәм иске басма китапларның киләчәге ничек булыр? Латин графикасына күчү белән аларга караш үзгәрерме һәм кайсы якка үзгәрер икән?

Алсу КӘРИМОВА,
М.Горький исемендәге музей хезмәткәре.

● Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында саклана торган китаплар күчермәсе.

Гыйнварда журналлар ни яза?

"КАЗАН УТЛАРЫ"

Шигърият һәм чәчмә әсәрләр.

М.Галиев. Догалы еллар. Эссе.

Г.Афзал. Мин картайган саен усалланам. **Шигырьләр.**

Р.Фәизов. Ике әни. Повесть.

Р.Фәйзуллин. Әй, бу яшәү!.. Шигырьләр.

Публицистика.

Ф.Дунай. Заманына күрә заны.

Р.Гаташ. Моңнар бәйрәме.

Г.Зәйнашева. Мәхәббәт турында уйланулар. Шигырьләр.

Г.Ахунов. Язучы һәм заман.

Хәтер

Я.Абдуллин. Шиһабетдин Мәрҗани.

Т.Галиуллин. Кабатланмас шәхес.

Н.Гамбәр. Аккош күлендә утлар...

Ф.Ибраһимова. Галимҗан Ибраһимов фатирлары.

Сәнгать

Н.Шәйдуллина. "Театрда гомер үткәне сизелми..."

Әдәби тәнкыйть

Р.Шәрәфиев. Үзең шатлана белмәсәң...

Китап күзәтү

Н.Сафина. Җиргә төшә сөю йолдызлары... үткәннән.

Ш.Галиев. Хикмәтле сүзләр.

Латин имлясында уку үрнәкләре. Имеш-мимеш түгел...

Безнең календарь

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

"СӨЕМБИКӘ"

Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең 70 яшьлек юбилее уңаеннан. Р.Камалетдинованың язучы белән "Кодрәтле сүз иясе" дигән әңгәмәсе урын алган.

Иң өлкән укучы Гомәр Бәширов журнал турындагы фикерләре белән уртаклаша.

"Әнигә дә, бәбигә дә" дигән рубрика дәвам иттерелә.

"Айсылу" кушымтасында психолог киңәше тәкъдим ителә.

Бу санны юбилярлар саны дияргә була. Г.Зәйнашевага 70 яшь тулу уңаеннан Л.Ихсанованың "Җырны тиккә җырламыйлар" дигән мәкаләсе тәкъдим ителә. Танылган режиссер К.Тумашеваның тууына 95 ел тулуга карата, шагыйрь Ф.Яруллинга 60 яшь тулу уңаеннан да язмалар бирелгән.

Ф.Сабированың Түбән Камадан "Язылган гомер булмасмы күмер" дигән мәкаләсе һ.б. бар.

"ТАТАРСТАН"

Рәмзи Ногмани. XXI йөз мәдәният гасыры булырмы?

Рафаэль Черкасов. Киләчәкнең азык хәзинәсе һәм химия.

Мәхмүт Әхмәтҗанов. Укытучы – йөзек кашы.

Изил Гарифуллин. Матур һәм батыр сүзе.

Рифкать Әхмәтьянов. Татар халкының рухи мәдәнияте.

Илтани Һилалова. Әкиятләр иле – Испания.

Рафаэль Мостафин. Чынбарлык белән йөзгә-йөз.

Миргазиян Юныс. Конгресс (Финляндиядә дөнья язучылары җыены).

Жорж Сименон. Мегрэ ханым танышы.

Фәнис Яруллин. Шигырьләр. Дөнья елмая. Мәзәкләр.

Айрат Бәхтияров, Рөстәм Курчаков. Татарстанның милли икътисады.

"САЛАВАТ КҮПЕРЕ"

Шигърият

Х.Халиков. Мактанчыклар ярышы.

Ә.Гадел. Алмагач кызы.

Р.Нуруллин. Карамада тугыз алма.

Нәсер

Ә.Баян. Сәрвиназ хикәяләре.

Әкият

Л.Лерон. Борчак шыттырам.

Җыр

Х.Халиков, Ә.Хәйретдинов. Былбыл сайратам.

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ, Татарстанның халык язучысы

Балачак

(Ахыры. Башы 3 нче санда).

Әнвәр түти белән без корган театрны Алмаздан бүтән кеше күрмәгәндер дә, ул да, мин дә серне чыгармадык. Әллә күреп тә дәшмәделәрме?

Авыл өе бик бәләкәй булса да, элек аңа әллә ниләр сыя иде! Сыер бозауласа, бозавын күтәреп өйгә кертәләр, кышкы суыктан саклыйлар. Без малай чакта суыклар чыннан да суык була торган иде. Көздән, ноябрь башларында төшкән кар язга кадәр шылт та итмичә эремичә ята иде. Бозау артыннан сыер да өйгә килеп керә. Бозавын ялый, иркәли, куе угыз сөте белән аңа үсәргә көч бирә... Угыз коймагын без барыбыз да бик яратабыз, коймак пешкән көн – елына бер килә торган бәйрәм. Ул көннең тагын бер шатлыгы бар: мин зур колхоз табагына тутырып күршеләргә угыз коймагы ташыйм! Күршебез Ипис түти коймак керткәч миңа бер уч чикләвек, бер уч айбагыр бирә, бозау турында озаклап, бөртекләп сораша: маңгаенда кашкасы释 бармы, бәкәле ак түгелме? Ни төсле?! Үзең керткән күчтәнәч, коймак белән чөгендер чәе эчә-эчә бозау турында сөйләү нинди рәхәт!.. Балачак рәхәтләре алар үзгә, аерата кадерле, аерата газиз...

Сыер өйгә кергәндә мин аның очлы мөгезләреннән куркып мич арасына кереп качам, Әнвәр түти мине арттан кочаклый, мин аның җылы тәненә тиеп дөньямны онытып тынычланам...

Аулак калган мизгелләрдә без кәмит күрсәтеп кенә яшәмибез, кайчагында Әнвәр түти боз каткан тәрәзә алдына килеп баса, ике кулы белән ике тәрәзәнең ике яңагына ябыша һәм тонык кына бер көйгә җырлагандай итә. Тавышы юк аның, тавык кырлавыннан аерылмый, ләкин сабый булганмын, тутамның – ятим-ялпының, бичара толның бертуктаусыз мөнәҗәт укуын белә алмаганмын. Сүзләрен аңлап бетермәсәм дә мин аның тәрәзә аша йотылып үз балачагына кайтканын кемнедер сагынып, юксынып мөнәҗәтләр укуын үтә дә ярата идем. Андый чакларда түти түгел, мин сагаям, капка әз генә шыгырдады исә, "кайттылар!" дип пышылдыйм... Уртак серебезнең дөньяга фаш булуын теләмим...

Менә безнең "гаилә" ишәя, исәя башлаган, мөгезләре төртеп чыккан наян бозау янына берәм-берәм сарык бәрәннәре кереп кушыла башлый. Бәрәннәр тиз үсә: атна дигәндә өйгә алар хуҗа була! Җитмәгән җирләре, аудармаган нәрсәләре калмый. Иләк, чиләк, ипи табаклары һәркөн күчеп, күченеп йөриләр. Өй тарая, бозауны муенчаклап аралыктагы тимер боҗрага бәйләп куялар. Бәйләп куймый кара, бәрәннәргә ияреп алдын-артын сикертеп чаба башласа! Бер көн ычкынган да ашлы сулар җыя торган лаканны аударган. Әй ләкте Әнвәр түти белән миңа!

Бозау, бәрәннәр белән аулак өйдә калырга ярата Әнвәр түти, ул аларны кочаклый, муеннарын кашый, чәйнәп ипи йомшагы каптыра, дымлы борыннарын үбә. Бәрәннәр аның саен наянланалар, кушаяклап сикерәләр, ишекле-түрле ду килеп чабалар. Муенчагын өзәрдәй булып аралыкта бозау сикерә, Әнвәр түти идән уртасына чыгып баса да учларын шапы-шопы китереп үзенең мәңгелек такмагын кабатлый: "Сездә кем бар киндер суга!.. Сездә кем бар киндер суга!" Бәрәннәрнең нәни тояклары дер селкеткәннән бүрәнә арасыннан мүк коела, кыстырган җиреннән уклау атылып чыгып идәндә бии, кисәү агачлары, җәмки, самавыр торбалары, ухаты, лар дер-дер селкенәләр. Андый чакта тик торып буламыни? Мин дә өйдәге хәрәкәткә кушылып китәм һәм Әнвәр түтигә ялгап такмак әйтә башлыйм... Юк, аның сүзләрен кабатламыйм, минем үземнеке, үзем чыгарган такмак бар...

Чыгарган беренче такмагым – шигъри юлларым хәтердә калмаган, соңгы бер юлы гына исемдә... Әлбәттә, ул шушы бөдрә йонлы, тере күзле, шук бәрәннәргә багышланган иде... "Идәнгә шомырт коя" иде аның соңгы юлы... Баштагы юллары: "яфрак ярата бәрәннәр... тамаклары тиз туя... Тамак туйгач сикергәләп, идәнгә шомырт коя", булды шикелле... Ни гаҗәп Әнвәр түти минем такмакка игътибар итте, "киндер сугучыны" онытып, миңа ияреп мин чыгарган такмакка күчте, без икәүләп идәндә сикергәләдек, керәшенчә әйтсәк, уармак килдек, димәк ясадык.

Иртәгесен без тагын аулакта калдык, бүтәннәрнең аяк эзе тынгач, бозау, өч бәрән, Әнвәр түти һәм мин пәри туен башладык... һәм Әнвәр түти кичә мин чыгарган такмакны кабатлый башлады... Бу хәл миңа көч бирде, дәрт өстәде... Шул көнне мин яңа такмак чыгардым. Анысы аралыкта моңаеп торган бозауга багышланган иде сыман...

4.

Кар китте, сукмаклар төште. Мин хәзер урамнан кайтып кермим дә. Аскы урамда, Кирушлар турында атау, җир иң әүвәл шунда ачыла. Җыелышып тәтәйле кузналы уйныйбыз, акча чөябез. Кичләрен мөгәҗи амбары тирәсенә яшьләр җыела. Кайчагында яшьләр уены безнең турга – Әндриян дәдәйләрнең амбар алдына күчә. Имәнле урамыннан гармунын күтәреп Чыжык Бәчелие килә. Уйныйлар, җырлыйлар. Әтинең иске пинҗәген иңемә салып, төренеп мин дә бер читтә басып торам. Яшьләр җырына кушылып иреннәрем кыймылдый, ни гаҗәп, берзаман мин яшьләр җырлаганның сүзләренә үз такмакларымны кушып җибәрәм.

Яз – бәйрәмнәр чоры. Беләм, озакламый Олы көн килеп җитәчәк. Олы көн – урысларның Пасха бәйрәме. Ул көнне Баграж – керәшен авылы гөр килеп торачак. Караңгылы-яктылыда бала-чагалар күкәй җыялар. Өйгә кергәч тиз-тиз "Иисус-Христус терелеп торган", диләр. Йорттан йортка йөреп минем дә манган күкәй җыясым килә. Тик мине әни чыгармый, "без татар, мөселманнар", ди ул. Мин, аңлап бетермәсәм дә, татар икәнлегемне, керәшеннәрдән аермамны сизә башладым. Су коенырга буа алдына төшсәк, малайлар миңа карап чыр-чыр көләләр, усалраклар:

Татар, татар – тарама,
Кермә безнең арага.
Кысылырсың, үләрсең –
Биш тиен акча түләрсең... –

дип җыр әйтәләр.

Усал малайларның авызын томаларлык такмак чыгарасым килә, барып кына чыкмый, җавап итеп кайдадыр отып алган җырны кабатлыйм:

Керәшен, керәшен – керкәле,
Баш түбәсе серкәле.

Бәйрәм якынайганын шуннан сизәм, көн туды исә Багражның кынҗыр кызлары әни янына күлмәк тектерергә киләләр. Бәйрәм якынлашканын бер сылу кызлар гына сизенәме!?

Югары очта Җәмәй атлы бер бик фәкыйрь кеше бар иде. Кышын тәмәке төрергә гәҗит каян алгандыр, һәр язда исә ул безгә килеп керә торган иде. Килә, болдыр баскычына утыра, дәшми – теле юк. Телсез Җәмәй дә диләр, кушаматы – "Пружин". Озын, чандыр гәүдә – сорау билгеседәй бөгелгән. Очлы иягенә өч-дүрт бөртек сакал ябышкан. Өстендә алагаем дәү якалы, терсәкләре ямаулы чикмән. Кырык ямаулы чалбар тишекләреннән тез башлары күренеп тора. Аягында киндерәләре ялганган дәү-дәү мыеклы чабаталар. Пычрак аягы белән өйгә керми, кат-кат чакырсаң да, ияген як-якка чайкый. Тәмәкегә гәҗит сорап килгән Җәмәйне безнең әни беркайчан да ашатмыйча, тамагын туйдырмыйча җибәрми торган иде. Өйдә нинди ризык пешсә, тәлинкәгә салып Җәмәй дәдәйгә чыгара. Мин аның ашаганын карап торырга яратӓм. Озын җәпле бармаклары катып, калҗаеп беткән, тырнаклары җитү. Алдына ризык килгәч ул кинәт үзгәрә, гәүдәсе тураеп киткәндәй була. Ул ризыкның бер бөртеген, бер тамчысын исраф итмичә, кадерләп, олылап ашый. Ипи, дурычмак өлешен йоткач, башын артка ташлый, бугаз алмасы бүлтәеп чыга, ул керфексез яшел күзләрен йома, күз урынында вак җыерчыклардан хасыйл елмаю гына балкып кала. Тәлинкә чыгарасыңмы, табамы – ризыгы беткәч ул һәрберсен ипи катысы белән ышкыйышкый сөртә, майга манчылган икмәк катысын кәнфит суыргандай суыра... Кулына гәҗит эләккәч тәмәкесен шартаякның тубырлы башы юанлыгы итеп төрә. Безнең өй тирәсендә кабызмый, әнинең тәмәке исен яратмавын белә, "тартмыйм, тартмыйм!" дигәндәй, тәмәкесен күз югарылыгына күтәреп күрсәтә.

Әниләр кая киткән булгандыр, бер көнне әбәдтән соң Җәмәй дәдәй килеп керде. Әнвәр түти ишегалдында, кояш күзенә мендәрләрне тараткан, мин җиз тасны аударып, астына баулы таяк кыстырып, тас астына җим сибеп күгәрчен тотарга маташам. Күгәрчен белән мавыгып Җәмәй дәдәйне онытып җибәргәнмен, бер заман карыйм, утыра да утыра теге, ыңы-шыңы юк, тез тишекләрен чикмән итәген кайтарып яшергән. Әнвәр түти тегеңә берни чыгармый. Мин аның янына йөгереп килдем. "Бетмәс монда әрәмтамак, хәерчеләр!" – ди тутам. "Ипи кыерчыгы алып чыгам!" – дип өйгә керә башлаган идем, түти мине эләктереп алды. "Йөрмә!" Мондый кирелеген белми идем тутабызның, аптырап киттем. Җәмәй дәдәй утырды, утырды да, бөгелеп, бөкерәеп чыгып китте. "Саран бака син, Әнвәр түти!" – дип кычкырганымны сизми дә калдым.

Хәерчеләр дигәннән, без бәләкәй чакларда хәерчеләр авылдан-авылга ел әйләнәсенә йөриләр иде. Ни бирсәң дә алалар, иске-москы киемсалымны да алалар, ипи кыерчыгына да бөгелә-сыгыла рәхмәт әйтәләр. Сәер, җәенке арбаларына утырып дөя җиккән кыргызлар килеп чыга иде. Алар дөяләрен урам уртасында туктаталар, үзләре өй борынча кереп йөриләр, чыбыркы сабы белән муеннарын кашып: "Яндык, казалы булдык", – дип, күзләреннән кысып кына тонык тамчылар чыгаралар. Керәшеннәр үтә ярдәмчел, мәрхәмәтле кабилә, кыргызларга ышаналар, җәллиләр, "бала-чагаң күпме?" дип белешәләр, яртышар капчык бәрәңге, подаука төбенә салып он чыгаралар, ашарга да дәшеп

● *Аяз Гыйләҗев Зәй районы Баграж авылында әти-әнисе хөрмәтенә эшләнгән чишмә янында.*

М.ШАКИРҖАНОВ фотосы.

кертәләр. Ә без, аю мае сөрткәннәрмени, дөя яныннан китмибез. Якын барырга базмыйбыз, дөянең усаллыгын беләбез, лач итеп төкерергә дә күп алмый ул...

Авылда тагын бер сәер хәл булды: тазарак тормышлы йорт хуҗаларын өйләреннән куып мунчаларга, таш амбарларга чыгардылар. Бездән ике-өч өй аркылы гына яшәгән Үртәми дәдәйләрне дә мунчага куылар. Ишле балалы Үртәми дәдәйнең өен мәктәп иттеләр. Тиздән, бик тиздән Үртәми дәдәйнең улы – яшьтәшем Бәчели белән алар өендә беренче класста укый башларбыз дип кем уйлаган...

барырга кирәк. Имәнле урамын узып Түбән авылга төшеп барганда әти белән әни әз генә тарткалашып алдылар. Әти: "Зәй аша барыйк, анда юл ышанычлы", – дигән иде, әни каршы төште. "Әллә каян әйләнеп йөргәнче, турыдан гына чыгыйк", – дип, үз сүзен куәтләде. Ата-аналар тарткалашканда быткыч балалар тик тора аламы? Азат, дилбегә тотып, кукыраеп кузлага утырган, борыны чөенке, олы малай, әти ягын куәтләде: "Зәй аша барабыз, Зәй аша!" Ә мин, әни малае, "урман аша барыйк, урман аша!" дип тыкырдатам. Әни алдына җайлап яткан энекәшем Алмаз, юлга чыгуга тирбәнеп йокыга китте. Түбән авылга төшкәнче бәхәс дәвам итте, ахыр чиктә ике як та йомшап, уртак фикергә килделәр: Ашыт-Әхмәт авыллары аша барабыз да Зәй аша кайтабыз! Азат борылып миңа телен чыгарып күрсәтте. Нигә очынган була инде, икебезнең дә сүзе үтте ләбаса!

Без Түбән авыл урамына барып кердек. Күрше авыл кешеләре, әти-әнине танып, түбәнчелек белән сәламлиләр, кая баруыбыз белән кызыксыналар, белгәч, безгә хәерле юл телиләр. Авыл кибете яныннан үткәндә әти атны тук-

5.

Без яшәгәндә йорт хуҗалары Багражга кайттыларммы, юкмы, хәтеремдә калмаган. Әндриян дәдәй хатыны, ике малае белән Федот детдомында озак кына яшәде шикелле. Кайтмый калмаганнардыр, алар үзара да, күрше-каршы белән дә тату, дус яшәрлек сабыр акыллы кешеләр иде. Кайтып, безнең тигез генә аккан тормышка

йөрделәр. Тоташ чия агачлары белән капланган бик биек тау башына менгәч, мин телсез калдым. Мондый киңлекләрне, ерак офыкларны, матурлыкны минем бер чакта да күргәнем юк иде. Баграж тавына менгәнем бар, ләкин безнең авыл өч яктан урман белән әйләндереп алынган да тау башыннан ерак офыкларны күреп булмый торган иде. Ә монда исә... бер-берсен кисешкән басу юллары, елга буе әрәмәләрен чәлмәштергән сукмаклары мине тәмам хәйран калдырды. Минем дә әнә шул, кышкы карда куян эзе сыман чәлмәшкән сукмаклардан, тагын әллә кайларга барасым, әллә нинди ят дөньялар белән танышасым килде...

Ничә көн кунак булганбыздыр, исемдә калмаган, кичләрнең берендә өстәл тирәсендә олылар белән тәмләп бәрәңге дурычмагы белән чәй эчеп утыра идек, кече яктан дурычмак өйгән тәлинкә күтәреп чыгып килүче апа лып итеп урындыкка утырды. Кызганычка, Әндриян дәдәй хатынының исемен онытканмын... Урындыкка утырды, тәлинкәсе шапылдап идәнгә төште, майлы дурычмаклар идәнгә тәгәрәде. Олылар: "Ни булды, ни булды?" – дип, апа тирәсендә кылбырдак килделәр.

сукмаклары

бер-бер бимаза ясасалар, ихтимал, хәтеремдә дә калыр иде. Явызлыкның ташка, яхшылыкның комга язылуын аңлый башлаган идем инде мин. Әндриян дәдәй тәбәнәк, базык кеше иде. Бер кулының дүрт бармагы юк, кыска, кисек буынлы бармаклары белән аркамнан сөеп куркытканы исемдә. Бөдрә йомшак чәчле иде без торган йортның хуҗасы. Багражда һәркемнең нәселдән күчеп килгән кушаматы бар. Әндриян дәдәйләрнең күршесе – "Бояр"лар. Ата-бабасы тимерче бу крәстиәннәргә ник "Бояр" кушаматы тагылгандыр, белмим. Авылның Югары очтан Түбән очка кадәр өйдән-өйгә сикереп күчә торган кушаматлар әлифбасы бар, әйтик: "Әндриян бөдрә, бояр ыштанын салып йөгерә..." Нәсел-нәсәбеңнән берәү авылга яки авыл кешеләренә ямanлык кыла икән, беттең, кара сакалың кая барсаң да артыңнан калмас! Берәр адәм хәтерлиме икән Югары Багражның кушаматлар әлифбасын? Ялкауларга, аңгыраларга, җыбыткыларга, канчыкларга, биләмчеләргә, каруннарга нык эләгә иде ул җор тезмәләрдә!

Нигә "Бояр" кушаматы алган нәселне ыштан салып йөгерткәннәр? Белмим. Ул нәселдән авылда байтак гаилә бар иде, һәммәсе һөнәрманнар, яхшы, тырыш кешеләр. Бояр Ибаны, яшьтәшем, исәнме син? Кайларга китеп югалдың?..

Әндриян дәдәйләргә кунакка барып кайту вакыйгасы онытылмаслык булып хәтергә сеңеп калды. Сөенечле дә, фаҗигале дә булды ул хәл.

"Барып кайтыйк булмаса бер, ничә чакырдылар инде!" – дип, өйдә сөйләшенгән сүзләргә игътибар иттем: кунакка бару балачакның бәйрәме иде бит! Кунак дигәндә мин бик җәһәт идем. Яңа юллар, ят авыллар, яңа җирләр... һәммә тараф серле, кызыклы. Ә мин сергә тартыла торган тере малай идем. Ниһаять, сүз күчә-күчә төп мәсьәләгә барып җитте. "Өйдә кемне калдырырга? Мал-туарга, йорт-җиргә кем күз-колак булыр?" Әнвәр түтине ашыгыч кына чакырып алдылар. Чакырган җиргә килми каламы безнең тәмле тамак тутабыз? Нәни төенчеген тотып, иплəп атлап, кичкырын килеп тә җитте. Мин авызымны ерып: "Ә без Әндриян дәдәйләргә кунакка барабыз!" – дип кычкырдым.

Әнвәр түтигә сыер савуны тапшырып булмый, сыер малы аны санга сукмый. Күршебездә үтә уңган, ишле балалы Ипис түтиләр яши. Олы эшләрне аңа тапшырып, вак-төяген Әнвәр түтигә йөкләп, ниһаять, без ерак юлга чыктык.

Федотка бездән ике юл бара икән, берсе – район үзәге Зәй аша, икенчесе аулак, урман юллар аша – Ашыт, Әхмәт, Кадер авылларын үтеп

татты һәм "вак-төяк булмасмы?" – дип кибеткә кереп китте. Ары-бире каранып утырганда күзем бер адәмгә төште. Бер йорттан чыкты кеше, селлин-селлин атлап икенче капкага кереп югалды. Әз генә вакыттан соң тагын чыкты, карасам, Җәмәй дәдәй! Өй борынча нишләп йөри икән Түбән авылда? Мин күргәнне әни дә күрә икән, сораулы карашымны абайлап: "Җәмәй дәдәң өй борынча хәер сораша, тамагын шулай туйдыра", – дип, аңлатып бирде. Җәмәй дәдәйне кызганудан җылап җибәрдем. Мин аның ничек яшәвен, ничек тамак туйдыруын, кемнәр белән торуын моңарчы бөтенләй белмәгәнмен икән! Әни нидер аңлатты,ниләр сөйләгәне хәтеремдә калмаган, мин: "Җәмәй дәдәйгә ашарына бирик!" – дип, әнине йолыккалый башладым. Әни күчтәнәчкә төрелгән ризыклар арасыннан үзе пешергән шадра печеньены тутырып алды да миңа сузды: "Бар, улым, Җәмәй дәдәңә бир!" Тыгыз коймалы урыс капкадан чыгып килүче бичара телсез каршысына йөгердем, ташка абынып егылдым, печеньеләрне күкрәгемә кыскан идем, алар чәчелмәде, кулым буш булмаганга борыным белән җиргә бәрелдем, канады. Канаса да еламадым, Җәмәй дәдәй биленә таккан капчыгына печеньеләрне шудырды да, дәү кулы белән аркамнан какты. Сирәк сакалын селкетеп рәхмәт укыды. Аның керфексез яшькелт күзләреннән күз яше кысылып чыкты...

Әни ап-ак кульяулыгы белән минем тузанга, канга буялган борын тирәләрен рәтләп торганда әти кибеттән чыкты, без сәфәребезне дәвам иттек. Авылны чыккач кына әни миңа карап: "И, улым, дөнья йөзендә бәхетсезлекләр бик күп шул әле", – диде.

Әти белән әни үзара сөйләшеп бардылар, иген уңмаган елларны, мин аңламаган налогларны, кысуларны телгә алдылар. Җәмәй дәдәй белән очрашу аларга шулай тәэсир иттеме, әллә мондый күңелсез әңгәмәнең бүтән бер сәбәбе бар идеме, без урманны чыктык, авыл араларын үттек, авылларга кердек, туктап ат эчердек, әни коега су алырга килгән апалар белән тиз-тиз нидер сөйләште, әмма ата-анамның йөзеннән моңсулык Федотка барып җиткәнче китмәде. Бу юлы әти-әни сөйләшкән сүзләр берәм-берәм минем күңелемә кереп оялады, әниемнең: "И, улым, дөнья йөзендә бәхетсезлекләр күп шул әле", – дигән сүзен мин гомерем буе онытмадым.

Бу сүзнең хак икәнлегенә тагын бер мәртәбә шунда, Федотта ук ышанырга туры килде.

Хуҗалар безне искиткеч җылы каршыладылар. Олыларга гына түгел, безгә, бот буе малайларга да сый-хөрмәтнең иге-чиге булмады. Пилмән дә пешерделәр, тавык та куырдылар. (Дөрес, тавык боты олы малай Азат белән, төпчек малай Алмазга эләкте, мин муен кимереп калдым!) Әндриян дәдәйнең уллары Никипар белән Ибан безне элек алпавыт утары булган детдом биналарын, таллар арасында җәелеп яткан тирән буаны күрсәтеп

"Башыма кемдер күсәк белән китереп сукты!" – диде апа, әз-мәз хәлен җыеп. Олылар дару эзләргә тотынды, мин тәмам аптырашта калдым. Нинди күсәк? Кем сукты? Өйдә бездән башка беркем дә юк лабаса. Уллары Никипар белән Ибан да өйдә юк, алар Зәйдән килгән кунак абыйны буа коерыгындагы камышлыкка, үрдәк атарга алып киткәннәр. Кичке чәйгә алар да кайтып җитәргә тиеш. Апабыз елапмы-елый, бәргәләнә генә, чыдый алмый. Әндриян дәдәй чакыруы буенча берәздән өйгә фельдшер килеп керде. Биргән даруларны эчмәде Әндриян дәдәйнең җәмәгате, гел бер сүзне кабатлады: "Бәла килде безгә, хәсрәт килде. Башыбызга кайгы төште!"

Эңгер-меңгер иңгәндә, кабык арбага салып Әндриян дәдәйнең кече улы Ибанның җансыз гәүдәсен алып кайттылар. Эш болай булган икән. Зәйдән килгән сунарчы камышлар селкенгәнен абайлаган да шул төшкә төбәп атып та җибәргән... Ядрәләре туп-туры Ибанның күкрәгенә килеп кергән. Ибан аһылдап кычкырган да шунда ук җан биргән... Шул секундта әнкәсенең башына күсәк белән органдай булган. Ана сизгерлегенә тиңнәр юк!

Әндриян дәдәй сап-сары нарат такталардан улына табут ясый... Нарат ылыслары белән, чәчәкләр белән бизәлгән Ибан агач караватта ята. Аның башы очында кара яулыгын бәйләгән әнисе утыра. Ишегалдында ике кулын аермаска йозаклап, һавада селки-селки бичара сунарчы, Әндриян дәдәйнең кардәше йөри. Өй тирәсенә йөзләгән детдом балалары җыелган. Бүтән чакта шукланырга, тәртәләшергә остарган малайлар да бүген тып-тын торалар...

Мин дә шулар тирәсендә йөрим. Мин бүген фаҗиганең ни икәнен, ата-ана хәсрәтен беренче тапкыр үз күзләрем белән күрдем. Хәзер буа өстендәге тип-тигез су да, биек-биеккә менеп киткән таулар да, буа өстенә ишелеп торган агачлар да, алпавыт утары, ул яшәгән йорт болдырының түгәрәк, сырлы-сырлы бизәкле баганалары да күземә күренми. Болытлымы көн, коялымы, барыбер караңгы...

Ибанны ничек, кая күмүләре исемдә калмаган. Кайсы юлдан кайтканыбызны да белмим, хәер, моның әһәмияте бар идемени хәзер? Әче күз яшьләренә төрелгән бу көн, нарат ылыслары арасында сузылган Ибанның балавыздай йөзе, Җәмәй дәдәйнең йорттан-йортка кереп теләнеп йөрүе шушы җәемнең иң авыр хатирәләре булды шикелле.

Ибан үлгәч, Әндриян дәдәйләр Федот детдомында озак тормадылар, Багражга кайттылар. Без гаиләбез белән Урта урамның буш өенә күчтек. Аның хуҗалары кая киткән булгандыр, хәтерләмим, мәгәр аларны да бер-бер нужа, бәхетсезлек күчереп йөрткәндер дип уйлыйм. Кешеләрне урыннан-урынга күчәргә мәҗбүр иткән тынгысыз заманга кереп баруыбыз хакында әти-әниләрнең кеше югында, шыпырт кына сөйләшүләре истә калган...

Китап күңел үстерә

Иманга тугрылык

"Ватан сугышы башланган елны мин Батыр педучилищесына укырга кердем, анда татар бүлеге бар иде. Татар бүлегендә укыганда мин үземне акбүз атта сыман хис иттем. Ә менә татар хәлфәләре фронтка китеп беткәч, без – татар шәкертләре үксезләр хәлендә калдык. Безне – татарларны чуашча укырга мәҗбүр иттеләр: баш тартсагыз, педучилищедан чыгарабыз, диделәр. Менә шул вакытта мин чуашча өйрәнә башладым. Ләкин туган телдә фикер йөрттем. Урыс-улак арасында япа-ялгызым озак еллар яшәсәм дә, әниемнең газиз улы, татар булып калдым", – дип яза үзенең "Иман кәрваны" дигән китабына кереш сүзендә шагыйрь Кави Латыйп.

Әйе, шагыйрь тормышта гына түгел, иҗатында да үз иманына тугры калды.

Бер каһәр җан, бер зәһәр җан
күзгә карап әйтте:
"Милләт дип яшәвең,
яшьнәвең юкка, бушка.
Сине мин җиңәчәкмен,
Сукага җигәчәкмен.
Үзеңне телсез, динсез, денсез
калдырачакмын,
учакта яндырачакмын.
Син бетәчәксең,
дөньядан китәчәксең.
Ә мин калачакмын.
Идел-йортыңны,
нәсел-нәсәбең белән,
яулап алачакмын..."
Шул очрашудан соң
өчләтә мин сакмын.

Шагыйрьнең байлыгы

Куларбамны тартып узган чакта,
Бөкерәеп, алга сузылып,
Икешәр дә өчәр машиналы
Күршеләрем кала кызыгып, –

дип яза Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев күптән түгел Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан "Уйлый күңелем төрлесен..." дигән яңа китабында. Уйланырсың да шул. Башлар әйләнерлек, сөйли башласаң телләр бәйләнерлек, үзе авыр, үзе кызык заманда яшибез бит. Безнең бу гасыр ахырындагы "тамашалар" иң элек шагыйрьнең ярсу күңеленә, мең-мең җәрәхәтле йөрәгенә килеп бәрелә дә, яңа җәрәхәтләр ясый. Түзә мескен йөрәк! Мең-мең җәрәхәттән торса да, җырлый тагын үзе. Дөрләп янаяна җырлый, чөнки җырламый тора алмый, чөнки ул әле нәрсәгәдер өметләнә, адәм баласына яхшылык тели, күңелен кузгатып булмас микән ди...

Күрер күзгә дә бик күркәм, эчтәлеге белән дә бик бай бу китапта шагыйрьнең төрле елларда язылган иң матур лирик һәм юмористик шигырьләре, балалар өчен язылган кызыклы әсәрләре, җырлары урын алган. "Уйлый күңелем төрлесен..." китабы шигырь сөюче дусларыбыз өчен матур бүләк булган. Шагыйрьнең куларбасында "байлар, бизнесменнар кызыгып карап калырлык" байлык бихисап, үзе әйтмешли – "бер капчык"!

Фирая ЗЫЯТДИНОВА.

Киңәш-табыш

Чәй агуыннан сак булыгыз

Пешерелгән чәй, бераз вакыттан соң, томыкланып кала һәм юка элпә белән каплана. Моны нәрсә белән аңлатырга?

А. САЛИХОВА.
Рязань.

Бу хәл чәйнең түбән сыйфатлы булуын күрсәтә. Хәзер азык-төлек базарлары сыйфатсыз продукция белән шыплап тулган. Шуңа күрә чәйне базардан яисә урамдагы палаткадан алган очракта, оялмагыз, сыйфат сертификатын күрсәтүне таләп итегез.

Чәйне пешергәннән соң, берничә сәгать үткәч, эчәргә тәкъдим ителми. Андый чәйнең файдасыннан битәр, зыяны күбрәк. Борынгы кытайлар, мәсәлән, шушы рәвешле үзләренең дошманнарын агулаганнар.

Грипптан котылыйм дисәң...

Грипп – хәтәр авыру. Ул организмны какшатып, төрле матавыклар китереп чыгарырга мөмкин. Бу сырхаудан саклануның берәр ышанычлы чарасы юкмы икән?

К.САБИТОВА.
Арча.

Чыныгу һәм даими С витаминына бай булган ризыклар белән туклану яхшы нәтиҗәләр бирә. Халык медицинасында да грипппка каршы дәвалар күп. Борынгы греклардан килеп чыккан бер чара тәкъдим итәбез. Аны кулланганда гриппны бөтенләйгә онытырга мөмкин.

Рецепт бик тә гади. Ярты лимонны кабыгы белән, уртача зурлыктагы 7-8 бүлемтек сарымсакны тәлинкәдә (сулары акмасын өчен) вак итеп турыйсың. Аннары аларны ярты литрлы пыяла банкага салып, аны кайнатып суытылган су белән тутырасың һәм 4 көн караңгы урында тоткач, суыткычка куясың (сарымсак белән лимонны алырга кирәкми).

Катнашманы көнгә бер тапкыр иртән, ашарга 20 минут кала бер аш кашыгы эчәргә кирәк. Балаларга исә яшенә карап киметергә мөмкин. Сыеклык банкада азая башлагач, дәваның икенче банкасын әзерләп куярга кирәк. Аны эчкәндә өзеклек булырга тиеш түгел. Сыеклыктан сарымсак исе килми.

Шунысына да игътибар итегез: ашказаны, эчәк авырулары (энтерит, энтероколит, ашказаны, уникеилле эчәк ярасы һ.б.) белән интегүчеләргә бу сыеклыкны эчәргә ярамый.

Шаян орлыклар

Ир-ат организмында сперматозоидлар өлгереп җитү өчен өч тәүлек тирәсе вакыт кирәк, дип укыган идем. Шуңа күрә без ирем белән көн дә мәхәббәт белән шөгыльләнергә булдык. Шулай эшләгәндә балага узудан сакланмаска да була бит?

АЛИСӘ.
Казан.

Мондый "алым" белән сакланырга тәкъдим ителми. Чөнки сперматозоидларның өлгерү вакыты уртача гына алынган. Әйтик, җенси яктан куәтле ир-атлар сперматозоидларының өлгерү вакыты күпкә аз. Кайвакыт икенче тапкыр якынлык кылганда да йөккә узарга мөмкин.

Шагыйрә Гөлшат ЗӘЙНАШЕВАга 70 яшь

Бер кыз бала җыр чыгарган...

Аның белән мин беренче тапкыр 1966 елда, Минзәләдә эшләгән чагымда таныштым. Ләкин әле аңарчы, очрашып күрешкәнчегә кадәр, Гөлшат Зәйнашева исемен күп тапкырлар ишеткән, аның шигырьләренә язылган җырларны тыңлап сокланган идем. Әле дә хәтерлим, 1957 елда безнең сәнгать һәм әдәбият әһелләре Мәскәүгә, татар әдәбияты-сәнгате көннәренә киттеләр. Анда Ифрат Хисамовның "Хөршидә-Мөршидә" дигән җыры буенча куелган сәхнә күренеше дә бик зур уңыш белән узган. Җырның шигырен Гөлшат Зәйнашева язган. Менә шул җырлы-биюле күренешне безнең Минзәлә җыр-бию ансамбле дә сәхнәләштерде. Халык шулкадәр яратты бу әсәрне, һәрчак алкышлап, гөр килеп кабул итә иде. Авылның иң гүзәл кызлары Хөршидә-Мөршидә кебек сылуларны сурәтләгән авторның үзен күрү теләге туганын хәтерлим.

1966 елда мин Минзәләдә район мәдәният бүлеге мөдире булып эшли идем. Гөлшат Зәйнашеваның Сарман-төймә" (халык көе), "Күл буена килсәң иде", "Яшь гомер" (Зиннур Гыйбадуллин көйләре) кебек җырларны гына искә алыйк. Күпме яшьләр, күпме буыннар җырлап үсте аларны!

Ә инде Сара апа Садыйкованың соңгы җырын – Гөлшат Зәйнашева шигыренә язган "Идел суы ага торыр" дигән җырны искә алмыйча һич мөмкин түгел. Яшәүгә, тормышка, халкыбыз язмышына мәдхия булып әверелде бит ул җыр һәм аны беренче булып Хәйдәр Бигичев җырлады. Гөлшат апа композиторларга карата да һич әрсез булмады, алар Гөлшат апаның шигырьләрен җыр өчен үзләре сорап алалар иде.

Гөлшат Зәйнашева Сара апа Садыйкова белән аеруча дус булды. Алар бергәләп бик күп матур җырлар иҗат иттеләр. Әмма аларның бу дуслыгы иҗат дуслыгы гына да түгел, ана белән кыз,

Минзәлә якларында туып-үсүен ишетеп беләм. Әле кулымда аның 1958 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан "Тыңларсыңмы җырларымны" дигән китабы да күптәннән йөри. "Рамай" исемле пьесасының да сәхнәләштерелүен беләм. "Күңелле сәхнә", "Мәктәп сәхнәсе", "Эстрада", "Клуб сәхнәсе" кебек күмәк җыентыкларда чыгып килгән әсәрләрен Минзәлә үзешчәннәре гел кулланып кына торалар. Әле соңрак Минзәлә театры аның "Кем гүзәл?" исемле пьесасын да сәхнәләштерде. Менә шундый бер вакытта, якташлары белән очраштыру йөзеннән, мин Гөлшат апа Зәйнашеваны Минзәләгә чакырдым. Алар Сара апа Садыйкова белән бергәләп килергә булдылар. Сара апа Гөлшат Зәйнашева шигырьләренә матур-матур көйләр-җырлар чыгарган иде. Менә шулай итеп, Гөлшат апа белән утыз елдан артык таныш икәнмен инде мин. Бу танышлык, ялгышмасам, чын иҗади дуслык булып, кешеләрчә, хәтта туганнарча дуслык булып әверелде.

Бу язмамда мин Гөлшат апаның зур, киң кырлы иҗатын яктыртырга тырышмыйм, бу язма – үзенә күрә бер истәлек, үзеңә бик тә якын булган кешенең, тынгысыз иҗат кешесенең бик күркәм сыйфатлары, табигате турында уйлану гына.

Гөлшат апаны чын мәгънәсендә табигать баласы дип беләм мин. Бер карасаң, шагыйрә бик тә туры сүзле – күңелендәгесен әйтә дә сала. Әмма ул, шул ук вакытта, бик тә нечкә һәм йомшак күңелле, сабый җанлы. Аның һаваланганын, мактанганын, йә булмаса, үзен кемнәрдер алдында эре тотканын һич күрмәссең. Аның бу сыйфатларына мин һәрчак соклана килдем. Әле Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры булып эшләгән чакларымны искә алам. Директорның аның үз вазифалары, үз вәкаләтләре бар, дигәндәй... күп драматурглар керә инде ул директор янына. Кайсысы, пьесасын күтәреп, ачуланышырга керә, кайсысы мәсьәләне "дусларча" хәл итәргә дип килеп керә. Әйе, без Гөлшат апа белән бик якын дуслар идек, дидем. Әмма аның янына беркайчан да "дуслыктан файдаланып" әсәр алып кергәнен, йә булмаса, нишләп минем фәлән пьесамны куймыйлар, дип тавыш күтәргәнен хәтерләмим. "Менә бер әйбер язган идем бит әле мин, укып кара әле, ошармы, юкмы", – дип тыныч кына, тыйнак кына әйтә иде ул. Бер-бер шигырь язса да, нәкъ шулай ди: тыңлап кара әле, сиңа ошар микән, дип киңәш кора.

Гөлшат апаның шигырьләренә иң талантлы, иң олпат композиторларыбыз дистәләгән-йөзләгән җырлар язды. Әгәр уйлый китсәң, үзе бер дөнья бит бу! Александр Ключаревның "Туган җирем Татарстан"ын, Рөстәм Яхинның "Китмә, сандугач"ын, Мансур Мозаффаровның "Менәргә иде Урал тауларына" дигән җырын, "Зәңгәр

туган белән туган арасында гына була торган гаҗәеп бер мөнәсәбәт иде. Сара апа аз гына авырып, күңелсезләнеп китсә дә, Гөлшат Зәйнашева шундук аның янына йөгерә, үзе генә белгән әллә нинди үләннәрдән чәен кайната, ничек итсә итә – аякка бастыра Сара апаны. Сүз уңаеннан шуны да әйтим әле: Гөлшат апа беркайчан да хәзерге заман таблеткаларына, дару төймәләренә ябышып ятмады, ул үзе җыйган дару үләннәрен, халык медицинасы ысулларын артыграк күрде, хәзер дә шулай. Әйтәм бит, чын-чынлап табигать баласы ул һәм менә шушы сыйфаты аның ихлас җырларында да тулысынча чагыла.

Гөлшат апаның Сара Садыйкова белән якыннан, бик якыннан аралашып яшәвен әйткән идем бит әле. Сара апага тугрылык Гөлшат Зәйнашеваның күңелендә еллар буена һич үзгәрми сакланган.

Бүгенге көндә Сара Садыйкованың иҗтимагый фонды эшендә, сөекле композиторыбызның исемен һәм иҗатын мәңгеләштерүдә армый-талмый эшләүчеләрнең берсе нәкъ менә Гөлшат Зәйнашева булыр.

Гөлшат апаның янә дә бер сыйфатын беләм. Ул беркайчан да, үзенә, үзенең иҗатына игътибар сорап, түрәләрдән һәм югары оешмалардан ни дә булса үтенеп-ялварып йөрмәде. Соңгы елларга тикле, иҗатының иң шаулап-гөрләп үскән бер чорында, бер бүлмәле "хрущевка"да язды, яшәде, балалар һәм оныклар үстерде – баш имәде. Ә бит үзе халык тарафыннан танылган шагыйрә, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, халыкның сөеклесе-сандугачы...

Гөлшат апаның табигатендә, холкында мине иң сокландырган сыйфатларның тагын берсе шул: уй-фикерен ашыгып-кабаланып әйтмәс, киңәш сораган кешегә һәрчак акыллы, төпле киңәш белән ярдәм итәргә тырышыр. Минем үземнең дә аның янына киңәшләшергә килгән чакларым күп булды. Сара Садыйкованың иҗтимагый фонды эше буенча инде күбрәк. Менә шундый чакларда Гөлшат апа, туктале, Әзһәр, менә болайрак итсәк ничек булыр икән, дип үз сүзен әйтә дә куя. Фикерен көчләп такмый, киңәшләшү рәвешендә әйтә ул аны. Һәм, ни гаҗәп, Гөлшат апаның шул сүзе дөрескә чыга да куя бит. Шуңа күрә мин аны кайчак, күрәзәче апа, дип тә атап йөртәм.

Миңа иҗат кешеләре белән элек тә еш аралашырга туры килде, хәзер дә еш була андый аралашулар. Гаепләп әйтүем түгел, әмма көндәшлек хисе бар инде ул, бар иҗат әһелләрендә. Матур итеп көнләшү бар, өнәмичә көнләшү бар. Ә менә Гөлшат апаның теленнән-авызыннан минем беркайчан да көнчелек сүзе ишеткәнем юк. Киресенчә, иҗатташ дусларының һәр уңышына балаларча сөенгәнен күрсәгез иде сез аның! Каләмдәшләре хакында һәрчак җылы сүз әйтер, матбугатта язып чыгарга вакыт табар, аларның өйләренә шалтыратып, яисә үзләрен күреп мактар-котлар.

Әлфия Афзалованың "Үзем турында" дигән бик тә матур, мәгънәле һәм тирән эчтәлекле китабы басылып чыкты. Бу китапны туплауда, аны әдәби эшкәртүдә Әлфия ханымга нәкъ менә Гөлшат апа ярдәм итте, ихластан ярдәм итте.

Гөлшат апаның юкка-барга зарланганын күргәнем юк минем. Хәер, моннан бик күп еллар элек борчылып әйткән иде: "Менә, радионың худсоветында бик матур бер җырны карадылар әле. Шунда бәйләнделәр бит шигырьгә: Кояш гомере булмый бит ул, диләр. Нишләп булмасын инде Кояшның гомере, ә?" Ни генә булмасын, Гөлшат Зәйнашева шигыренә Фәтхерахман Әхмәдиев язган ул җыр заманында бик тә популяр булды, аны балалар да, яшьләр дә, өлкәннәр дә яратып җырлады.

Бер кыз бала җыр чыгарган,
Багышлап әнисенә.
Икәү бергә җырлыйк, диеп,
Өйрәткән энесенә.
Кояш, кояш мәңге балкый,
Мәңге нур сибә.
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа...

Никадәр гади сүзләр, никадәр изге кичерешләр бу җырда.

Бу көннәрдә мин Гөлшат апаның иҗат активлыгына, һәрчак хәрәкәттә булуына тагын бер кат сокланам, шатланып бетә алмыйм. Кай арада диген, менә гел искәрмәстән, гел көтмәгәндә олы бәйрәме дә килеп җиткән! Искәрмәстән дип әйтүем дә шуннан: Гөлшат апа, кайчан гына карама, гел арабызда, шат йөзле, һәрчак елмаеп торыр, өеннән бер чыгып китсә, гәзит-журнал редакцияләренә сугылыр, Сара Садыйкова фондына кереп чыгар, бер-бер эш уйлап табыр, бер-бер мәсьәлә кузгатыр. Аның армас-талмас йөрәгенә, тынгы белмәс җанына мәдхия укыйсы килә.

Алдан әйткәнемчә, бу язмада мин Гөлшат апаның иҗаты турында сөйләүне максат итеп куймадым. Мондый зур иҗатка бәя бирү – белгечләр эше, әдәбият галимнәре эшедер. Әнә бит, Госман ага Бакир әле 1957 елда ук, моннан кырык ел элек, Гөлшат Зәйнашева турында, талантлы автор үсеп килә, аның каләме эшли белә, дип язып чыккан. Мондый бәяне Гөлшат апа үзенең иҗаты, иҗат гомере белән тулысынча раслап яшәде һәм раслап яши. Ул үз шигырьләренә язылган җырларны үз балалары кебек якын күрә, оныкларыдай якын итә. Ә мин менә шундый якташым барлыгына, татар хатын-кызлары арасында Гөлшат Зәйнашева кебек каләм ияләре булуына горурланып яшим һәм, һич тә икеләнмичә, аны җырлар алиһәсе дип атыйм.

Әзһәр ХӨСӘЕНОВ,
Сара Садыйкованың иҗтимагый фонды рәисе.



Батулла баганасы

Витамин мәсьәләсе

Рәис Даут белән аның хатыны Диләрә ханым һәм Нурихан Фәттах белән аның хатыны Руфинә ханым берберсенә кунакка йөрешәләр икән. Бер мәҗлестә Диләрә ханым кунакларны алма ашарга кыстый башлый:

– Ашагыз, С витамины! – ди.

– Алмада С витамины булмый! – ди Фәттах.

– Нишләп булмасын, Нурихан! – ди хуҗабикә. – Алмада С витамины бар!

– Юк! – ди Фәттах. – Алмада С витамины булмый.

– Гомер буе витаминнар белән эш итеп, мин алмада С витамины булганын белмәскә!

– Гомер буе китап укып та алмада С витамины юклыгын мин дә белмәскә тиешмени?

Руфинә ханым иренең аягына баса: янәсе, хуҗабикә белән сүз куертма.

– Типмә аякка, – ди Фәттах. – Алмада С витамины юк.

Рәис хатынының тәпиенә баса: янәсе, кунак белән сүз куертма.

– Рәисем, нигә аякка тиясең! Алмада А, В, С витаминнары бар!

– Алмада С витамины юк! – ди Фәттах.

Уңайсыз тынлык урнаша. Хуҗабикә:

– Җә, ярый, булмаса булмас! Алма ашап үлгән кеше юк әле, ашагыз! – ди.

Шушы бәхәстән соң бу ике гаилә йөрешмәс булганнар, ди.

Сөенеч

Гомер буе сәгатьсез йөргән Нурихан Фәттах, ниһаять, сәгатьле була. Ләкин сәгате бик тиз ватыла. Төзәттерергә илтә бу моны. Унбиш көннән соң сәгатен барып та ала.

– Бездә сыйфат билгесе өчен көрәш, – ди оста. – Сәгатеңне шәп төзәттек.

Сыйфатлы төзәтелгән сәгатьне тагып, Фәттах өенә кайтып китә. Ничә минут кайттым икән, дип Фәттах сәгатенә карый – сәгать йөрми. Тагын китә бу остаханәгә. Сәгатьне алып калалар. Тагын атнаун көннән сәгатьне хуҗасына тапшырганда, оста:

– Менә дигән сәгать бу! – ди.

Фәттах тагын сәгатен тагып кайтып китә. Озак та узмый, сәгать тагын туктый. Төзәттерергә алып барганда, караклар трамвайда Фәттахның сәгатен чәлдерәләр, сәгать юклыгын күргәч, Фәттах:

– Һай, рәхмәт каракларга! Һай рәхмәт оста кулларга. Рәхәтен күрегез шул сыйфатлы сәгатемнең! – дип сөенә.

Ринат МӘННАН кытыклары

"Алтынчы сыйныфта укыганда беренче шигырьләремне яза башладым..." – дип сөйли РИНАТ МӘННАН. Әлбәттә, ул яшьтә күпләр мәхәббәт турында яза. Һәм инде башка шагыйрьләрнең мәхәббәт турындагы шигырьләрен дә яратып укый. Бу ярату Ринатны пародия жанрына алып килә. Ринат үзе – Чистай ягыннан, бүгенге көндә Казанда яши, табиб булып эшли. "Мин – 1946 елда, эт елында, февраль аенда туганмын, – ди Ринат Мәннан. – Күпләр пародия-эпиграммалар язуны кем беләндер "этләшү" дип уйлый. Әмма бу "этләшү"дән түгел, ә бәлки, шигырьне, шигъриятне яратудан килә..."

Пар(О)дөяләр

Ит базары

Йөрәкнең төрлесен беләм мин:
Кыюын, куркагын, сафларын...
Йөрәгем, белмим, син ниндидер.
Тик беләм: мин сине сатмамын.

Әдхәт СИНУГЫЛ.

Дуңгыз, сыер йөрәкләре
Бик күп иде базарда.
Бәясе, әйтим, төрлечә,
Тавыкныкы – арзанга.
Озак йөрдем шул тирәдә,
"Әйдә, рәхим ит!" – диләр.
Минекенә җитмиләр шул,
Минекенә җитмиләр!
Кыю, куркак, сафмы? – белмим,
Ләкин әйттем аларга:
Сатмыймын мин йөрәгемне
Хәтта яшел долларга!

Табыш

Аерып булмас безне. (Археологлар,
Бәлки, безне бергә табарлар?)
Гоби чүлендә, бер-беренә ябышып,
Ташка әйләнгән динозаврлар!

Роберт ӘХМӘТҖАН.

Кайда гына казымыйлар
Безнең археологлар.
Казып йөри торгач, безне
Сөбханалла, таптылар!
Гәүдәләребезне биш кат
Чүпрәк белән сөрттеләр.
Соңыннан пумалаларын
Битебездән йөрттеләр.
Таныдылар, ахры, мине,
Күңелдән сөенделәр:
– Бу олуг шагыйребезне
Тагын бер сөртик, диләр!
Ләкин шулчак күреп алдым
Ике лом һәм борауны.
– Ай-һай-һай, бу коралларсыз
Аерып булмас боларны!
Таш булып каткан йөрәгем
Жу итеп куйды кинәт.
Тәки бу археологлар
Аералар бит, димәк...

Эпиграммалар

Вәлиләргә

Разил, Равил, Мансур, Римзил -
"Псевдонимсыз" Вәлиләр.
Шигырь белән, җор сүз белән
Халыкны дәвалыйлар.

Рамил Курамшага

И җырлатты да Илһамны,
Менә инде тамаша, -
Тавышы сеңеп калдымы -
Җырлый хәзер... Курамша.

Үз-үземә

Ни әйтим үзем турында?
Үз эшем яхшы беләм:
Ике-өч рифма белән дә
Поэма язып бирәм,
Кирәксә...

Урамнарны урадым

Йөрим Казан каласында
Искә килә Тукай, Такташ...
Әле генә эз калдырды
Асфальтында Рәдиф Гаташ.
Әнә, юлны чыгып бара
Арба тартып Әхәт Гаффар,
Арбасында – романнары,
И тырыш кешеләр дә бар!
Әнә, бара аннан артта
Мыштым гына Госман Садә.
Куып җитәргә ашыкмый -
Аңа ярый, нишләсә дә!..
Монысы кем – күн пәлтәдән? -
Ә, таныдым, бу – Фазули.
Ул да ашыкмыйча атлый -
Җырларына сүзләр эзли.
Күңелләрем җылынды бит -
Шагыйрьләргә юк аптыраш.
Йөрим Казан каласында,
Искә төшә Тукай, Такташ...

Сала саен мең дә бер мәзәк

Минем күрше Марат эштән кайтканда, кичке табын, гадәттәгечә, әзер иде. Ул, өс-башын салып, тиз генә юынып алды да шунда – аяк астында буталып йөрүче быел биш яшен тутырган Ләйсәнне кулына алып сөйгәннән соң, өстәл янына утырды.

Башка көннәрдәгечә, хатыны белән уен-көлке сөйләшә-сөйләшә, ашыйэчә башладылар. Тик "тел бистәсе" генә бүген, нигәдер, әтисенә серле итеп карап куйгалаудан гайре, һичбер сүз эндәшми.

– Ни булды, кызым? – ди Марат, аның көлсу чәчләреннән сыпырып. – Әллә чирләп киттеңме?

Ләйсән башын иеп, тез өстендәге бәләкәй кулларына карап утыруын белә. Әмма бу хәл әлләни озакка бармый. Ул, күзләрен тутырып әтисенә кабат карый да ялварулы тавыш белән:

– Әти, тагын кайчан аракы эчәсең инде?! – ди.

Марат бермәл ни әйтергә белмичә тора. Узган атнада, моннан алдагы өч ай өчен берьюлы хезмәт хакы алгач, сөенечтән, хезмәттәшләре белән бергә ярыйсы гына кунак булды ул. Өйгә кайтышлый кызына төм-томнар да, шул исәптән шоколад та сатып алды.

Бу хәлгә Ләйсән бик сөенгән иде. Аракы эчсә, әти тагын шоколад алып кайтыр иде, дип уйлавы икән сабыйның.

– Минем шоколад ашыйсым килә! – ди дә ул, әтисенең алдына ук кереп утыра.

Рәхим БАКИРОВ.

Балык Бистәсе.

Тәкә

(Мәсәл)

Көне буе чабып көтүендә
Кайтып килгән вакыт бик арып.
Артык уйламыйча юл читеннән
Тәкә иартеп кайткан бер Сарык...
Кырда яшәгәнме – үзе арык,
Йон өтелгән, туңган – калтырый.
Буреданме качкан: мөгез сынык,
Койрык өзек – арты ялтырый.
Башта Сарык аны киендерде
(Җил тимәсен, диеп, йонсыз бит...).
Хайван, тоягын да кыймылдатмый,
Һаман печән ашый юньсез. Тик
Бүген аңа гына риза түгел,
Беркөн, тереп мөгез сыныгын,
Мәэлдәде, "әче су" да торсын
Аш астына, шунда ныгырмын!
Шул көннән соң өзерләнде аңа
"Әче су" да, яхшы ашы да.
Кая барсын, кемгә зарлансын соң
"Җил уйнагач" Сарык башында?
...Белмим, нәрсә булып бетәр иде
Әҗәл буып тотып якасын,
Әйтте: "Әче суың" ташламасаң,
Җир астына кереп ятасың!..
Нык шүрләде Тәкә, "судан" бизде
(Хайваннар. да, тели яшәргә...).
Шунысы начар, бүген зур сарайда
"Урын җитми" килгән яшьләргә.
"Азык әрәм китә!
Тын кысыла!
Һава җитми, Сарык, күрәсең!"
Әмер бирде: кабат яшь бәрәннәр
Сараема атлап кермәсен!
...Бәлки, вакыт килмешәк Тәкәне
Чыбыркылап, ярып куу ачык басуга?
Азыгы да җитәр, тән ачылыр,
Салкын җилдә бетәр ачу да!
Безнең тормышта да "Тәкәләр"нең
Өс бетәйсә, туйса тамагы,
Төп хуҗалар өчен аш кызганыч,
Тар күренә иркен "сарае".

Шакирҗан АХУНОВ.

Тамаша заллары чакыра

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры

23 гыйнвар – "Мәхәббәт хатирәсе" (Ф.Бүләков).

24 гыйнвар – Аяз Гыйләҗевкә 70 яшь тулу уңеннан тантаналы кичә.

25 гыйнвар (көндез) – "Кылый Кирам балдагы" (Аманулла).

25 гыйнвар (кич) – "Җимерелгән бәхет" (Н.Островский).

27 гыйнвар – "Йөрәк маем" (Т.Миңнуллин).

29 гыйнвар – "Күрәзәче", премьера (З.Хәким).

30 гыйнвар – "Каениш, көндәш һәм башкалар" (Г.Камал).

31 гыйнвар – "Хуҗа Насретдин" (Н.Исәнбәт).

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры

23 гыйнвар – "Син бит минем бергенәм" (И.Мәхмүтова).

23-29 гыйнвар – МХАТ театры гастрольләре.

Зур концерт залы

23 гыйнвар – Татарстан Республикасының халык уен кораллары оркестры концерты. Солистлар – Е.Михайлова, В.Киреев, Г.Мөхәммәтдинова, О.Вайспекер. Оркестр солистлары – В.Булыгин, В.Захаров, С.Помясов. Дирижер А.Шутиков.

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры

24 гыйнвар – "Спящая красавица" (П.Чайковский).

25 гыйнвар – "Алтынчәч" (Н.Җиһанов).

28, 29, 30, 31 гыйнвар – "Белоснежка и семь гномов" (К.Хачатурян).

Курчак театры

23 гыйнвар – "Кот в сапогах" (Ш.Перро).

24 гыйнвар – "Кот в сапогах" (Ш.Перро).

25 гыйнвар – "Золушка" (Ш.Перро).

28 гыйнвар – "Кот, петух и лиса" (А.Янкелевич).

29 гыйнвар – "Җен кызы" (Зөлфәт).

30 гыйнвар – "Беда от нежного сердца" (В.Соллогуб).

31 гыйнвар – "Дюймовочка" (Х.Андерсен).

Татар яшьләр театры

20 гыйнвар – "Мисс убырлы" (Ф.Галиев), Яшел Үзән шәһәре, 13 нче балалар бакчасы; Теләче районының Шәтке авылы.

20 гыйнвар – "Бер көрешү үзе бер гомер" (Ф.Яруллин), Теләче районының Шәтке авылы.

22-29 гыйнвар – "Мисс убырлы", "Уеннан уймак" (Ф.Галиев, Ш.Зәйни), Әтнә районында гастрольләр.

Һенрих Һейненең

"Алар качып кына шәраб эчә..."

Үткән ел без татар әдәбиятының олуг әдипләре – шагыйрь Мөхәммәдьярның тууына – 500, Габделҗаббар Кандалыйның – 200, Г.Ибраһимовның 100 ел тулу көннәрен зур горурлык һәм тирән хөрмәт хисләре белән билгеләп үттек. Әйе, татар халкының да кешелек дөньясы алдында горурланып торырлыгы бар: аның бөек шагыйрьләре-әдипләре үлемсез. Аларны да бөтен дөнья белергә тиеш... Шул ук вакытта татар халкы үзе дә җиһандагы һәрбер милләтнең бөек шәхесләрен онытмый, һәр халыкның рухи-мәдәни байлыгын үзләштереп вә җанына сеңдереп, аралашып яши. Бу туганлык-арадашлык та нәкъ менә әдәбиятта аеруча калку чагылыш таба. Әйтик, без бөек Тукаебызның Һейне әсәрләрен яратып укыганын һәм тәрҗемә иткәнен дә беләбез. Чөнки Тукай үз инешендә генә чупырдап ятырга теләми, ә бәлки зур суларга – диңгез-дәрьяларга барып кушылырга омтыла. Әйе, Сибгат ага Хәким әйтмешли, Тукаебыз да "Өйрәнгән, Пушкинны да, Һейне, Шиллерын да, Байронын да өйрәнгән. Шагыйрь җаны шулай куша, шулай таләп итә". Әмма ул барыбер үзе булып калган. Әдәбиятта, шигърияттә интернационализм ул нәкъ менә милли үзенчәлекләрне тагын да кадерләбрәк саклау һәм милли үсеш-яңарыш өчен дә гаять зарур. Безгә кадәр дә ул шулай булган, бездән соң да шулай булыр.

Күптән түгел бөек нимес шагыйре Һенрих Һейненең дә тууына 200 ел булды. Ул 1797 елның 13 декабрендә Дюссельдорф шәһәрендә тукымалар белән сату итүче вак сәүдәгәр Самсон Һейне гаиләсендә туган. Шагыйрьнең ватаны ул чагында Аурупаның иң артта калган илләреннән берсе була: XYIII гасырда аны "Герман милләтенең изге Рим империясе" дип йөрткәннәр. Һенрих Һейненең бөтен иҗади эшчәнлеге Германиянең якты киләчәге, нимес халкының азатлыгы өчен көрәшүе белән бәйләнгән. Аның әсәрләре кеше шәхесенең ирекле һәм гадел җәмгыять турындагы хыялларын чагылдыра. Алар дөньядагы демократик һәм гуманистик көчләргә гадел социаль үзгәртеп корулар юлында үзенә бер рухи терәк булырлык. Һенрих Һейне – даһи лирик-романтик һәм бөек публицист. Аңарда гүзәллек хисе белән социаль гаделлек хисе бер-берсеннән аерылгысыз рәвештә үрелгән. Аның гаҗәеп үткен сәяси һәм сатирик шигырьләре заманында хәтта Маркс белән Энгельсның да игътибарын җәлеп иткән... Ләкин ул хакимияткә омтылучы практик сәясәтче түгел, ә бары тик бөтен гомере буена Кеше язмышы, Кеше һәм Җәмгыять турында уйланып, газапланып яшәүче нечкә хисле Шагыйрь булып кына кала. Һейне дөньяга искиткеч мәхәббәт һәм бер үк вакытта коточкыч ирония белән караган...

1830 елгы Француз революциясеннән соң, Һейне, әлеге вакыйгалар белән рухланып, һәм бигрәк тә, хаким сыйныфларның үзенә карата теләктәш булмавын аңлап, бөтенләйгә Парижга күчеп китә. Анда ул шул чорның күренекле шәхесләре белән якыннан аралашып яши, актив иҗат итә. Шунда ул гади крәстиән кызы Матильдага өйләнә. Матильда исә нимес телен дә, мәшһүр иренең иҗатын да белми, шулай да Һенрих Һейне гомере буе хатыны турында кайгыртып, аны яратып һәм канәгать булып яши.

Шуны да әйтергә кирәк, Һейне баштарак бик радикаль карашларда тора. Җәмгыятьне тамырыннан үзгәртеп коруга омтылып, ул реформалар юлын кискен кире кага. Әмма бу ниндидер катып калган катгый сәяси принцип түгел, бары тик аның нәкъ менә шагыйрьләрчә бунтарь йөрәкле булуыннан гына килгәндер, дигән фикер дә туа. Чөнки шагыйрьнең эчке дөньясы гаҗәеп каршылыклы хисләр белән тулы. Чөнки ул яшәгән дөнья үзе, аның бөтен мохите-тирәлеге шундый ук каршылыклар белән кайнап тора.

Парижда яшәсә дә, ул Германия турында бер генә минутка да исеннән чыгармый, эмиграциядә яшәп иҗат иткән бөтен әсәрләре аның үз ватанын чиксез яратуы, аның өчен тирән борчылуы һәм сагыну хисләре белән сугарылган. Үләр алдыннан Берлинга кайтырга рөхсәт сорап язса да, Пруссия хөкүмәте аның үтенечен кире кага һәм кайта калса, кулга алу белән яный.

Һейне турында дуслары, таныш-белешләре, гомумән, замандашлары язып калдырган истәлекләрдән күренгәнчә, Һенрих Һейне бик тә нечкә күңелле, җаны тиз җәрәхәтләнүчән кеше, шул ук вакытта, гаять үткен-зәһәр телле, бик тә каршылыклы шәхес була. Аның холкындагы һәм дөньяга карашларындагы гаять четерекле моментлар, бәлки аның яһүд булуыннан һәм үзенә карата әйләнә-тирә дөньяның да нәкъ менә шулай четерекле мөнәсәбәттә торуыннан да килә булса кирәк. Бер караганда, ул гаҗәеп юмарт, икенче карашка бик тә исәпле, меркантиль кеше, бер карыйсың, ул искиткеч аристократ һәм шунда ук халык иҗатына һәм тел байлыгына мөкиббән киткән, гади хезмәт халкына теләктәш рухтагы демократ шагыйрь, бер карыйсың, ул искиткеч патриот һәм шул ук вакытта, гомерлек эмигрант... Дин белән дә шулай: башта ул динне бөтенләй кире кага, ә соңыннан, инде паралич сугып, озак еллар хәрәкәтсез авырып яткан көннәрендә, Аллага "кайтып егыла". Бер караганда, ул менә дигән турылыклы дус, икенче карыйсың – шул ук дусларыннан ачы вә зәһәр көлүче сатирик... Бер яктан, Маркс белән хатлар язышып торган "кызыл" сәясәтче, икенче яктан, шәхси кичерешләренә баткан, газапланып бәрелеп-сугылып яшәүче ялгыз бер индивидуалист... Кыскасы, бөтен җаны-тәне белән – Шагыйрь. Ләкин аны мондый каршылыклы газаплар эченә, оҗмах белән тәмуг арасына да нәкъ менә шул дөнья үзе, аның әйләнә-тирә мохите тартып керткән. Чөнки ул артык акыллы һәм белемле – ягъни бөтенесен дә аңлый, уйлана; чөнки ул артык нечкә хисле – һәммәсен дә сизә, үз йөрәге аша үткәрә...

Һенрих Һейне гомере буе бөек шагыйрьләрдән өйрәнә, аларга сокланып һәм кызыгып карый. Аның, мәсәлән, үзенең дә бөек Шиллер яки Һете шикелле үк, нимес халкының "үз шагыйре" булып йөрәгенә кереп каласы килә. Ул инглиз шагыйре Байронга да кызыгып карый, аңардан үрнәк алып, үзенең сәяхәт көндәлекләрен яза һәм анда заманының чынбарлыгын үткен чагылдыра. ("Германия" поэмасы, "Юл сурәтләре" әсәре).

> **Бу көйне беләм, сүзләрен дә беләм,**
> **Беләм бик яхшы – авторларын да:**
> **Алар качып кына шәраб эчәләр,**
> **Коры суны мактап – халык алдында, –**

дип яза ул бер шигырендә икейөзле дөньяны истә тотып.

Әйтергә кирәк, Германиядә Һенрих Һейне нимес милләтчеләре тарафыннан әледән-әле эзәрлекләнеп торган. Алар шагыйрь иҗатының чын милли әһәмиятен киметеп күрсәтергә тырышалар, аның олы талантын күрмәмешкә салышалар... Ихтимал, моның аңлатып була торган сәбәпләре дә бардыр... Бөтенесе ага, бөтенесе үзгәрә, дигәндәй, чорлар, заманалар үзгәреп тора, фикерләр дә төрләнә. Әмма Һенрих Һейненың кабатланмас шәхесе һәм язмышы, шулай ук, үзеннән соң бай һәм олы әдәби мирас калдыруы аның чын талант иясе булуын исбатлап торалар. Ничек кенә булмасын, ул нимес телендә уйлаган, нимес телендә иҗат иткән һәм кешелек дөньясының рухи байлыгына үзеннән күренекле өлеш керткән атаклы шагыйрь. Аны бөтен дөнья белә, укый, өйрәнә, гыйбрәт ала. Һейне шигырьләренә язылган күпсанлы романсларның авторлары – дөньяның шөһрәтле композиторлары Григ, Лист, Шуберт, Чайковский, Рахманинов һ.б. Ул – мәхәббәт һәм фәлсәфә шагыйре.

Без аның белән беренче чиратта урысча тәрҗемәләре аша таныштык. Аны тәрҗемә итүчеләр арасында Лермонтов, Михайлов, А.Толстой, Блок, Добролюбов, Фет, Тютчев, Майков, Маршак, Тынянов, Анненский, Левин кебек күренекле урыс шагыйрьләре-әдипләре һәм безнең Тукаебыз да бар...

Һейне, озак һәм газаплы авырудан соң, 1856 елның 16 февралендә Парижда вафат була.

...Бүген мин "Мәдәни җомга" укучыларына бөек шагыйрьне искә алу җәһәтеннән, аның замандашы, француз язучысы Александр Вейльның бер истәлеген тәкъдим итәм. Миңа ул гаять кызыклы булып тоелды, чөнки истәлек моннан 150 еллар элек Аурупа язучыларын нинди проблемалар борчыганлыгы турында бик ачык сөйләп тора...

Лена ШАГЫЙРЬҖАН.

Александр ВЕЙЛЬ

Һейне турында истәлекләр*

1847 елда миңа Эжен Сюдан китабымны бастырып чыгару өчен мең франк акча бирәчәген хәбәр иткән хат килеп төште. Аны Һейне дә укыды. Шуннан соң ул, Эжен Сюның шулкадәр юмарт булуына соклануын белдереп, үзенең дә Сю белән бер очрашып, сөйләшеп утырырга теләвен әйтеп куйды. Бу ике атаклы язучы үзара таныш түгелләр иде. Мин Һейнегә Эжен Сюның моңа бик теләп риза булачагын әйттем.

– Шулай ук сездән, – дип өстәде Һейне, – минем дустым Бальзакны да чакыруыгызны үтенәм. Безнең күптәннән күрешкәнебез юк...

Аның белән без 1838 елдан бирле аралашабыз. Минем чакыруымны ишеткәч, Бальзак чыраен сытып куйды. Ул социализм белән мавыгып киткән Сюны бик үк өнәп бетерми иде булса кирәк. Әмма Һейне белән күрешергә каршы түгел. Ул килергә вәгъдә бирде. Эжен Сю да килергә булды һәм безнең бу ниятебез тиздән чынга да ашты. Мәҗлес минем өйдә булды.

Гаҗәп хәл! Менә дигән мәшһүр өч язучы табын янында, ни әдәбият, ни шигърият хакында бер генә сүз дә сөйләшмәделәр. Анда сүз өч сәгать буена гел Республика, Монархия һәм Коммунизм турында барды. Әңгәмәгә баштан ук һәм тулысынча Бальзак хуҗа булып алды.

– Минем карашларым күптәннән билгеле, – диде ул. – Хакыйкатьнең яңа булуы мәҗбүри түгел... Шулай ук мин үз фикерләремнең кимчелекле якларын да беләм. Хәер, минем дустым Һейне аларны үзе дә бик тиз шәйләп алыр. Әмма мин бүген "яңа" дип йөртелгән карашларның ялган һәм һич тә тормышка ашмаслык булуын исбатларга телим һәм минем монда килүемнең төп максаты да әнә шул. Мин республиканы бик теләп кабул итәр идем, әмма мин аның җәмгыять тормышында китереп чыгарачак котылгысыз тискәре

* Кыскартып бирелә.

нәтиҗәләреннән шикләнәм. Шуны да әйтим, үзен бик яңа дип йөргән социализм идеясе дә бик куркыныч нәрсә: ул һәрвакыт үзенең анасы – республиканың һәм кардәше азатлыкның башын ашап килде. Шулай булды һәм булачак. Бу инде иркен тормыш белән – Ирек, ягъни Платон белән Аристотель арасындагы мәңгелек бәхәс. Немесләрдәге Лютер белән Мюнцер арасындагы бәхәс кебегрәк...

- Ах, сез минем өлкәгә килеп кердегез, – дип җанланып китте Һейне. – "Лютер белән Мюнцер арасында" дия күрмәгез: "Лютер белән Лютер", яисә "Мюнцер белән Мюнцер" арасында, дисәгез, дөресрәк булыр... Чөнки әле бер генә немеснең дә беркайчан да үз-үзе белән ярты елдан да артыграк килешеп яши алганы юк. Һәрбер немес үзе белән үзе каршылыкка кереп бата. Бербөтен немеснең булганы да юк, булмас та. Әгәр Германиядә бер көн килеп милли бердәмлек урнашса, ул бары тик көч һәм каты кул белән генә тотылып торачак, чөнки, кагыйдә буларак, немесләр төшкә кадәр бер төрле уйласалар, төштән соң икенче төрле фәлсәфә куерта башлыйлар...

- Ярар, – диде Бальзак, – алай булгач, французларча ачык итеп сөйләшик. Сайлап куелган хакимият белән нәселдән килгән хакимият арасындагы аерма нәрсәдә? Сайлап куелган власть – бөтен милләтнеке, ә монархия – бер гаиләнеке генә. Беренче карашка республика гаделлекнең гәүдәләнеше кебек күренә, ә монархия – көчләп яулап алу шикелле. Әмма җентекләбрәк карасаң, мәсьәләнең икенче ягы калкып чыга. Асылда сайлап куелган хакимият нәрсә соң ул? Ун миллион граждан үзләренең хакимлеген билгеле бер вакытка кемгәдер тапшырып тора, һәм әгәр дә үзләре таләп иткән шартлар үтәлмәсә, аны кире тартып алырга да хаклы булып кала. Димәк ки, һәр француз үз хакимлегенең ун миллионнан бер өлешен кемгәдер тапшырып тора ала... Ә ни өчен ул бу хокукка ия? – Француз җирендә туганга күрә.

Шуннан, карагыз: шул ук хокук нигезендә, ул бу җиргә үзе дә хуҗа булырга тиеш ич. Ягъни – Франция җиренә. Бу җир мөлкәтенең ун миллионнан бер өлеше аныкы булырга тиеш. Афинада һәм Римдә аграр законнар шулай барлыкка килгән. Әмма борынгы республикалар җирне эшкәртү өчен коллардан файдаланганнар. Бу – хак, һәм нәкъ шуңа күрә дә Моисей, тарихтагы бөек демократ, республика урнаштыргач һәм җирне кабиләләр арасында бүлгәләп бетергәч, илле елга бер тапкыр шул ук җирләрне шул ук гаиләләргә кабат кайтарып бирү көнен билгеләгән. Солон исә, республика урнаштыргач, бөтен бурычларны бетергән. Ә Ликург гомумтигезлек идеясен уйлап чыгара.

– Бу уңайдан, бер искәрмә әйтеп үткәргә рөхсәт итегез, – дип бүлдерде аны Һейне. – Игътибарыгызны шуңа юнәлтер идем: Ликург белән Солон, үз ватаннарында республика игълан итү белән, чит илгә чыгып качалар.

– Мин әле шуны да белдем, – дип дәвам итте Бальзак, – безнең дустыбыз Сю, коммунист булмас өчен, фурьеризмга ябышкан, диләр... Әмма халык бу төшенчәләрне аңламаса да, юләр түгел ул. Хакимиятне сайлап кую белән, ул мөлкәтнең дә бүленүен тели башлый.

– Бик күпләргә иң кирәк әйберләр дә җитешеп бетмәгән бер вакытта, беркемнең дә артык байлыгы булырга тиеш түгел! – диде Сю.

– Бу инде бик күпләргә төпле фикер һәм аек акыл җитешмәгән бер вакытта, беркемнең дә акыл иясе булырга хакы юк, дип әйтү белән бер булыр иде, – дип каршы төште аңа Бальзак.

Сүзгә шунда Һейне кушылып китте:

– Минем дустым Бальзак "акыл" һәм "артык байлык" дигән төшенчәләрне үзара якынайта шикелле. Гадәттә, акыл "артык нәрсә" белән "кирәк нәрсә"не аера белү өчен кирәк була торган иде... Дөнья яралганнан бирле фәлсәфә "иң кимендә", "кирәк кадәр генә" дигәнне хуплап килә. Ягъни – минимумны. Хәтта рухи өлкәдә дә. Менә ни өчен яһүдләр мәңгелек. Алар һәрвакыт булачак һәм аларны беркем дә уздыра алмаячак, чөнки алар динне дә кирәк кадәр генә алганнар.

– Матурлык та – артык байлык, – дип елмаеп куйды Бальзак. – Яшь, сәламәт хатын-кыз матур булмаса да ярый. Чөнки аңа сөю-сөелү өчен иң кирәге бирелгән. Димәк, ямьсез хатын-кызлар: "Без үз минимумыбызны алмый торып, беркем дә матурлыкка ия булырга тиеш түгел", – дисеннәрме?..

– Аларның минимумы, – дип яңадан сүзгә катнашып китте Һейне, – йә ир, йә сөяркә... Үзара гына әйткәндә, һәрбер хатын-кызның ир-атка хокукы булырга тиеш. Ә менә Саксониядәге ирләр бу яктан бик акыллы булып чыккан. Аларда никахлашу лотерея буенча алып барыла һәм тугрылык мәсьәләсе дә бик җитди куела. Никахлашырга тиешле яшьләрне башта бик әйбәтләп тикшерәләр һәм һәрберсенә номер-җирәбә язып бирәләр. Кәләш үзенә ирне капчыктан тартып ала. Берәү дә онытылмый. Алмашырга да ярамый. Аерылышу өчен сәбәп бары тик хыянәт кенә була ала.

– Шуннан нәрсә? – дип сорады Сю. – Мондый никахлар бәхетлеме соң?

– Мәкерле сорау! – дип җавап кайтарды Һейне. – Соң бит бәхетле никах ул беркайда да вәгъдә ителми, ул тик язмыш бүләге генә... Аның каравы, андый гаиләләр тизрәк ишәйгән, чөнки аларны алдан ук табиблар карап тәкъдим итә торган булган...

– Нәрсә, бер генә кыз да һәм егет тә "отыш"тан риза булмауларын белдерә алмаганмыни?

– Булгалаган инде. Ул чагында алар бу кабиләдән китәргә тиеш булганнар.

– Менә күрәсезме? – дип куйды Бальзак тавышын күтәреп. – Мондый коммунистик җәмгыять бары тик артта калган аерым кабиләләрдә генә мөмкин. Әгәр алар бердәм кагыйдәләр белән яшәсәләр, мондый гадәт ярты ел да дәвам итмәс иде...Әгәр барлык хатыннар һәм ирләр шундый канунга буйсындырылса, бу берөзлексез гражданнар сугышына китерер иде...

...Ирләр, көлешә-көлешә ниндидер кинаяле үткен сүзләр әйтешеп, темадан бераз читкә тайпылдылар...

– Әйдәгез, сүзне читкә бормыйк, – диде Бальзак түшендәге тастымалын төзәткәләп. – Беләсезме, әфәнделәр, мин бит Сен-Симонны да, Фурьены да, коммунизм идеяләрен дә бик шәп өйрәнгән кеше. Соңгысы – барлык "изм"нарның котылгысыз логик нәтиҗәсе булып тора. Шулай итеп, нәрсә соң ул коммунизм? Бу – борынгы кыргыйлык чорына кире кайту, дигән сүз. Бу – барлык хезмәт төрләренә һәм төрле категорияләрдәге хезмәт ияләренә бер үк дәрәҗәдә, ягъни бары тик минималь хезмәт хакын гына түләп бару, дигән сүз... Бу – даими коллык һәм тиранлык кына түгел, бу инде мәңгелек анархия дә. Ә хатын-кызлар белән эш ничек тора? Күп хатын белән тору яки уртак хатыннар белән яшәү тәртипләренә ничегрәк карыйсыз? Бу бит вәхшилек! Ә инде күп хатын белән торуны көчләп тагалар икән, бу инде үзе коллык, дигән сүз! Менә бит нинди бозыклык! Берсе икенчесенә бәйләнгән. Коммунизм – демократиянең иң беренче һәм иң рәхимсез дошманы. Ул абсолют монархиянең турыдан-туры ярдәмчесе. Образлы итеп әйткәндә, Сюга аеруча ошасын өчен, болай дим: республика табигый сәламәтлек булса, коммунизм аңа карата яман шеш белән бер...

– Ярый, – диде аңа каршы Сю, – минем хөрмәтле дустым Бальзакка рәхәт булсын дип, мин дә шуны әйтим: мин коммунист түгел. Мин фәкать социалист. Аермасын соңрак аңлатырмын. Ә хәзергә Бальзак менә мондый сорауга җавап бирсен иде. Коммунизм идеясе һәрвакыт яшәп килгән. Сез аны иҗтимагый фикернең бер чире дип тә атый аласыз, әмма ул бар! Ә менә монархиянең аңа каршы нәрсә уйлап чыгарганы бар соң? Шушы бәлаләрнең беренчел сәбәбе ул үзе түгелмени? Ул үзе яман шеш түгелмени? Халык алдында үз сүзен әйтә алу хокукына ия гражданнары булган республика, ичмасам, әле бу чиргә каршы дару тәкъдим итә ала. Ул даруны эзли, көрәшә. Яки менә ун миллион француз хәерчелектә көн күргән вакытта, ни өчен әле йөз мең дворян яки рухани майда йөзәргә тиеш? Ни хаклары бар, шайтан алгыры?! Әйдәгез, башта төрле законсызлыкларны, тир түкмичә генә үзләштергән байлыклар һәм өстенлекләрне бетерик, аннан соң нишләргә кирәген күз күрер. Алга барырга кирәк, шунда гына офыклар да киңәер...

Әлеге нотык барышында Сю шулкадәр ялкынланып китте ки, Һейне аны тынычландыру өчен иртән үзе җибәргән шампан шәрабен бокалга салып, аңа сузды:

1797 1856

– Сез безгә үзегезнең илһам ширбәтен авыз иттергән кебек, инде безнекен дә татып карагыз, – диде ул.

Әңгәмәнең туктарга исәбе юк иде әле. Сүзне тагын Бальзак дәвам итте:

– Мин искелек калдыкларыннан әвәләнгән киләчәк турында сөйләмим. Мин прогресска ышанам. Әмма шуны гына әйтәм: бәлки, үткәндәге республикалар киләчәк өчен беренче үрнәкләр генә булгандыр. Без һәрвакыт нинди дә булса яңалык ачуга барабыз. Кешелек дөньясы да, аерым шәхес кебек, бертуктаусыз өйрәнә. Әмма менә шуны беләсе иде: төп хакыйкатьләр һәрвакыт шул ук искечә булып калмый микән? Берәр абсолют яңалык туа микән? Кайсыдыр философ әйткән бит: хакыйкать ул суган шикелле, әрчегән саен яңа кабык килә дә чыга, ә үзе һаман шул бер суган, дигән...

– Һәм күздән дә һаман шул ук яшьне агыза, – дип эләктереп алды Һейне аның сүзен, гадәтенчә, үткен теллеләнеп. – Хәзер инде мин чүл консерваторлары үкенеп искә ала торган Мисыр суганнарының нәрсә икәнен аңлыйм.

– Чын хакыйкать шунда ки, – дип дәвам итте Бальзак Һейненең шаяртуына бераз ачуы килеп, – бик күп кешеләр читтән кемнеңдер боерып, буйсындырып яки мәҗбүр итеп торуыннан башка бәхетле дә була белмиләр. Абсолют ирек һәрвакыт абсолют анархия булган һәм булачак.

...Инде вакыт шактый соң иде. Табын яныннан кузгалыр алдыннан, Сю, Һейнегә мөрәҗәгать итеп, сорап куйды:

– Безнең дустыбыз Һейненең фикере ничегрәк соң?

– Һәрбер немеснеке кебек, минем дә фикерем берничә төрле. Әмма мин аларны кыскача гына әйтеп тә бирә алам. Башларгамы?

– Башлагыз, – диде Бальзак, – сезгә бу кыен булмас. Пегаска да атланып алсагыз...

– Мин тәүлекнең көн һәм төннән торуын белеп алдым, – дип сөйләп китте Һейне, бераз киная белән: – Ягъни мәсәлән, – үзара каршылыктан торуын. Төннән башка көн, никадәр генә гүзәл булмасын, бик күп уңайсызлыклар тудырыр иде. Шулай ук көннән башка төн дә газаплы булыр иде. Тагын шуны сизеп алдым мин: дөньяга бала тусын өчен дә ир белән хатын кирәк икән бит... Һаман шул ике капма-каршылык... Гәрчә, алар кайвакыт үзара гармониядә торсалар да.

Аннары менә нәрсәне төшендем: берәр юньле эш килеп чыксын өчен дә бер ахмак белән бер акыллы кирәк икән. Миңа Берлиозның әйткәне бар иде: ике диссонанстан һәрвакыт гармония туа, дип... Кыскасы, мәңгелек гүзәл күренешләр үзара каршылыктан тукылган. Дусларым, республика һәм монархия белән дә эш нәкъ менә шулай тора, минемчә. Монда "теге яки бу" түгел, "тегесе дә, монысы да" таләп ителә. Икесенең кушылмасы. Үзара каршы булгач, алар кушылудан менә дигән аккорд яңгыраячак. Шулай булгач, яки монархистлар идарә итә торган республика, яисә республикачылар идарә итә торган монархия кирәк.

Сүземне тәмамлыйм, чөнки минем хатыным бар, дөресрәге мин – хатынымның ире. Ә ул минем даһилар белән утырып дөньямны онытуыма беркайчан да ышанмаячак, шуңа күрә миңа өйгә кайтырга вакыт, һәм мин сезне дә үз өемдә күреп шатланырмын дип өметләнеп калам. Без республика игълан итәрбез: аның президенты – Бальзак, секретаре Сю булыр. Ә мин сезнең җиңүләрегезгә дан җырлап шигырьләр язармын. Чөнки французлар шагыйрьгә даһи сәясәтче булырга һич тә юл куймаячаклар...

Бу атаклы өч шәхескә кабат беркайчан да күрешергә туры килми...

Иң-иң...

Иң күп әйбер йоткан кеше 1927 елда мәгълүм була. Ул – 42 яшьлек хатын. Аның эченнән 2533 чит әйбер чыга. Шулар арасында 947 булавка да бар. Ул "никтер эчем авырта" дип табибка күренергә килгән була.

Иң күп танклар 1954 елдан 1980 елга кадәр СССРда чыгарыла. Барысы – Т-54/55 тибындагы 50 мең танк.

Иң авыр авиабомба – 7,7 метрлы, 9980 килолы "Грэнд Слэм" дигән инглиз бомбасы 1945 елның 14 мартында Германия өстенә ташланган. Икенчесе – 1949 елда Калифорниядә (АКШ) сыналган 19050 килолы бомба.

Иң куәтле атом ядрәле бомбаның куәте 57 Мт тирәсе булып, СССРда, Яңа Җирдә 1961 елның 30 октябрендә сыналган. Ул бомбаның афәтле дулкыны Җир шарын өч мәртәбә әйләнеп чыккан.

Иң канлы һәлакәт Кытайда 1556 елның 2 февралендә Шэньси һәм Хэнань провинцияләрендә була. Монда бик каты җир тетри. Нәтиҗәдә 830 мең кешенең гомере өзелә.

3 тонналы, 15 метрлы (диаметры), калынлыгы 2,5 сантиметрлы коймак Англиядә 1994 елның августында пешерелә.

Иң зур карамель конфеты (леденец) Англиядә, Блекиулдәге Король кондитер фабрикасында ясала. Аның авырлыгы 413,6 кило, озынлыгы 5 метр, калынлыгы – 43,2 сантиметр.

Иң зур крендель (пончик) 1993 елда Америкада Аттика шәһәрендә пешерелә. Ул 1,7 тонна авырлыкта була.

Иң зур тизлектә оча торган хәрби реактив самолет – СССРда эшләнгән МиГ-25 самолеты. Аның максималь тизлеге (радар үлчәгән) – 3395 км/сәгать.

Иң зур су асты көймәсе дә Русиядә эшләнгән. Ул "Тайфун" атлы субмарина класслы көймә. Аның озынлыгы 171,5 метр, авырлыгы – 26500 тонна.

Кулында һәм бармагында иң күп бармагы булган кеше – Лондонда туган (1921) ир бала. Аның кулында – 14, аягында 15 бармагы булган.

Иң кыйммәтле теш – XIX гасыр башында яшәгән галим Исаак Ньютонныкы. 1816 елда Лондонда ул тешне 730 фунт стерлингка саталар. Сатып алучы Ньютон тешен балдагына куйдыра.

Ядрә дигән исем беренче мәртәбә 1877 елда цирк артисткасы "Зәзәл"гә ("Красотка") бирелә. Лондонда пушкадан аткач, ул 661 метр ераклыкка оча.

384 метрлы трасса буйлап "коймак йөгерешләре" Австралиядә үткәрелә. 1985 елның 19 гыйнварында Мельбурнда Ян Стикленд дигән кеше трассаны 59,5 секундта коймак тотып йөгереп уза.

Иң-иң...

ایمان الفباسی

بسم الله الرحمن الرحيم

Иман әлифбасы
IMAN ƏLIFBASЬ

Узган атнада Казандагы "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә читтән торып укучыларның беренче чыгарылышы булды. 27 шәкерт. Әлеге уку йортының дипломнарын алып, төрле төбәкләргә таралды. Шул уңайдан бирегә ифтар мәҗлесе уздырылды.

Нинди уку йорты соң ул мәдрәсә? Анда нинди белгечләр әзерләнә?

Мәдрәсәләр Көнчыгыш илләрендә Ислам дине кабул ителү белән халыкка шушы дин гамәлләрен өйрәтү мәктәбе буларак барлыкка килә. Аларның башлангыч, урта һәм югары белем бирә торганнары булуы мәгълүм. Шундыйларның берсе – Казандагы "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе 1882 елдан алып 1918 елга кадәр яшәгән. Һәм шул чорда Казан губернасендә иң алдынгылардан берсе булган. 36 ел эчендә ул меңнән артык шәкерткә башлангыч һәм урта белем биргән. Алар арасында Миргазиз Укмасый, Зариф Бәшири, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Әнәс Камал, Кәрим Тинчурин, Гыйбад Нугайбәк, Галимҗан Шәрәф, Хуҗа Бәдигый, Фәхри Әсгать, Фәтхи Бурнаш, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Исхак кебек күренекле әдипләр һәм галимнәр, Габдрахман һәм Габдулла Камал кебек талантлы артистлар, Салих Сәйдәшев, Солтан Габәши кебек мәшһүр композиторлар, Бакый Урманче кебек шөһрәтле рәссам-сынчылар бар. Бу мәдрәсәнең урта бүлеген тәмамлаучыларның бик азы гына мулла булып китә. Мәдрәсәне Галимҗан Баруди җитәкли. Бирегә җәдитчә укытыла. Шәкертләр әлифбадан 3-4 айда укырга-язарга өйрәнгәннәр.

XIX гасыр азагында мәдрәсәдә инде

аяклы парталар, кафедра, кара такталар, тарих, география карталары, плакатлар булдырыла.

1912-14 елгы программа буенча башлангыч бүлектәге айлык программаның 39 сәгате дин тәгълиматына, 111 сәгате дөньяви фәннәргә бирелә. Урта бүлектә дин тәгълиматы 43 сәгать, дөньяви фәннәр 131 сәгать укытыла. Тарих, гарәп, фарсы, төрки телләрен укытуга зур әһәмият бирелә.

90 нчы еллар башында Казанда әлеге мәдрәсә яңадан тергезелде. Без аның ректоры Наил ЯРУЛЛАга берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

– Наил хәзрәт, бу мәдрәсә элекке "Мөхәммәдия"нең дәвамы булып эшли башладымы?

– Әйе. Ул моннан 5 ел элек ачылды. Кичке һәм көндезге бүлекләрендә беренче чыгарылыш узган җәй үк булган иде. Менә инде читтән торып уку бүлегендә укучы шәкертләр укуларын тәмамладылар, 15 гыйнварда аларга дипломнар тапшырдык.

– Аларны нинди программа буенча укыттыгыз?

– Без элекке "Мөхәммәдия"нең укыту программасын таптык. Ләкин аны шактый үзгәртергә туры килде, чөнки безгә хәзер урта мәктәпне тәмамлаган кешеләр килә. Аларга география, биология, математика, физика кебек фәннәрне укытуның хаҗәте юк. Без Ислам тарихын, татар халкы һәм Ислам дәүләтләре тарихын, хокук белемнәрен өйрәтүгә нык игътибар бирәбез.

– Мәдрәсәне ничә кеше тәмамлады?

– Көндезге һәм кичке бүлекләрне 50 кеше, читтән торып уку бүлеген 27 кеше тәмамлады. Хәзер көндезге бүлектә – 200, кичке бүлектә – 300, читтән торып уку бүлегендә 250 кеше белем ала.

– Аларны кайларга җибәрәчәксез?

– Татарстанның үзендә генә дә 700дән артык мәчет эшли. Аларда эшләр өчен имамнар җитешми. Хәер, безнең мәдрәсә Татарстан өчен генә түгел, Башкортстан һәм тулаем Русия өчен дә кадрлар әзерли. Укучыларыбыз да бөтен Русиядән, хәтта Таҗикстаннан килгән шәкертләр дә бар.

– Сездә укучыларның яше ничегрәк?

– Күпчелеге яшьләр, югары һәм урта белемлеләр. Әнә читтән торып укып, мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында Әтнәдән Әззинә Низамова, Чаллыдан Гөлнур Хәйруллина – укытучылар, Гөлфия Сафина – шәфкать туташы. Башкортстаннан Файсол ага Мостафин һәм Казаннан 71 яшьлек Мәйсәрә әби кебекләр дә бар. Алар яшь буынны тәрбияләүдә күп файда китерәләр. Нәтиҗәдә Мәйсәрә әбинең ике кызы хәзер мәдрәсәбезнең көндезге бүлегендә укый. Оныгы да мөселман мәктәбендә белем ала.

– Мәдрәсәдә укыту өчен кадрларны кайдан алдыгыз?

– 90 нчы еллар башында бертөркем яшьләр чит илләргә Ислам дине буенча белем алырга киткән иде. Алар укуларын тәмамлап кайттылар. Шуларның кайберләрен, аннары Казан дәүләт университетын һәм педагогия университетын тәмамлаган кайбер белгечләрне укыту эшенә тарттык.

– Үзегез кайда белем алдыгыз?

– Мин Бохарада "Мир-Гарәп" мәдрәсәсен тәмамладым. Аннары ике ел Мәдинәдә белемемне күтәрдем. Укыту бүлеге мөдире Камил хәзрәт Вәлиулла да югары дини белемле, мәдрәсә эше өчен янып-көеп йөри.

– Уку-укыту өчен бирегә шартлар җитәрлекме?

– Хәзер ярый инде, авырлык белән булса да элекке "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе бинасын безгә кайтардылар. Моңарчы шартлар начар иде. Мәдрәсәне Рамазан мәчетенең бер бүлмәсендә ачып, аннан Нурислам һәм башка мәчетләрдә йөргән идек. Аллага шөкер, кыенлыклар җиңелеп бара. Ислам динен көчәйтү өчен лаеклы кадрлар әзерләүдә акрын-акрын алга барабыз.

Заһид ШӘФИГЫЙ.

Наил ЯРУЛЛА,
"Мөхәммәдия" мәдрәсәсе ректоры:

Бездә малайлар да, бабайлар да укый

● Мәдрәсәдә укучылардан бер төркем (сулда).
● Мәдрәсә ректоры Наил Ярулла, мөдәррис Винерулла Ягъкуб һәм ректор урынбасары Камил Вәлиулла.

Мидхәт ШАКИРҖАНОВ фотолары.

Дәресләрне Харис хәзрәт САЛИХҖАН алып бара

Кадер кичәсе

Галәмнәрне, мәхлукатны, барлык тереклек дөньясын вә адәмне юктан бар кылган Раббымызның олуг нигъмәте – Коръән Кәримнән нур алып, һәр мизгелдә дә изге гамәл белән Аллаһумызның рәхмәтен өмет итеп, Рамазан шәрифтә ураза тоту бәхет-сәгадәтенә ирешкән, бүген җир йөзендә яшәгән бер миллиард ярым мөселман белән бергә, газиз Татарстаныбызда 749 мәхәлләгә берләшкән әһле ислам быелгы гыйнварның 25еннән 26сына каршы төндә – 26 нчы Рамазанда, ислам дөньясының иң газиз вә мәхәббәт мизгелен – Кадер кичәсен каршыларга әзерләнә.

Ни өчен соң Аллаһы Раббымызның барлыгына, пәйгамбәребезнең хаклыгына иманда булган бәндә ихлас күңел белән, үзенә генә хас җаваплы вә саваплы кичереш илән Кадер кичәсен хөрмәтли? Шуның өчен, чөнки, 610 нчы милади елның Рамазан шәриф ае Кадер кичәсеннән башлап, Мөхәммәд галәйһис-саләтү вәссәламгә Җәбраил фәрештә аркылы яшерен аваз белән Аллаһу Раббымызның олуг нигъмәте – Коръән Кәрим 23 ел буена иңдерелде.

Аллаһу Раббуль гыйззә мөбарәк "Кадер" сүрәсендә: "Иннәәәә әнҙәлнәһү фии ләйләтил кадр", ягъни "Дөреслектә Без иңдердек Коръәнне Кадер кичендә", – диде. Сүрәне дәвам итеп Раббымыз: "Вәмәәәә әдәраакә мәә ләйләтел кадр". Әй бәндәм, син бу Кадер киченең бөеклеге вә әһәмияте турында нәрсә дә булса беләсеңме?" – дип сорый да, ул бөеклекне аңлатуны ошбу аяте кәлимә белән дәвам итә: "Ләйләтүлкадри хәйрам мин әлфи шәһр". "Ул бер кичә үзе мең айдан да изгерәк!", – ди. Димәк, Мөхәммәд өммәтенең бер бәхетле бәндәсе бу кичәдә Аллаһу хак сүбхәнәһү вә тәгаләгә ихлас күңеленнән булган гыйбадәтләрен багышлап изгелектә үткәрсә, ул сиксән өч ел да дүрт ай дәвамында кылынган гыйбадәт савабына лаек булачак. Чөнки вакыт берәмлегенең бер мең ае – сиксән өч ел да дүрт айга бәрабәр. Алай булгач, бу аяти кәлимәнең асыл мәгънәсе шул булыр: Кадер төнен тәгать-гыйбадәттә үткәрү бер мең ай дәвамында кылынган гыйбадәттән дә зуррак. Бу җөмләдән заманыбызның олуг әдибе газиз Тукаебыз, Раббымызның "Кадр" исемен йөрткән 97 нче сүрәсендә тәсдыйк ителгән "Ләйләтүл кадри хәйрам мин әлфи шәһр" – дигән кәлимәсен, шигъри ысул белән: "Кадер кич" дип атый, һәм:

Шул капугдан күндерербез
Тәңребезгә бер теләк,
Бер кадер кич Тәңре каршынд
мең айдан да изгерәк!

- дип тәфсир кылуы һәрбарча иманлы бәндәне гафиллектән уята да, үзенә генә хас куанычында уйга сала. Ничек кенә соң уянмассың да уйланмассың!

Аллаһу тәгалә "Кадр" сүрәсендә "Тәнәззәлүл мәләәъикәтү вәрухху фииһәә бидни Раббиһим мин күлли әмр", ягъни "Кадер кичендә Җәбраил һәм башка фәрештәләр иңәрләр күктән җир йөзенә Раббымызның әмере белән", – дигән җөмләне Тукай:

Йон мамыктай әйләнер җирдә бу кич
әрвах вә рух,
һәр фәрештә сафлары җирдә йөрер
меңәр груһ.
Ул мәләикләр җыярлар тол ятимнәр
яшьләрен;

Барча көчсезләр, зәгыйфьләрнең аһын, каргышларын, – дигән шигъри юллар белән аңлата.

Аллаһу Раббул гыйззә Кадер кичәсе "мең айдан да изгерәктер вә артыграктыр", диде дә Кадер кичәсенең ничәнче кичәдә икәнен адәмнәрдән яшерде. Бөтен Рамазан ае дәвамына харам гамәлләр кылмыйча, җан иясен рәнҗетмичә, гөнаһлы булмыйча, Аллаһ кушкан изгелекләрне генә эшләп, ятим, мескеннәрнең хәлләрен белеп, ярлыларга, ярдәмгә мохтаҗларга малың булса мал беләнме, күңелең изге булып – телең, куәтең, гамәлең беләнме, ярдәм итү өчен, бөтен Рамазан шәрифтә хәерле изге эшләргә өндәп, Коръән укып, газизләребезгә мәрхүмнәребезгә догалар кылырга боерды. Аларда разый булсалар иде дип, Бер Үзенә, Бер ялгызына ниятләп Аллаһу тәгалә ураза тотарга кушты. "Кадер киче" кеби төн Рамазан шәрифтә килгәндә, бәндәләр арасында булган гөнаһларының кичерелүен ихлас, җан-тән аша теләгән кеше иң элек телдән тәүбә итәргә тиеш. Шунда гына Аллаһу Раббымызның мәрхәмәте белән сугарылган бәндә бәхет-сәгадәткә ирешә. Шулай булгач, Рамазан шәрифнең һәр мизгелендә изгелеккә омтылыйк. Хата-гөнаһларыбызны төзәтергә ашкыныйк! Ашыгыйк!

Харис САЛИХҖАН,
Татарстан Диния нәзарәте рәисе урынбасары.

"Сәлам биргәндәй Казан халкына..."

Менә бит, язмышлар диген, әй. Татарстан радиосының 70 еллыгы уңаеннан язма әзерлим дип, төрле еллардан сакланып калган кәгазьләремне караштырып утыра идем, арадан менә шушы шигырь килеп чыкты.

Әйе, бу шигырь Хәсән ага Туфанныкы иде. Аның кулы, аның яшел карасы. Әмма бу шигырь аның китапларына кермәгән, мөгаен, матбугатта да чыкмагандыр. Әмма ул радио аша яңгырады.

Башта ук шуны аңлатып китим: Хәсән ага бу шигырьне коммунистлар партиясенең XXIII съезды ачылуга багышлап язды. Дөресрәге, минем үтенеч буенча язды ул аны. Татарстан радиосының соңгы хәбәрләр редакциясендә өлкән мөхәррир булып эшләгән чагым иде. Менә шунда мин Хәсән агага мөрәҗәгать иттем. Ул, уйлап карармын, диде. Билгеләнгән вакытка килеп, шигырен укып, язылып та китте.

Хәзер әйтергә мөмкиннәр: имеш, Сталиннан-советлардан күпме җәбер күргән Хәсән Туфан нигә андый "кызыл" шигырь язды икән, дип. Минемчә, Хәсән аганы аңлап бетермәүчеләр генә шулай әйтергә мөмкин. Ул бит җәберне генә күргән кеше түгел, соңыннан аклану кебек нәрсәне дә, Сталинның шәхес культы фаш ителүне дә күргән кеше. Аның дөреслеккә ышанычы, киләчәк көннәргә ышанычы чагылмый кала аламы иҗатында? Ленинга да, коммунизмга да ышанган буынның шагыйре дә иде бит әле ул. Алардагы шул ышаныч, шул өмет бүген берәрсендә бармы соң? Уйлап карыйк әле. Шуңа күрә Хәсән ага безгә үз чоры белән бик аңлашыла.

Аннан соң, Хәсән ага безне, радио хезмәткәрләрен бик хөрмәт итә иде. Шуңа күрә дә бит, мин съезд ачылган көнгә шигырь язып бирүен үтенгәч:

- Кайчанга кирәк соң инде ул? – диде дә, язып та килде. Хәсән аганың вәгъдәсендә торуы, сабыр, төгәл һәм тәвәккәл булуына күп тапкырлар игътибар иткәнем булды. Хәзер дә ул күз алдымда. Менә, ямь-яшел кара белән язылган шигыре. Кәгазь инде саргаеп беткән. Әмма язуы, хәрефләре әле һаман да ап-ачык. Менә шул кәгазьне кулыма алдым да уйга калдым. Хәсән аганың радио фондында язылып калган тавышы бар-барын. Әмма ул, ни кызганыч, үзенең катлаулы язмышы турында истәлекләр язып калдырырга өлгермәде. Аның тавышын яздырып алуда безнең баш мөхәррир Рим Кәримов күп тырышлык куйды-куюын. Тик, әйтәм бит, ул язмалар каралама хәлендә генә калды бугай. Ул тасмаларның Рим Кәримов (үзе дә мәрхүм шул инде) гаиләсендә яки радиода, әдәбият редакциясендә саклануы ихтимал. Әлеге тасмалар белән кызыксынырга кирәк, дип уйлыйм мин. Хәсән Туфанның бу шигырен дә нәкъ шул теләктән чыгып тәкъдим итәм.

Наил ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Истә калачак көннәр

Көттем мин кичә
Тарихи таңны,
Тизрәк әйлән, дип, тизрәк, Җир шары.
Бу бөек таңны, мин генәмени? -
Һәрбер континент көтте бит аны.

Кунаклар килде бөек съездга,
Туганнар килде континентлардан.
Чит илләрдәге сыйнфый көрәшнең
Алгы сафыннан, канлы кырлардан.

Аэропортлардан
Ленин янына,
Кызыл мәйданга килгән чагында,
Узып барышлый керә китәләр
Безнең илгә дә телевизорда,
Сәлам биргәндәй Казан халкына,
Батыр халыкның улы-кызына.

Съездга барган вәкилләребез,
Бездән аларга сәлам әйтегез!

Нинди зур безнең уңыш-җиңешләр,
Безнең өмет тә, димәк, вак түгел.
Бөек съездга юнәлгән бүген
Өметләр белән безнең бар күңел.

Ленинчылардан көткән өметләр
Һичбер вакытта бушка булмады.
Шуны раслыйлар безнең гомернең
Барлык еллары, барлык юллары.

Ленин юлының асыл гадәтен,
Асыл сыйфатын хәтергә алып,
Кояшның тагын чыгачагына
Инанган кебек ышана халык.

Эшкә ашарлар, чәчәк атырлар
Бөтен теләкләр, бөтен өметләр.
Гомерләр буе истә тотарлык
Чор булып калыр безнең бу көннәр.

РЕДАКЦИЯДӘН: Кадерле дуслар! Мондый кульъязмалар безнең "Мәдәни җомга"да даими биреп барылачак. Әгәр кемдә дә булса классикларыбызның кульъязмалары булса, безгә рәхим итегез!

ЙОЛДЫЗНАМӘ
(26 гыйнвар - 1 февраль)

КУЧКАР (21.03-20.04). Атна сездән сабырлык, үз-үзеңне кулда тотуны, ихтыяр көче туплауны таләп итә. Иң мөһиме – бәхәскә кермәгез. Юл йөргәндә, эш урынында саклану кагыйдәләрен төгәл үтәгез, бәхетсезлек булу ихтималы бар.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04-21.05). Атна башында ук сезне юллар көтә, 30 гыйнварда тагын сәфәр чыгарсыз. Бу сәфәр сезнең ихтыяҗ өчен кирәк, шуңа күрә дә аңа алдан матди, рухи көч туплау сорала. Бу атнада сез илаһи көчләр ихтыярында. Сез аны изге максатларга юнәлтегез, тупаслыктан, бәхәсләрдән сакланыгыз.

ИГЕЗӘКЛӘР 22.05-21.06). 27се көнне сезгә мул итеп акча, табыш керә. Әмма яңа эшләргә керешү өчен бу уңайлы атна түгел. Вакыйгалар, кешеләрнең явызларча мөнәсәбәте сезне сынау алдына куя. 30ы көнне автомобильдә юл йөргәндә ашыкмагыз.

КЫСЛА (22.06-22.07). 26, 28, 29ы көннәре сезгә уңыш, канәгатьләнү китерер. Сезгә уңай тәэсир итә торган очрашулар, дустанә вакыйгалар кичерерсез, дустанә элемтәләр урнаштырырсыз. 27, 30, 31е сезнең өчен шактый борчулар китерә. Яраткан шөгылегез белән мавыгыгыз, зур эшләргә алынмагыз, төшенкелеккә бирелмәгез.

АРЫСЛАН (23.07-23.08). 27, 29, 30, 1се сезнең өчен уңышлы көннәр. Күңелсез вакыйгалардан башланган атна, сәяхәткә, юлга чыккач, сезгә рухи дәва бирәчәк. 28е көнне зур проектларга керешмәгез. Ул сезнең өчен уңышсыз вакыт. Илаһи көчләр ярдәмгә килер. Җан таләбенә колак салыгыз, изге гамәлләр кылыгыз, сөенеч алырсыз.

КЫЗ (24.08-23.09). Атнаның ике көне – 26, 27е сезгә мәрхәмәт күрсәтә. Сезнең матди табышка корылган эшлекле мөнәсәбәтләрегез финишка килеп җитми генә таркала. Шуның нигезендә сез эштә дә, өйдә дә бәхәс, гауга чыганагы булып торасыз. Атнаның төп өлешен шушы халәт билә́п тора. Гаепне кешедән эзләргә ашыкмагыз, үзегезнең кылган гамәлләрегезгә аек акыл белән бәя биреп карагыз, ялгышыгызны тапмый калмассыз.

ҮЛЧӘҮ (24.09-23.10). Гыйнварның соңгы атнасы сезгә дә сынаулар куя. Ул бәхәсле көннән башланып китә. 27се көнне сезгә сәламәтлегегез турында кайгыртучанлык күрергә туры киләчәк. Салкын тиюләрдән һәм шуның нигезендә килеп чыга торган авырулардан сакланыгыз. Дөрес, атнаның соңгы ике көне сезгә шәфкатьле.

ЧАЯН (24.10-22.11). 26сы көнне юл йөргәндә, транспортта, эш барышында технология, юл йөрү һәм транспорт белән дөрес идарә итү кагыйдәләреннән читләшмәгез. Аз гыйна ялгышлыкның да бәхетсезлеккә китерү ихтималы бар. 28, 29, 30ы көнне үз-үзегезне кулда тоту таләп ителә. Бәхәскә кермәгез, юк-бар өчен тавыш чыгармагыз. 31е көнне табыш алырсыз һәм гаилә бюджетын тулыландырырсыз.

УКЧЫ (23.11-21.12). Сезнең хастаханәгә эләгү ихтималыгыз зурдан. Сәламәтлек турында вакытында кайгырту һәм чара күрү күпкә хәерле. Сезнең өчен атна бик уңышлы түгел. Зур эшләргә керешергә ярамый. Анда бәхәсле минутлар да, күңелсез вакыйгалар да бар. Әмма соңгы ике көн сезнең файдага.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12-20.01). Атна сәфәр чыгудан башланып китә. Ләкин юл чыкканда артык ашкынмагыз, ул әлләни зур канәгатьләнү китермәс, борчулар туар, тормышыгызга көтелмәгән, ямьсез борылыш китерер. 29, 31, 1есе көнне сезне көтелмәгән вакыйгалар, очрашулар көтә.

СУКОЯР (21.01-19.02). Атнаны нииндидер бәхәсле кичерешләрдән башлап китсәгез дә, атна дәвамында сез иң бәхетле кеше, үсеш кичерәсез: акча керер, зур эшләр башларсыз, илаһи көчләр сезнең тарафта булыр, яшәү, мәгънәсе турында пышылдар. Ләкин 31е көнне финанслар белән сакчыллык күрсәтегез, сезнең кесәгә керер-чыгарга теләүчеләр табылыр.

БАЛЫК (20.02-20.03). Сез атнаның иң бәхетле кешесе. Һәр тармакта, һәр өлкәдә сез югары уңышларга ирешерсез. Планеталар сезнең карамакта, алар сезгә изгелек, бәхет юллый. Серле, изге көчләр дә сезгә уңыш чыганагы булып тора.

Күләгәдә төлке бар

Баскыч бәласе

Бу вакыйга Казанда була. Үткән елның ноябрь аенда алтмышны узган бер әби-карчык фатирында ишек кыңгыравы чылтырый. Коммунизм идеалларында тәрбияләнгән әбекәй "Кем бар анда?" дип сорап та тормыйча, ишекне шар ачып җибәрә. Шуны гына көтеп торган йорт басучы өч кешенең икесе, атылып ишектән килеп керә, өченчесе ишек артында караулда кала. Караклар юлда торган әбине стенага таба төртеп җибәрәләр, әби, егылганда тотынып нәрсә эзләп, кулы белән җыелмалы тимер баскычны урыныннан кузгата. Тимер баскыч, үз чиратында, тар аралыкта, йортбасарлар башына килеп төшә. Берсенә каты ук эләгә, ахырысы – анысы һуштан язып идәнгә ава. Икенчесе исә, баскычны, әбинең һәм аның нәсел-нәсәбен йомры сүзләр белән кат-кат искә ала-ала, "поддельнигын" фатир ишегеннән кире коридорга сөйрәп чыгара. Исәпләре – качу. Әби, йорт басучылар артыннан ишеген ябып, аксый-аксый телефонга килә, милициягә "жалу бирә". Ул арада оператив төркем килеп җитә, ишек алдында каракларның өчесен дә тотып бәйлиләр. Менә хәзер өйдәге тәртипсезлек тормыш ямен боза, дип карагыз инде. Әгәр тимер баскыч үз урынында – балконда торса, вакыйгаларның ахыры күңелсез булыр иде.

Менә сиңа мәче!

Чаллыда ике хатын яшәгән фатирга акча, алтын әйберләргә нәфесе төшеп, бер имансыз кеше шалтырата. Өйдә яшәп ятучы... мәче хуҗабикәләренә ярдәмгә килә. Ишек шакучы үзен "Горгаз" инспекторы дип тәкъдим итә, ишек ачылып, каршысына ике ханым килеп баскач, кесәсеннән пистолетка охшаган нәрсә тартып чыгарып, боларга төби (соңыннан "пистолет"ның карага буялган агач кисәге икәне беленә). Үләр дәрәҗәгә җитеп курыккан хатыннарны бүлмәгә этеп кертеп, йорт басучы аларның "стенка"дагы бөтен кыйммәтле нәрсәләрен алып, төреп маташканда... карак өстенә бу гаделсезлекне күреп ярсыган мәче сикереп төшә. Сиам мәчесе усал бит ул, каракны битенә үткен тырнакларын батырып, тешләп һәм тырмап, "пистолетын" ташлап качарга мәҗбүр итә. Шундый мәчең булса, эт тә кирәк түгел...

Һавадан төшкән акча

Монысы Әлмәт шәһәрендә булган хәл. Бер пенсионер милициягә чүп савыты яныннан-урамнан тапкан пистолет китереп бирә. Тәртибе шундый – бу гамәле өчен картка шактый мул итеп акча түлиләр. Карт авызын ерып, өенә карчыгы янына кайтып керә: чүп чиләге дә буш, күктән төшкәндәй, көтмәгәндә кесәгә акча да килеп керә...

Бәрәңге – коткаручы

Казанда икенче бер пенсионер милициягә җитдирәк "табыш" китерә. Ике "текә" егет картның гаражын "чистартырга" килә. Берни дә абайламаган карт кич белән соң гына гаражына бәрәңгегә килсә, гараж ишеге ачык, уты янып тора, ә аста – базда ике карачкы шәйләнә – нидер эзлиләр. Зиһенле карт, шпионнарча йомшак басып, баздан баудан ишкән "баскыч"ны тартып ала. Теге ике карак аста бикләнеп кала бит! Хәзер аларга кетердәп торган тозлы кыяр белән кыздырылган бәрәңге ашап рәхәт кичерү тиз генә тәтемәс инде.

("АиФ Регион").

Игътибар яңа рубрика: Мәшһүрләр дә адәм баласы

Илбашка теләк белдерү

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев республика журналистлары белән очрашкан чакта: "Иртә белән кырынганда мин башкарасы көндәлек эшләремне янә күздән кичерәм, гомумән, алда торган планнар турында кайта-кайта уйлыйм", – дип әйткән иде. Йөз-бит шәрифендәге төкләрдән арынганда башына матур-матур идеяләр килүен дә искәртте Илбашыбыз. Хуш, кем кайчан уйланырга ярата – һәрбер адәм баласының үз эше. Бу форсаттан файдаланып, шундый теләк кенә белдерәсе килә: иртән халык күзенә чыгарга әзерләнгәндә Президентыбыз милләтнең чәчәге саналган зыялыларның тормышы, гомумән, мәдәниятнең бүгенге хәле турында күбрәк уйланып, башына һәркемне сөендерерлек матур уйлар килсен иде һәм... озаграк кырынсын иде.

Әйтми – беленми, ачмый – күренми

Ренат АКЧУРИН, ***атаклы кардиолог:***
"Борис Николаевич Майкл Дебейкиның "Тибүче йөрәкнең диетасы" исемле
китабы белән таныш... Спиртлы эчемлекләргә килгәндә, күп булмаган микъдарда
аларны кулланырга мөмкин. Хәтта шундый француз феномены да бар: көнгә 100-
150 грамм коры кызыл шәраб эчеп кую атеросклерозның азып китүен тоткарлый...
Мин бит премьерыбызның да йөрәгенә операция ясаган идем. Виктор Степановичның
вакыты булганда, кайчак аралашырга тырышабыз. Мин аның белән берничә тапкыр
ауда да булдым. Ул – бик һәвәс аучы, машинада тиз йөри, мәргәннәрчә ата..."

Людмила ЧУРСИНА, ***СССРның халык артисты:***
"Беләсезме, миндә ничә кан буталган? Урыс канынnан тыш, грек, төрек, поляк, латышныкы...
Ә кино сәнгатендәге кайбер интим күренешләргә килгәндә, "Анар үскән утраулар-да" фильмында мин анадан тума хәлдә басып торам. Нигә, матур күкрәкле яшь хатында шушы байлык белән күпмедер бүлешү теләге һәрвакыт була. Әлбәттә, матур күкрәк яки аппетитлы арт янына башкалары да кирәк..."

Алисә ГАЛЛӘМОВА, ***Халыкара гроссмейстер:***
"Мин белмим, Казанга кайтуым бәхеттерме, әмма китүем бәхетсезлек булып чыкты. Бу адым шәхси тормышымдагы ялгышым гына булып калмады, шахмат өлкәсендә дә мин бик күпне югалттым.
Ә шахматтан киткән очракта, мин хуҗабикә булачакмын. Өйдә малаем белән бергә яшәргә уйлыйм..."

Михаил ГОРБАЧЕВ, ***СССРның экс-президенты:***
"Без пицца ашарга элек тә йөргәләдек һәм менә хәзер дә барып килдек – ролик төшерергә. Минем гаиләм, Раиса Максимовна безнең баруыбызга каршы иде. Әмма мин киттем...
Пицца – үзенә бер төрле ризык бит, чөнки ул кешеләрне берләштерә һәм тормышның мөһим өлеше булып тора. Кешеләр аны ашап кына калмыйлар, шул ук вакытта үзара аралашалар да..."

Александр КОРЖАКОВ, ***Русия Президенты тән сакчыларының элекке башлыгы, РФ Дәүләт Думасы депутаты:***
"Без үзебезгә аллалар барлыкка китердек, ә алар, фанилларча, сыяләр дә, кәкәй дә итәләр, тыгынганчы ашап, лыкынганчы эчәләр дә..."

Фәндәс САФИУЛЛИН, ***Татарстан халык депутаты:***
"Әгәр бөтенләй эчмәсәң, иртән баш авыртмаячак. Мин, мәсәлән, 31 декабрьдә спиртлы эчемлекне тамчы да капмадым. Ураза! Менә инде икенче ел мин ураза тотам..."

Пәйгамбәрләр гамәле

Узган үгез елы кайбер язучылар өчен шактый бәрәкәтле булды: дәртләре ташып торган бер иш ир-егетләребезнең балалары дөньяга килде. Бу җәһәттән бәгъзеләр "Ну и что?" дип борын җыерырга мөмкин. Авыз күтәреп сөйләрлек вакыйга түгел, янәсе. Юк шул, түбәндә китерелгән исемлек бик үк гадәтиләр рәтенә керми. Хикмәт шунда: бу әдипләребезнең балаларын аларның икенче (бәлки, өченче), яшь хатыннары тапты! Кыскасы, быелтыр Ләис Зөлкарнәйнең – Мәрьям исемле кызы, Гәрәй Рәхимнең – Кобрәт атлы малае, Ринат Мөхәммәдиевнең – Зөләйхасы, Айдар Хәлимнең Кадриясе дөньяга аваз салды. Бәхет-тәүфикълары белән туып, гомерләре озын булсын, Ярабби!

Мәгълүм булганча, Равил Фәйзуллин да яшь хатынга өйләнде. Әмма бу гаиләдә әлегә үрчем күренми. Кем әйтмешли, булыр – орлыгы Бохарада түгел...

P.S. *Астрологлар раславынча, юлбарыс елында, гадәттә, малайлар 7-8 процентка күбрәк туа. Әгәр нәсел дәвам иттерүче варислар турында хыялланучылар булса, йоклап ятмыйча, уңай форсаттан файдаланып калыгыз.*

Мәхәббәттә угрылык кичереләме?

Татарстанның һәм Русиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Ренат Ибраһимов һәм аның хәләл җефете Альбина 10 гыйнварда "Русия" телеканалы оештырган "Минем гаилә" тапшыруында катнаштылар. "Ирләрне хәләл хатыннарыннан ничек урлап китәләр?" Шушы темага багышланган әлеге тапшыруда Альбина ханым мәхәббәттә ихтыярсыздан "угры" исемен алуы, ягъни мәшһүр җырчыны ничек итеп үзенә каратуы турында сөйләде. Ә элекке хатынына "урланган" Ренат исә мондый хәлләрне Октябрь инкыйлабыннан соң дин кануннарының йомшаруына бәйләп аңлатты. Ай-һай, хикмәт шунда гынамы икән?! Ренат Ибраһимов үзе 50 яше тулу уңаеннан чыгарылган компакт-дискына, әнә, тикмәгә генә "Мин яратам..." дип исем кушмагандыр. Барысы өчен дә нәкъ менә шул авызлыклауны белмәс Ярату гаепле бугай.

Әллә Алла, әллә "Волга" саклаган

...Күптән түгел Татарстан Премьер-министры белән булган юл хәвефе вакытында аны "иномарка"да утыруы гына коткарып калган, диләр. Бу чыннан да шулаймы соң?

Белгечләр раславынча, Фәрит Мөхәммәтшин утырган "Мерседес", чынлап та, Оренбург трактында килеп чыккан авариядә аның гомерен саклап калды. Әгәр ул сериялап чыгарыла торган "Волга"да утырса, һәлакәт нәтиҗәләре Премьер өчен дә, юлдашлары өчен дә күңелсез тәмамланган булыр иде. Һәрхәлдә, "Мерседес", каршысына ыжгырып килгән "КамАЗ" белән бәрелүдән читкә тайпылгач, кюветка төшеп утыра. Хөкүмәт җитәкчесе, бәхеткә, җиңелчә тән ярасы гына ала, башкасыннан әлеге "иномарка" йолып кала. Әмма, шулай да, аның исән калуында "Волга"ның өлеше зур. Әлеге машинада Премьерның юлдашлары утыра, алар – ДАИ хезмәткәрләре – төп ударны үз өсләренә алалар һәм, үз тормышлары бәрабәренә, Фәрит Хәйрулловичның гомерен саклап калалар.

Ил белән "кухаркалар" идарә иткәнче, кухняда да югалып калмаучы эшлекле хаким булса, күпкә отышлырактыр. Президентыбыз Минтимер Шәймиев – нәкъ менә шундый затларның берсе. Мөмкинлек булган очракта ул үзе табын әзерләргә ярата. Әмма дәүләт җитәкчесенең мондый эшкә вакыты бик аз кала. Хәер, Минтимер Шәрипович җәмәгате Сәкинә ханым әзерләгән аш-суны бик яратып ашый. Ә ризык мәсьәләсендә ул артык нәзберек түгел, диләр. Затлы кәнфитләргә исе китмичә, гап-гади прәннек белән дә чәй эчә Илбаш. Сугыш елларында алабута күмәче, туң бәрәңге көлҗемәсе, көрпә белән кара солыдан пешерелгән ипи авыз иткән, ә студент елларында кайчак көнгә өчәр тапкыр булканы кайнаган су белән ашаган кеше олпат яшькә җиткәч ничек инде тәгамнең кадерен белмәсен?! Шөкер, хәзер бездә җаның теләгән төрледән-төрле ашамлыклардан кибет киштәләре сыгылып тора. Тик менә башкалабыз мэры азык-төлекнең бәясен законсыз төстә күтәреп кенә куймасын.

М.КОЗЛОВСКИЙ фотосы.

Күреп кайту

Җәгъфәр ишан Бохарада йөреп кайткач, аның янына якыннары һәм иярченнәре күрешергә килгән. Алар: "Инде күп җирләрне гиздегез, безгә күргән гаҗәп хәлләр турында сөйләгез", – дигәннәр. Моңа каршы ишан: "Бохарада хатыннар хаҗәтләрен өй түбәсенә чыгып үтиләр. Шул хатыннарның шәрә күтен күреп кайттым, аннан башка гаҗәп нәрсә күргәнем юк", – дигән, имеш.

Мәшһүрләр колагына

- *Кешенең ахмаклыгына дәлил – бер-беренә дошман булган ике кешене дус итеп тотуыдыр.*
- *Дөньяда иң авыр нәрсә – ризык аз вә гакыл күп булып, икесе бергә җыелуыдыр.*
- *Хөкүмәт башында торучылар кәҗә тәкәсенә генә булса да гыйбадәт кылучы, динле булсыннар.*
- *Ирләр тән булса, хатыннар җандыр.*
- *Һәр ике кеше дә ирле-хатынлы булмый.*
- *Күрү өчен йөрүче хатыннарга караганда күрелү өчен йөрүче хатыннар күбрәк була.*
- *Ирләрнең өйдә утыруы, хатыннарның читтә йөрүе фәкыйрьлек коралыдыр.*
- *Алдан күрүчән тәрбияле һәм дә гакыллы хатыннан мәхрүм йорт – җимерек йорт.*
- *Бер хатын ялгыз бер ирне генә бәхетле итүгә бурычлы.*
- *Дәрт ирләрдә бер өлеш булса, хатыннарда җиде өлеш була.*
- *Наданнарның галимнәрдән өйрәнгән нәрсәләренә караганда, галимнәрнең наданнардан өйрәнгән нәрсәләре күбрәк була.*
- *Балаларга калдыра торган мирасларның иң кыйммәтлесе – дин өйрәтеп калдыру.*
- *Дөреслек катнашмаган ялганга каршы торуы җиңел, каршы тору авыр булган нәрсә – дөреслек катнашкан ялган.*
- *Өмете беткән кешенең өмете – үлем генә.*
- *Ата-анаңны кабергә салган дөньядан ни мәрхәмәт өмет итмәк кирәк!*

Ризаэддин бабагыз ФӘХРЕДДИН.

Тургай

Хәкимҗан ХАЛИКОВ

Кузен ачтым

Иртән барсам – чишмәбезне
Төмам харап иткәннәр:
Кузен саклап торган ташын
Ватып алып киткәннәр.

Югыйсә бит бу елгада
Башка таш та бетмәгән?!
Менә хәзер яр ишелеп,
Чишмә юлын бикләгән.

"Монда миңа
кадер юк", – дип,
Ташлап китсә чишмәбез,
Инешсез дә калабыз бит,
Аннан соң без нишләрбез?!

Кулым белән казып, шундук
Кузен ачтым мин аның.
Шул вакытта күрсәгез сез
Ямьләнгәнен дөньяның!

Чишмә ургый сөенечтән,
Җырлап ага сулары.
Шатлыгымнан аның кебек
Мин дә җиңел суладым.

Атлар ярату сере

Кыш җиттеме, сагындыра
Ат саклаган болыннар;
Әниләре тирәсендә
Уйнап йөргән колыннар.

Ялларыннан сыйпап үтә
Җәйнең җылы җилләре...
Шулай берчак кара айгыр
Кинәт кешнәп җибәрде.

Як-ягыма карап алсам -
Яр буенда бүреләр!
Бераз туктап торалар да
Тагын тыз-быз йөриләр.

Уйнап йөргән колыннар да
Кинәт тынып калдылар.
Әниләре безне шундук
Уратып та алдылар.

Ә мин атлар арасыннан
Бүреләрне күзәтәм:
Алдагысы – башлыклары
Гүя үрнәк күрсәтә.

Тешлим генә диган иде
Аккашканың арт ботын,
Аткай тибеп, карт бүренең
Үзен яхшы акыртты.

Икенчесе һөҗүм иткәч,
Аңа шундый типте ул;
Тояк белән башын ярып,
Аны тынсыз итте ул.

Алмачуар бәлеш итте
Бер бүренең танавын.
Дүртенчесе, коты очып,
Ялтыратты табанын...

Бу вакыйга әле һаман
Истән чыкмый нигәдер.
Минем атлар яратуым,
Бәлки, шуннан киләдер.

СЫНАТУ

Илфат белән урманда
Җиләк җыйган чагында,
Күтәрелеп карасам -
Елан тора янымда!

Телен сузып: "Сс-сс", – ди...
Кая керер җир тапмыйм.
Ярдәм көтеп дустымнан:
"Чыбык бирче, Илфат?" – дим.

Илфат дәшми. Күрәсең,
Ишетмәде сүземне.
Үзем исә еланнан
Бер дә алмыйм күземне.

Шактый торгач карашып,
Әллә инде шүрләде.
Елан кинәт юк булды,
Шуннан аны күрмәдем.

Тыр-тыр чапкан Илфатны
Көчкә куып җиттем мин.
"Нигә ташлап киттең?!" – дип,
Аннан үзен теттем мин.

Күз алдымда әле дә
Мышык-мышык елавы.
Куркак дустың булганчы,
Артык икән булмавы.

Ныграк төшенәм

Вагыйзь үзе белгәнне
Ялынсаң да өйрәтми.
– Эшне аны үзеңә
Өйрәнергә кирәк, – ди.

Ә мин белгән һөнәрне
Һич кызганмыйм кешедән.
Өйрәткәндә үзем дә
Эшкә ныграк төшенәм.

КөнЧелек

Нинди генә
Җырлар белми
Сыерчык!
Шуңа аннан
Көнләшкән, ди,
Бер чыпчык.

Сыерчыклар
Үтерде, дип,
Кызыңны,
Котырткан ул,
Чыр-чыр килеп,
Козгынны.

"Коң!" – дип кенә
Куйган козгын
Ачудан;
Шулчак кызы
Кайтып килгән
Басудан.

Чыпчык исә
Чак котылган
Үлемнән...
Бик кызганып
Тормыйм әле -
Үзеннән,
үзеннән.

Тыйнак малай

Вилдан сөйли: "Әни миңа:
Син, – ди, – пәхтә, җыйнак малай...
Чынлап, малай.

Мине күрсә, елавыннан
Туктап кача елак малай,
Чынлап, малай.

"Кыйныйбыз!" – дип, урап алды
Бүген мине унлап малай,
Чынлап, малай.

Унысын да өеп куйдым,
Бар да минем сымак малай,
Чынлап, малай:
Мин бит бик тә тыйнак малай".

"Әнә, алар!" – диган идем,
Шым булды, әй, тыйнак малай,
Чынлап, малай.

ИСКӘРТҮ

Ни арада бу кадерле
Кечерәйгән кулмәгем?
Әни югач, мин бит аны
Тик бер атна кимәдем.

– Әнием дим, кара әле,
Җиңе бигрәк кыскарган.
Моны кисәң, әллә нилләр
Ишетерсең кызлардан...

Дәү әтием җитди генә
Әйтеп куйды шуннан соң:
– Җиңең кыска булса булсын,
Кулың озын булмасын.

Теләп башкарган эш

"Үзең ясадыңмы, – диләр, -
Бу сыерчык оясын?
Түбәсенә нинди матур
Манара да куйгансың!.."

Эшлим икән, әти кебек,
Эшлим аны яратып.
Үзең теләп башкарган эш
Яхшы була һәрвакыт.

Фаҗигаләр елы

Узган елны чын-чынлап фаҗигаләр елы дип атарга була, чөнки аларның саны 1582гә җитте. Техникага бәйле фаҗигаләр 8,7 процентка, табигый бәла-казалар 29,7 процентка артты. Аларда 82 мең русиялеләр һәлак булды. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы подразделениеләре фаҗига һәм бәла-каза вакытында 4,5 мең тапкыр коткару эшләрендә катнаша һәм 11 мең кешене коткарып кала.

("Известия").

Тәмәкечеләргә көн бетә бара

Майнадагы Франкфурт халыкара аэропорты дирекциясе 1 гыйнвардан пассажирлар өчен бирелгән барлык биналарда

курыкмый, ди ул. Киресенчә, туганнарына язылган васыятьнамәсендә Питер үзенең җәсәден, 50 данә ипи шары ясап, диңгезгә ташларга кушкан.

("СПИД-Инфо").

Тегермән... канатсыз калган

Ирландиягә һәм Британиянең төньяк-көнбатыш районнарына көчле давыл һөҗүм итеп (секундка 145 км) 100 яшьлек агачларны тамыры белән кубарып ташлый, автомобильләрне әйләндереп сала, түбәләрне очыра, җил тегермәннәренең канатын сындыра. Раштуа бәйрәме алдыннан гына меңнәрчә гаиләләрне электрсыз кала. Илгә гаять зур зыян килә.

(Ассошиэйтед Пресс).

Мордар китүчеләр арта

РФ дәүләт статистика комите-

каль җыелышка башкалада яшәүче күренекле кешеләр, сәхнә йолдызлары үз фатирларында яшәүче җанияләрен ияртеп, күтәреп килгәннәр иде. Күренекле астролог Павел Глоба Нострадамус исемле ташбакасын, Семен Осиашвили Гаврик исемле ак күсесен, "Божья коровка" җырчы төркеме Нельсон исемле этләрен, данлыклы цирк артисты Наталья Дурова үзе белән кулга ияләштерелгән бүре һәм 3 метрлы елан алып килгән иде. Бар кешенең күзе телевидениедә бара торган "Хайваннар дөньясында" тапшыруын алып баручы Николай Дроздовта булды: ул учына зур кара үрмәкүч утыртып, җилкәсенә кара елан салып килеп керде. Георгий Жженов кына бер хайван да ияртми килгән. 5 ел элек яраткан этен җирләгәннән соң, ул кабат эт тотмаска булган.

Шулай хайваннар һәм кешеләр аралашкан арада, Н.Дроздовның үрмәкүче югалып, бар кешене куркуга салды. Үрмәкүч табылды, ЧП булмады: барысы да "Ребята, давайте жить дружно" дигән шигарьгә тугры калдылар.

("МЭ").

тәмәке тартуны тыярга булды. Аэропорт администрациясе исеменә тартучы мосафирлардан нинди генә шикаять кермәсен, дирекция чигенми, тартмаучылар мәнфәгатен яклавын белдерә. Бу чара тәмәке белән сату итүче Германия эшкуарлары кесәсенә дә суга. Чөнки Германиядә ел саен 33 млрд. маркалык тәмәке-сигаретлар сатыла иде.

(Рейтер).

Аэростат арзангарак төшә

Американың НАСА аэрокосмик агентлыгы космик тикшеренүләр өчен 30 катлы йорт биеклегендә гаять зур аэростат төзергә булды. Бу аэростат 1350 кг авырлыктагы аппаратларны 35 км биеклеккә күтәрә алачак. Аэростат һавада 100 көннән артык торачак. Ул спутник җибәрүгә караганда арзангарак төшә. Аны Австрия яки Яңа Зеландиядән җибәрү күздә тотыла.

Парик кию тыела

Испаниядәге Кадис шәһәрендә, хакимияттән рөхсәт алмыйча һәм полициядә теркәлмичә, хатын-кызлар парик киеп йөри алмыйлар. Мондый тәртип моннан ике ел элек – парик кигән хатын-кызлар тарафыннан байтак кына талаулар булганнан соң кертелгән.

Бәдрәф кәгазе коткарган

36 яшьлек испанлы Хулия Кордоба ике дошман төркем үзара атышкан вакытта кибеттән килеп чыга. Бер ядрә аның куркудан күкрәгенә кыскан сумкасына – дөресрәге андагы туалет кәгазе рулонына эләгә. Югыйсә, ядрә әлеге ханымның йөрәгенә үтеп керәсе булган.

Җәсәде – балыкларга

Англиянең көньягындагы Сомерсетта яшәүче 51 яшьлек чәчтараш Питер Ходж бик һәвәс балыкчы икән. Хөтта балыкларга азык булудан да

ты мәгълүматларына караганда, илдә үз-үзен үтерүчеләр елга (100000 кешегә) 39-40ка җитә. Шуның 80 проценты ир-атлар өлешенә туры килә. Боларның да бары тик 20 проценты гына пенсия яшендәгеләр. Хатын-кызлар арасында бу нисбәт бергә-бер. Русиядә үз-үзен үтерүчеләр АКШ һәм Япониядәгедән 3-4 тапкырга артыграк.

("АиФ").

Шайтанның күзе ачылачак

Мәскәү циркында чыгыш ясаучы Шайтан кушаматлы макакага (маймыл) берничә көннән операция ясалачак. "Артист"ның күзендә катаракта булып, ул берни дә күрми. Күрмәсә дә, маймыл, әйбәт ишетүе аркасында, бәрелеп-сугылып йөрми. Мондый операция Русиядә әлегәчә кадәр ясалмаган. Операциядән соң Шайтанның ике күзе дә күрә башлаячак, дип өметләнәләр.

("КП").

Егетләр, әйдәгез, дус яшик әле

Мәскәүнең "Мерилин" клубында: "Кешеләрне саклаучы хайваннар" акциясе булды. Бу уни-



Ул салым түләмәде.
В.ЧУМАЧЕВ рәсеме.
("КП").

Кунакханәләр өчен дә сугыш

9 гыйнварда иртән Мәскәүдә үз йорты ишек төбендә "Русия" кунакханәсе директоры 49 яшьлек Евгений Цимбалистов үтерелде. Мәскәү эчке эшләр идарәсе хезмәткәрләре бу җинаять заказ буенча эшләнгән дип фараз итә. Җинаятьчеләр директорның акчасына да, башка кыйммәтле әйберләренә дә тимәгәннәр. Кунакханәләр буенча йогынты ясау мәйданын бүлешү, күрәсең, һаман саен кыза бара: әле күптән түгел генә "Рэдиссон-Славянская" кунак йорты милкен бүлешүчеләрнең берсе булган АКШ гражданы Пол Тэйтумны, аннан соң "Совинцентр" генераль директорын (аңа "Международная" кунакханәсе дә керә) автоматтан атып үтергәннәр иде. Сүз уңаеннан берничә ел элек "Русия"нең элекке директоры үтерелүен дә әйтергә кирәк. Анысын балта белән чапкалаганнар иде.

Уенчык бүреләрдән коткара

Кукмара районындагы Комар авылының бишенче сыйныфта укучы ике малае кырда чаңгы шуарга чыгалар. Кинәт аларны бүре көтүе куып җитә. Малайлар куркып калмый – чаңгыларын салып, аркага-арка басалар да, чаңгы таякларын (мылтык шикелле) бүреләргә төбиләр. Бүреләр малайлар тирәли әйләнеп йөриләр, китәргә уйламыйлар да.

Бу вакыйга бик күңелсез тәмамланыр иде, әмма малайларның берсе кесәсендә ике шартлаткыч (петарда) барын исенә төшерә. Бүреләргә алар шартлаткыч ыргыталар һәм бүреләр куркып кача. Малайлар кайтып сөйләгәч, җирле аучылар бүре көтүен юк итәргә карар кыла.

Сарык урынына... кешеләр

"Долли сарыгы" дип дөнья шаулаткан фәнни ачышны кешеләр белән кабатлап карау нияте дөньякүләм җәмәгатьчелекне борчуга салды. Чикаго галиме Ричард Сид озакламый дөньяда беренче кеше игезәкләре чыгара башлауга керешәчәген белдерде. Ул елга 200 мең игезәк кешеләр "җитештерергә" ниятли. Коточкыч тәҗрибәләрен үткәрер өчен ул ярдәмчеләр дә, бала табудан мәхрүм ир белән хатын да тапкан. Баласыз гаилә фән хакына "беренче игезәкләр"нең (нәкъ үзләренең копияләрен) әтиәнисе булырга ризалык биргән. Бу игезәкләр аларга нибары бер миллион долларга төшәчәк. Әмма, җәмәгатьчелек басымы астында, АКШ Президенты Билл Клинтон бу эшне үз илендә тыйды. Моңа Аурупадагы күп кенә илләр дә кушылды.

("КП").

Татар энциклопедиясе битләреннән

АРШИНОВ Виктор Петрович (1945 елда туган), нәкышче, график, 1993 елдан Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Иҗаты: "Реквием" картинасы (1973). Г.Тукай һәм М.Җәлил әсәрләренә рәсемнәр, "Алтынчәч" операсына театр костюмнары эскизлары (1973-76) һ.б.

АСАНОВА Неллифор Абдулла кызы (1935 елда туган), әдәбият белгече, философия фәннәре докторы, 1983 елдан профессор. 1961 елдан Казан университетында фәнни-педагогик эштә. Хезмәтләре: 20 нче гасыр француз әдәбияты, романтизм мәсьәләләре, әдәбият-сәнгать бәйләнышлары.

АТЛАСОВ Һади Мифтахетдин улы (Һади Атласи, 1876-1938), тарихчы, җәмәгать эшлеклесе. 1898-1903 елларда Буа, 1903-09 елларда Әлмәт районы авылларында укыта, кыз балалар мәктәбе ача. 1907 елда 2 Дәүләт Думасы депутаты. Патша администрациясе мәктәпләрне ябкач, фәнни эш белән шөгыльләнә. 1913 елдан археология, тарих, этнография җәмгыяте әгъзасы. 1917-18 елларда Милли Мәҗлес депутаты, мәктәп реформасы үткәрү эше алып бара. 1920-30 елларда Казанда, Бөгелмәдә педагогик эштә. Хезмәтләре: "Казан тарихы", "Сөембикә", "Себер ханлыгы тарихы", мәктәп дәреслекләре. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

АТНАГУЛОВ Сәләхетдин Садри улы (1893-1937), сәясәт, матбугат эшлеклесе, язучы. 1917-18 елларда Милли Мәҗлес депутаты, Урал-Идел штаты комиссиясе рәисе, 1919-20 елларда "Кызыл Армия" гәзите мөхәррире, Татар-Башкорт хәрби коллегия комиссариаты әгъзасы. 1920-29 елларда ТАССР халык мәгариф комиссариатында, "Татарстан" гәзите мөхәррире (1922-24). Яңалиф төзүдә катнаша. 1930 еллар башында фәнни педагогик эштә. Татар имлясын камилләштерүгә өлеш кертә. "Кечкенә шахта" (1925), "Гарантияле мәхәббәт" (1927), "Каф тавы артында" (1928) әсәрләрен яза. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

АФАНАСЬЕВ Вадим Алексеевич (1932 елда туган), скрипкачы, педагог. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. 1958 елдан Казан консерваториясендә укытучы. 1964-69 елларда музыка мәктәбе директоры. 1990 елдан камера ансамбле, концертмейстер әзерләү кафедрасы мөдире, 1992 елдан профессор.

АФЗАЛ (Афзалов) Гамил Гыймазетдин улы (1921 елда туган), Татарстанның халык шагыйре (1991). Г.Афзал иҗатында көлке, мәзәккә, сатирага корылган кечкенә хикәяләргә, балалар өчен шигырьләргә, җырларга зур урын бирелә. "Кар сулары" (1957), "Ышаныгыз" (1971), "Кышкы озын кичләрдә" (1975), "Айлы кичләр" (1977), "Шундый-шундый эшләр" (1988) җыентыклары, "Сайланма әсәрләр"е (1991) басыла. 1977 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелә.

АХМАТОВА Анна Андреевна (1889-1966), урыс шагыйрәсе, тәрҗемәче. 17 яшеннән бабалары фамилиясен йөртә. 1941 елда Чистайда эвакуациядә була.

Дүшәмбе
26 ГЫЙНВАР
"ТАТАРСТАН"
7.00-8.00 "Чулпан".
17.35 Мультфильмнар.
17.55 Балалар өчен "Тамчы".
18.10 "Эшмәкәрлек телевидениесе".
18.45, 20.45 "Җиһан". Хәбәрләр.
19.00 "Замандаш" циклыннан. "Якты юл". Н.ЮЛТЫЕВА.
19.45 Яңалыклар.
20.00 "Барысы өчен дә хоккей".
20.30 "Әлли-бәлли-бәү".
21.00 "СИРАНО ДЕ БЕРЖЕРАК". (21.45 – "Яңалыклар").

"ЭФИР"
6.00, 10.20, 11.30, 14.35, 2.15 Музыкага чикләр юк.
6.15 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
6.45 "Республика" информацион-аналитик программасы.
7.20 Информацион-күңел ачу программасы: "Уян һәм җырла!".
8.45 "ПЛЯСКА В МАНХЭТТЕНЕ".
10.40 "ВАВИЛОН-5".
11.45, 14.45 "Дарухана".
12.00, 15.00 "ТСН-6".
12.10 "МЕЧЬ ГЕДЕОНА". 1 нче серия.
15.10 "ЗОЛОТОЙ ТУМАН".
16.30 Мультфильм.
17.00, 19.30, 22.00, 3.20 "Шәһәр" информацион программасы.
17.15 И.Демидов шоуы: "Күзәтү".
18.20 "ВАВИЛОН-5".
19.10 Мультфильм.
20.00 "СВОБОДНОЕ ПАДЕНИЕ".
21.40 Мультфильм.
22.30 Юл патруле.
22.50 "ВУДУ".
0.20 Спорт атнасы.
0.50 "ОСП" студиясе.
1.30 Бенни Хилл шоуы.
1.45 "Атна һәлакәтләре".
3.00 Мультфильмнар.
3.40 Нәфис фильм.
5.15 "Республика".

1 НЧЕ КАНАЛ
6.00 "Хәерле иртә!"
9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 1.10 Яңалыклар.
9.15 "РОКОВОЕ НАСЛЕДСТВО".
10.00 "Могҗизалар кыры".
11.00 "Сәламәтлек".
11.30 "Бу көйне беләсеңме?"
12.15 "Бергә".
13.05 "ВОЗВРАЩЕНИЕ РЕЗИДЕНТА".
14.25 Футбол күзәтү.
15.20 Мультсериал: "Розовая пантера".
15.45 "Марафон-15".
16.05 "Йолдызлар сәгате".
16.40 "НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ РОБИН ГУДА".
17.10 "...16га кадәргеләр һәм өлкәнрәкләр".
17.30 "Деньга тирәли".
18.20 Сериал: "РОКОВОЕ НАСЛЕДСТВО".
19.05 "Җавап тотар чак".
19.30 Телеуен: "Бу көйне беләсеңме?"
20.00 "Без".
20.45 "Тыныч йокы, нәниләр".
21.00 "Вакыт".
21.40 "ПОЛТЕРГЕЙСТ".
22.45 "Атаклы кешеләр тормышы" М.Плисецкая.
23.15 Спектакль: "Женитьба".

"РУСИЯ"
7.00 Мультфильмнар.
7.15 "Уян!".
7.30, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.30 Хәбәрләр.
8.00, 23.55 Кизү булеге.
8.15 Почта аша әйберләр.
8.20 "Стронг" тәкъдим итә.
8.25 "Хәтер өчен".
8.30 Акчалар.
8.45 Графоман.
8.55 Православие календаре.
9.00 "Аншлаг" һәм Ко.
10.05 "САНТА-БАРБАРА".
11.30 "ГРАФИНЯ ДЕ МОНСОРО".
12.20 Музыкаль ринг – яңа буын.
14.35 "СЕЗОН НАЛОГОВ".
16.30 "МАЛЕНЬКИЙ БРОДЯГА".
17.30 Кроссворд.
18.00 "Бер вакыйга тарихы".
18.15 "ПОЕЗД ДО ДРУКЛИНА".
20.30 "Нечкәлекләр".
20.45 "САНТА-БАРБАРА".
21.50 "Довгань шоу".
22.20 "ГРАФИНЯ ДЕ МОНСОРО".
0.15 Автошоу.

"КУЛЬТУРА"
8.00, 0.20 Музыкаль экспромт.
8.15, 14.00, 0.00 Мәдәният яңалыклары.
